Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

06
июнь 2017
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ВИКТОР ФЁДОРОВ. «САБАНТУЙ»

ИЗГЕ БОЛГАРДА – ИЗГЕ ҖЫЕН

20 майда «Изге Болгар җыены» булып узды. Бу юлы Болгар җиренә Россиянең төрле төбәкләреннән 40 мең мөселман җыелды. Мәгълүм ки, 1095 ел элек (310 һиҗри, 922 милади ел) 21 майда Идел Болгарстанында ислам дине рәсми рәвештә кабул ителә.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

6 (282)

июнь 2017

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

32

6 ЮРТ ТАТАРЛАРЫ
Илья Торопицын

104 ЖИҢҮ ПЛАКАТЛАРЫ

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 *Нури Арслан*

ТАРИХИ МИРАС

4 Болгар. Чатырлар лагере. Фестиваль-вакыйгалар комплексы
6 Юрт татарлары. *И.Торопицын*
13 Югары мәдәниятне саклау юлында: Габделбари хәзрәт Исаев. *Ә.Бостанов*
20 «Идел»дә Каюм Кулаткы мәкаләләре
24 Итил, Саксин, Хаҗитархан, Әстерхан... *Ф.Җәүһәрова*
26 Финляндиядә татар әсирләре. *Ч.Сафиулла*

ТАТАР ГАМЕ

32 Тормыш яме (*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Леρон әңгәмәсе*)
42 Авыл — милләтнең бишеге
49 Муса авылы тарихы
54 Галәми уйлы татар улы. *А.Хәмзин*

ДИНИ МИРАС

58 Ислам дөньясы. *Г.Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

64 Кутадгу билик. (Котайткыч белем). *Й.Баласагуни*
68 Чыңгызханның ак болыты. *Ч.Айтматов*
74 Өч анкета

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

78 Гадел Кутуй

ХӘТЕР САНДЫГЫ

81 Олуг әдипкә бәйле кайбер истәлекләр. *Л.Хәмидуллин*
84 Баттал булуын онытмады... *Ф.Баттал*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Марат Закиров
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

СӘНГАТИ МИРАС

90 **Минем беренче театрым.** *Н.Дунаев*
93 **«Син сазыңны уйнадың...»** *Э.Каюмова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

96 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
98 **Тел турында уйланулар.** *Һ.Атласи*

ХӘТЕР САГЫНДА

104 **Җиңү плакатлары**
106 **Олы Мәрәтхуҗа һәм Туфан Миңнуллин**
110 **Ядкярләргә – бер гасыр.** *Р.Садыйкова*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

112 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның май ае.**
114 **«Безнең мирас» хәбәрләре**

ШАЯН МИРАС

116 **«Шалтыр-шолтыр шаулата...»**

118 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Май*
119 **Мирасворд**

Заказ №А-1056. Тираж – 2000 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 26.04.2017
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм А.Дубин, С.Львов, Татарстан Милли музее архивларыннан, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры архивыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Чишмә янында». Киндер, майлы буяу.
И.Мусин рәсеме

КӘРИМ ТИНЧУРИН
(15.09.1887 – 15.11.1938)

***

Дөньядагы барлык нәрсәләрнең нигезендә экономика дигән бер нәрсә тора.... Большевизмның башын әнә шул бетерәчәк.

***

Революция салмак темпны яратмый.

***

Бозау итен ашау белән генә арыслан сыерга әверелмәгән төсле, кухаркалардан министрлар ясап булмас.

***

Акылы белән йөрәген берләштерә алган кеше генә үзенчә тормыш кора ала.

***

Үлгән арысланны тычканнар да кимерә.

***

Тай тәртәгә нихәтле дошман булса да, ат булгач, тәртә эченә үзе керә башлый.

***

Йомшак чикләвекне корт ашый.

***

Алтын – Иванда, хатын – ишанда.

***

Сукыр тычканга карт песи дә арыслан булып күренә.

***

Безнең икмәкне ашаган кеше безнеңчә булырга тиеш.

***

Сугышып, без түгел, Наполеон да хикмәт чыгыра алмаган.

***

Авыздан чыккан һәр сүзгә балалар белән җүләрләр генә ышана.

***

Җанлы сүзләр укучыга тизрәк ирешүчән була.

***

Арысланнарның яшәүләре өчен бозауларның, сарыкларның, кыр кәҗәләренең яшәүләре кирәк.

*Текстны **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

---

* Кәрим Гали улы Тинчурин – татар драматургиясе классигы, күренекле артист һәм режиссер, Пенза өлкәсенең Спасс районы (хәзерге Демьян Бедный районы) Таракан (Аккүл-Белоозерка) авылында туган.

Безнең мирас №6 июнь 2017

Болгар. Инфраструктура

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

Болгар шәһәрлеге территориясендә каты асфальттан берничә километр автомобиль юлы салынды. Ул шәһәрлекне төньяк-көньяк, көнбатыш-көнчыгыш юнәлешләр буенча кисеп уза. Архитектура истәлекләре арасында җәяүлеләр өчен юллар, Иерусалим чокыры аркылы җәяүлеләр күпере салынды, Истәлек билгесе һәм Ак мәчет янындагы территорияләр төзекләндерелде.

Кече манара һәм Ханнар төрбәсе, Кара пулат, Габдрахман коесы, Ак мәчет, Икмәк музее янында агачлар утыртылды.

Болгар шәһәрлегенең көнбатыш, көнчыгыш һәм көньяк керү юлларында капка-манаралар яңадан төзелде. ■

УРТА ӘЛӘЗӘН

(Россиядәге иң зур татар авылының XVII йөз азагы-XIX гасырдагы тарихыннан кайбер сәхифәләр)

Ренат Мәрданов, Наилә Китаева

1780 елдан Урта Әләзән авылы Саратов губернасының Кузнецк өязенә кергән.

ПЕНЗА ӨЛКӘСЕ – ТАТАРЛАРНЫҢ БОРЫНГЫ ҖИРЛӘРЕ

Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда чорында халык шактый күп яшәгән Уза һәм Кадада елгалары арасындагы үзәнлек XIV гасырның азагыннан XVII йөзнең ахырына кадәр диярлек бушап кала. Территориядә өч гасыр дәвамында кешеләрнең бик аз санда гына көн күрүенә, беренчедән, 1395 елгы Аксак Тимер һөҗүмнәре сәбәпче булса, икенчедән, көньякта яшәүче күрше кавемнәрнең бу җирләргә оештырган яулары вакытында кешеләрне әсир итеп, аеруча Кече Азия илләреннән килгән сәүдәгәрләргә кол буларак Кара диңгез буе һәм Кырым базарларында сатып җибәрүләре сәбәп булгандыр. Шуның өстенә, XIV гасырның уртасында Азия тарафыннан килеп чыккан чума авыруы да шактый халыкны кырып сала. Болар барысы да борынгы татар җирләре – хәзерге Пенза өлкәсе, без өйрәнә торган Уза һәм Кадада елгалары буендагы кешеләрнең күпләп һәлак булуына, әсир төшеп яки качып котылып чит җирләргә таралуына этәргән.

XVII гасырның 30 нчы елларында Мәскәү хакимияте, акрынлап, Пенза төбәгендәге биләмәләрен ныгыта башлый. 1635-1636 елларда Ломовка елгасының югары һәм түбән агымнарында ике зур крепость барлыкка килә. Шул ук елларда Нугай даругасына аркылы төшеп, Козлов (хәзерге Мичуринск)-Тамбов һәм Ломов чик буе сызыгы төзелә. 1638 елда исә, көньяктан һөҗүм итүче дошманнардан саклану өчен, махсус линия буенча, Саранск, Атемар, Сура, соңрак Сембер шәһәрләренә нигез салына. 1653 елда Инсар шәһәре, ә инде 1681

елда «эшлекле кешеләр» тарафыннан борынгы татар каласы Бортас урынына Городище шәһәре төзелә. 1680 нче еллар башында Сызраньнан Городище аша Пензага да чик буе ныгытмасы төзелергә тиеш була, әмма эш төгәлләнми кала.

ӘЛӘЗӘНГӘ КАЙЧАН НИГЕЗ САЛЫНГАН?

Нәкъ менә шушы елларда Уза һәм Кадада елгалары арасындагы үзәнлектә татар авыллары барлыкка килә. Саратов тарихчысы А.А.Гераклитов фикеренчә, аларның иң борынгысы – 1685 елда нигез салынган Пәндәлгә (урысча Пенделка) авылы, дип санала иде. Дөрес, хәзерге Урта Әләзән җирләрендә, әйткәнебезчә, борынгы заманнан, Идел буе Болгарстаны, Алтын Урда дәүләтләре чорында ук халкыбыз яшәгән. Моны 1886 елда авыл янындагы урманны чистартканда Нәҗметдин һәм Фазлетдин исемле крестьяннарның XIV гасырга нисбәтле Җучи Олысы тәңкәләре табуы дәлилли. Тәңкәләргә Җанибәк, Мөхәммәт, Әбүбәкер ханнарның исемнәре сугылган була. Әмма соңрак, алда әйтелгән сәбәпләр аркасында, бу җирләр бушап кала. Өч гасыр чамасы вакыт узгач, бирегә яңадан кемнәр һәм кайчан килеп төпләнүен дәлилләүче документ Россия дәүләт борынгы актлар архивында саклана. Чыганакта 1681 елның сентябрендә Төмән (урыс чыганакларында Темников) һәм Саранск өязләрендә яшәүче морза һәм йомышлы татарларга, дәүләткә тугры һәм намуслы хезмәт иткәннәре өчен, Сура, Әләзән, Уза һәм Кадада елгалары буеннан болын һәм тугайлыклар, урман бүләк итеп бирелгәне, элек бу җирләрдә кеше яшәмәгәнлеге турында язылган. Документта хәзерге көндә дә авылда яшәүче кайбер нәселләрнең – Бәйбарсов, Дулатов, Бичурин, Ходайбирдин, Чумаев, Тугушев, Борнашев, Байгузин һәм башкаларның борынгы бабалары телгә алына. Шуңа нигезләнеп, без, Урта Әләзән авылына моннан 336 ел элек нигез салынган, дип әйтә алабыз.

Дөрес, морзаларның, мәсәлән, Әлмәмәт морза Дулатовның Әләзәндә җир алганчы ук Төмән һәм Кадом өязләрендә, ә Арслан Акбулатовның Саранск өязендә биләмәләре булган. Ә кайберләренең, мәсәлән, Мостай Кормашев һәм Бикчура Булатовларның Әләзәнгә килгәнче җирләре булмаган. Күп очракта йомышлы кешеләр буш җирне төзелеп килә торган шәһәр яны, саклану чигенең аргы ягыннан үзләре табып, бу турыда гаризада белдергәннәр. Йомышлыларның җир буенча үтенечләре нигездә канәгатьләндерелгән һәм бу дәүләт өчен дә файдалы булган, чөнки татарлар буш җирләргә – ныгытылган линия белән дала чигенә килеп урнашып, стратегик яктан мөһим вазифа үтәгән – көньяктан һөҗүм итә торган дошманнардан Россияне саклау өчен «тере стена» булып торган. Бу елларда Пенза төбәгенә, аеруча Уза һәм Кадада елгалары буенда яшәүчеләргә нугай, калмык, азов һәм кырым татарлары даими рәвештә һөҗүм итеп, авылларны талап һәм халкын әсир итеп алып китә торган булган. Шунлыктан, бирегә яшәү гаять куркыныч, дип саналган. Мисал өчен, 1680 елда Кырым ханы Сәлимгәрәй улы Дәүләткәр җитәкчелегендәге 4 меңлек азов татары, калмык һәм нугайлардан торган гаскәр Пенза тарафына һөҗүм итеп, күп кешеләрне әсир иткән. 1708 елның язында дала халкы яңадан чик буена һөҗүм итеп, Югары һәм Түбән Лом өязләрендәге авылларны талый. 1717 елның җәендә исә Кубань буенда яшәүчеләр, Петровск һәм Пенза крепостьларын камап алып, өязләргә һөҗүм итә, 216 торак пунктны туздыра һәм халкын талый. Әләзән авылы кергән Уза ыстаныннан гына да 8994 кешене әсирлеккә төшерәләр. Бу һөҗүм нәтиҗәсендә Пенза төбәгенең көньяк өлеше, шул исәптән татар авыллары да көлгә әйләндерелә.

Икенчедән, йомышлы татарларга җир биреп, Мәскәү хакимияте үзенә карата рус булмаган халыкларда уңай мөнәсәбәт тудырган. Җирнең күләме йомышлы татарның дәрәҗәсенә бәйле рәвештә тәкъдим ителгән. Офицерлар – йөзбашы һәм иллебашларга 45 гектардан

120 гектарга кадәр, атлы казакларга – 18 гектар чамасы, җәяүле казакка – 9 гектар, ә инде воевода һәм морзаларга иң зур мәйдан – 100-150 гектар җир бирелгән.

Архив документында: «Патшаның 1682 елгы фәрманы буенча, татар җирләрен рус кешеләренә бирү тыела», – дип язылган. Әлӛзән авылына беренче килеп төпләнүчеләр – морзалар һәм йомышлы кешеләр күп очракта үз җирләрен кечкенә кишәрлекләргә бүлеп, башка татарларга да саткан.

XVIII гасыр башында Әлӛзәннән көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш юнәлештә – хәзерге Пенза өлкәсенең Кузнецк, Сосновоборск, Неверкино һәм Лопатино районнарында да татар авыллары барлыкка килә.

«ЧАБАТАЛЫ МОРЗАЛАР»

XVIII гасырның азагыннан башлап йомышлылар сословиесе акрынлап бетерелә. Ә инде XVIII гасыр башында ук Урта Әлӛзән һәм Уза-Кадада елгалары буендагы җирләргә татарларның килеп төпләнүе төгәлләнә, халыкның Саратов далаларына, Самара, башкорт якларына күченү процессы башлана. Көньяктагы дала халкы һөҗүменнән тынычланып калган төбәкнең уңдырышлы җир-сулары урыс алпавытлары һәм монастырь әһелләренең күзен кызыктыра. 1719 елгы халык санын теркәү мәгълүматларына караганда, Уза һәм Кадада елгалары буендагы күп кенә урыс авыллары алпавытныкы булган, алар әкренләп Әлӛзән янындагы җирләрне дә тартып алган. Әйтик, алпавыт Жедренский Елшанка, Вершаут авылларына һәм Әлӛзән янындагы урманга ия булган.

Татар җирләрен тартып алу XVIII гасыр дәвамында тагын да көчәйгән. Алпавыт һәм түрәләрнең чамасыз кылануы әлӛзәнлеләрнең хәлен шактый мөшкелләндергән. Шуның өстенә, төрле салымнарның күләме дә арта. 1730 елдан башлап 83,5 хуҗалык бөтен-кирәк яраклары белән бер рекрут бирергә тиеш була.

1713 елда Петр Iнең татар морзаларын ярты ел эчендә чукындырып бетерү, чукынмаган очракта аларның җирләрен керстьяннары белән тартып алып, патша карамагына тапшыру турындагы фәрманы басылып чыга. Бу фәрман чукынырга теләмәгән Әлӛзән морзаларына зур зыян сала. Алар, дин исламга тугры калып, крестьяннарыннан аерыла, хуҗалыклары тарая, шулай итеп, бер өлеше сәүдә белән шөгыльләнә башлый. Пенза төбәгендәге 50 мең чамасы татардан ел саен нибары 2-3 кеше генә чукынган. Морза һәм крестьяннарның бер өлеше, туган җирләрен ташлап, Урта Азиягә качкан.

1784 елдагы Әби патша фәрманы буенча, морза нәселеннән булган мөселманнар, үзләренең империягә тугрылыкларын исбатлый алсалар, рус дворяннары белән бер хокукка һәм өстенлеккә ия булганнар. Бу фәрман Әлӛзән халкына да турыдантуры кагылган. Аларның күбесе сәүдә белән шөгыльләнсә дә, үзләренең морза нәселеннән булуын онытмаган. Шулай итеп, Урта Әлӛзән авылында яшәүче Агишев, Багдалов, Байгулдин, Бәхтиев, Бахтехуҗин, Бәйбарс, Бикмаев, Дашкин, Дебердиев, Дәүләтов, Курамшин, Надыршин, Тугушев, Уразов, Ханбиков, Якупов фамилияле морзалар, үзләренең элеккеге өстенлек һәм дәрәҗәләрен кире кайтаруларын сорап, Дворяннар җыенына гариза яза. Әмма алар моңа ирешә алганнармы, юкмы – бу турыда без белмибез. XIX гасыр-XX йөз башы Саратов губернасы Дворяннары җыенында әлӛзәнлеләрнең фамилияләре күренми. Моңа объектив – янгыннар һәм башка төрле бәла-казалар вакытында документларның юкка чыгуы, бюрократия шартларында дәүләт оешмаларыннан тиешле дәлилләрне табып булмау һәм субъектив – христиан диненен кабул итмәгән татар кенәзләре һәм морзаларының балаларына хакимият тарафыннан гадел булмаган мөнәсәбәт тә сәбәп булгандыр, мөгаен.

XVIII гасырның ахырыннан халык саны, шуның белән бергә аз җирле яки җирләре бөтенләй булмаган игенчеләр арта башлый. 1797 елгы фәрман буенча, хакимият җирсез крестьяннарга башка урыннарда, нигездә Идел яры буена – Хвалын, Вольск һәм Саратов


Книга записная входящимъ въ Саратовское наместническое правленіе о благородіи находящихся въ магометанскомъ законѣ мурзинскихъ и княжескихъ фамилій доношеніямъ.

Месецъ Июль

Әләзәнлеләрнең морза нәселеннән булуын дәлилләүче документ

өязләреннән җир тәкъдим итә. Кузнецк өязенең барлык татар авылларыннан да яңа җирләргә күченеп китәргә теләүчеләр шактый күп була. Шулай итеп, 1820 нче елларда Урта һәм Түбән Әләзән авылыннан якынча 150 гаилә Иделнең икенче ягындагы Яңа Әләзән авылына нигез сала. Аның тирәсендә тагын Сосновый Гай һәм Яңа Пәндәлкә исемле татар авыллары да барлыкка килә. Әләзәнлеләрнең бер өлеше тагын да көньяккарак китә. Хәзерге Волгоград өлкәсенең Ленин һәм Ставрополь районнарындагы татар авылларына да халык нигездә Пенза һәм Саратов губерналарыннан килеп төпләнгән. Шулай ук Әстерхан, Бакы, Ростов, Мәскәү һәм Петербург калаларына да күчеп китүчеләр күп булган.

РЕКРУТ ЙӨКЛӘМӘСЕ

Урта Әләзән халкы авыр рекрут йөкләмәсеннән мөмкин булганча качарга тырышкан. Моңа рекрутларның озак елларга сузылган хезмәт срогын тотып, бик азының гына туган җирләренә кире әйләнеп кайтуы, икенчедән, татар солдатының гаскәргә алынгач чукынудан куркуы – төп сәбәп. Шуның өстенә, Урта Идел һәм Урал буе татарлары хәрби хезмәткә Балтыйк буена, флотка яки туган җирләреннән шактый ерак төбәкләргә җибәрелгән. Шул сәбәпле, хезмәткә сәләтле егетләр Әстерхан ягына һәм башкорт, казакъ далаларына чыгып качкан. Булдыра алганнары сәүдәгәр сословиесенә языпып, үз балаларын рекрутлыктан коткарып калган.

Безнең мирас №6 июнь 2017

Рекрутлыктан котылуның башка, канунлы юлы да булган: әти-әни үз баласы өчен акча түләп, хезмәт итәр өчен, башка гаиләдән яки авылдан яшь егетне яллаган. Андыйларга «рекрут өчен түләү квитанциясе» бирелгән. Әләзән авылына бәйле шундый документларның берсе Саратов дәүләт архивында саклана. Анда 1866 елның 15 июнендә Саратов губернасының Кузнецк өязендәге Урта Әләзән авылының дәүләт крестьяны Салих Дашкинның үз урынына 22 яшьлек урыс егете Дмитрий Сморинны рекрут итеп җибәрүе турында язылган. Шуның өстенә, Дашкинның гаиләсе казнага кием-салым өчен 11 сум 5 тиен, азык-төлек өчен 8 сум 38 тиен, хезмәт хакы өчен 90 тиен, барлыгы 20 сум 33 тиен акча да түләгән.

Әмма әләзәнлеләрнең күбесе, йомышлы татарларда күптәннән килгән традиция буенча, Ватанга хезмәт иткән. Шундый мөхтәрәм ир-атларның берсе – Хөсәен Вәли улы Әбүзәров. Улы Габбасның сүзләренә караганда, ул XIX гасыр азагында биш ел буе Варшавадагы гусар полкында хәрби хезмәттә булган, соңрак Беренче Бөтендөнья сугышында катнашкан. Аның нәселен бүген дә «гусарлар» дип атап йөртәләр.

СӘҮДӘ ҺӘМ КӘСЕП

XVIII гасырның икенче яртысыннан, Россия белән Урта Азия арадашчысы буларак, татарларның сәүдә капиталы зур үсешкә ирешә. Самара өлкәсенең дәүләт архивында Әләзән халкының сәүдә эшенә осталыгын исбатлаучы бер документ саклана. «1835 елның 17 июлендә бертуган Сапожниковлар фирмасы татар сәүдәгәре Габдерәшит Баишев белән сәүдә килешүе төзи. Баишев тарафыннан Сапожниковлардан һәр поты 10 сумнан пычрак, юылмаган 2 мең пот (32 тонна) сарык йоны сатып алына. Әләзән сәүдәгәре Баишев 2 мең сум, ә аннары 8 мең сум акча калдыра», – дип теркәлгән әлеге чыганакта. Барлыгы ун мең сум! Бу сумма аванс буларак кына кертелгән, ә инде тулы исәп-хисап көзен, йон тулысынча җыелып беткәннән соң гына ясалган. Шуннан килешүнең гомуми суммасы 18-20 мең сум булган, дип чамаларга мөмкин. Дөрес, мондый килешүләр сәүдәгәрләр арасында гадәти хәл булган. Әмма безнең өчен Урта Әләзән бае Габдерәшит Баишевның шул чорда шактый зур акча – ун мең сумны аванс итеп калдыра алуы әһәмияткә ия. Мәгълүм ки, ун мең сум акчасы булган байлар I гильдия сәүдәгәр, дип саналган, аларның мал-мөлкәте, яшәү рәвеше һәм җәмгыятькә йогынтысы хәлле дворяннарныкыннан әллә ни аерылмаган. Шуны да искәртик: Саратов һәм Пенза губерналарында мондый бай сәүдәгәрләр


Конторѣ Коммерціи Совѣтника Сапожникова,
торгующаго подъ фирмою Братьевъ Сапожни-
ковыхъ я нижеподписавшійся Кузнецкой ку-
пецъ изъ Татаръ Абдрашитъ Хамидовъ
Баишевъ, далъ сію торговую запись въ томъ,
что куплено мною у него Сапожникова собран-
ной по рѣкѣ Иргизу овечьей русской шерсти
грязной, немытой, каковая у него въ сборѣ
имѣется отъ тысяча восемь сотъ до
двухъ тысячъ пудъ, цѣною за пудъ по
десяти рублей на монету; каковую шерсть
принять я при заведеніяхъ его на ху-
торѣ деревни Посека Кашповскаго; вышло
слѣдующей за сіе количество суммы денегъ,
имѣю взнести я въ его контору при яв-
кѣ моей къ пріему шерсти къ отдачѣ
уже мною въ задатокъ Двухъ тыся-
чамъ рублямъ еще Восемь тысячъ
рублей; а остальные за [illegible] обязанъ
додать по расчету за принятое количество
по окончаніи пріема [illegible] шерсти [illegible]

Г.Баишевның бертуган Сапожниковлар белән сәүдә итешүе турында документ

XVIII гасыр-XX йөз башында Урта Әләзәндә халык саны

	1795	1839	1865	1902	1911	1926
Ирләр	778	985	899	1633	1779	2122
Хатын-кызлар	1005	1018	899	1619	1865	2128
Барлыгы	1783	2003	1798	3352	3644	4250
Хуҗалыклар	310	331	287	529	626	770

Урта Әләзән авылы

берничә генә булган. Саратов губернасы буенча төзелгән «Россия империясенең торак пунктлары исемлеге»ндә әләзәнлеләр турында: «Өязнең бу һәм аның тирә-ягындагы татар авылларында яшәүче халык җир эшкәртү белән шөгыльләнә, әмма алар сәүдә эшенә күпкә һәвәсрәк һәм биредә, үзләренең спекуляцияләре белән, көнбатыш һәм Новороссия губерналарында яһүдләр уйнаган кебек рольне башкаралар», – дип язылган. Аңлашыла ки, бу чорда спекуляция сүзе совет чорындагы кебек тискәре мәгънәне белдерми, ә киресенчә, моның белән түрәләр татар халкының сәүдә эшендә уңышлы эшләвен, бер үк вакытта шактый ук хәйләкәр һәм оста булуларын күрсәтергә теләгәннәр.

Тарихи документларда кайбер әләзәнлеләрнең, үз җирләрен эшкәртүләре өстенә, Попов һәм Жедринский кебек алпавытларга да үз кораллары, аеруча тимер сука белән барып эшләүләре языла. Шулай ук җөен 140лап кешенең Иделнең аргы ягындагы эре промыселларда һәм кыр эшләрендә хезмәт итүләре мәгълүм. Гомумән алганда, җир аз һәм бурычлар күп булу сәбәпле, Кузнецк өязенең 8,5 процент крестьяннары Саратов, Әстерхан, Оренбург далаларына һәм Бакы шәһәренә китеп, сезонлы эшкә ялланган. Күп балалы гаиләләрдән ир кеше гадәттә июнь-август айларында, ягъни печән өсте һәм урак вакытында читкә барып эшләп, 50-60 сум акча алып кайта алган. Ә кечкенә гаиләнең башлыгы бары тик урак өсте вакытында гына читкә китеп, бер-ике ай дәвамында 25-30 сум акча эшләгән. Әләзәнлеләр тапкан акчаларын үз хуҗалыкларына сарыф иткән – җирне арендалаган өчен түләгән, орлык, эш кораллары һәм терлек сатып алган.

***

Гомумән алганда, Урта Әләзән авылы халкы уртак Ватаныбыз Россиягә тугры һәм намуслы хезмәт иткән, илгә афәт килгәндә аны яклап батырларча көрәшкән. Илләр, җирләр имин вакытта тырыш һәм хезмәт сөючән халык җир эшкәртү, иген игү һәм, әлбәттә, бик теләп сәүдә эше белән шөгыльләнгән. Урта Әләзән халкы кайда гына яшәмәсен, үз туган җирен, нигезен, нәсел-нәсәбен онытмаган. Гасырлар дәвамында нигез салынган традицияләр XX гасырда да дәвам иткән һәм әләзәнлеләр хәзер дә сәүдә-кәсеп эшендә зур уңышларга ирешәләр. ■

Пенза өлкәсенең Урта Әләзән авылы – Россия Федерациясендәге иң зур татар саласы: 2011 елда монда 9372 кеше яшәгән. Архив материаллары аңа 1681 елда татар морзалары нигез салган, дип күрсәтә. Җитмешенче елларда ул «Әләзән» миллионер совхозы буларак таныла, Германия белән Голландиягә кипкән суган сатып, СССРга валюта кертә. Совет иле таркалып, совхозлар илкүләм бөлгәндә дә Урта Әләзән аягында басып кала, җәһәт кенә базар икътисадына яраклаша. Тора-бара дүрт май сыгу заводы, хәләл продукция җитештерә торган колбаса цехы, тегермән, пилорама, агач эшкәртү остаханәсе, автосервис, ике стоматология кабинеты, компьютер клубы, такси паркы, фитнес-үзәк төзелә. Бүгенге демографик күрсәткечләр шаккатырырлык: биредә туучылар саны үлүчеләр санына караганда ике мәртәбә артык. Елына уртача 80 гаилә корыла, 3 гаилә таркала, 120гә якын бала туа, 60 кеше бакыйлыкка күчә[1].

Урта Әләзәннең тагын бер кызыклы ягы бар: монда икътисади үсеш белән югары дәрәҗәдә исламлашу бергә үрелгән, ул – автоном (ягъни милли республикадан читтәге) исламлашу үрнәге булып тора. Авыл төбәк татарларының дини үзәге дә. Биредә һәрдаим Пенза өлкәсе мөселманнары корылтае уза. Россиянең төрле төбәгендә эшләгән сигез мөфти шушы саладан чыккан.

2006 елда миңа Урта Әләзәндә булырга, анда яшәп алырга, кешеләре белән аралашырга туры килде. Бу авыл чын-чынлап гаҗәпләндерде: җирле халык, традицияләргә тугры калган хәлдә, иҗтимагый яктан актив, базар икътисадына җиңел яраклашкан һәм иң мөһиме – боларның нигезендә... ислам кыйммәтләре ята булып чыкты. Мөгаен, бу феноменны, гомумиләштереп, «ислам протестантизмы» дип атарга мөмкиндер. Аның нигезендә хезмәт, гаилә һәм иман ята.

Әләзән утравы

Лилия Сәгыйтова

ХЕЗМӘТ

Совет авылы кичергән фаҗигаләр, билгеле, Урта Әләзәнне дә читләтеп үтмәгән: хәлле крестьяннар үз вакытында монда да таланган, атылган, сөрелгән. Халык хәтерләгәнчә, күмәкләштерү бик авыр барган . Егерменче еллар азагына авылда 500 крестьян хуҗалыгы булган. Аларның йөздән артыгы – таза тормышта яшәгән, һәрберсе 2-3 ат тоткан, эш кораллары, кирәк-яраклары иң яхшылардан саналган. Ярлылар авылда азчылыкны тәшкил иткән. Колхозга керүчеләр икътисади яктан зәгыйфь булган: егерменче елларда 35 хуҗалыкны берләштергән күмәк хуҗалык нибары 9 ат асраган.

Үзәкләштерелгән совет икътисады чорында әләзәнлеләр дәүләт хезмәтендә (совхозда) эшләүдән тыш та акча юнәтү юлын эзләгән. Әләзән туфрагы иген үстерер өчен кулай түгел, ләкин халык, алда аталганча, моннан чыгу юлын җиңел тапкан: җитмешенче еллардан башлап суган үстерә башлаган. Үсемлекчелек һәм терлекчелек тармагында совет җәмгыяте өчен гайре табигый тоелган хезмәт төре – гаилә әртиле киң җәелгән. Сәнәгать яхшы үсеш алган – авылда

[1] Марданов Р.Т., Китаева Н.В. Средняя Елюзань: страницы истории самого крупного села России. – Казань: Татарское книжное издательство, 2006. – С.6.

[2] Шунда ук.

BABY

Пенза сәгать заводы филиалы, аяк киеме, электролампа җитештерү, тегү цехлары эшләгән. Шулай ук, халык үзенең ярдәмче хуҗалыкларыннан да табыш алган. Бригадаларга оешып, читкә китеп төзелештә эшләү, «сәүдә кору» гадәткә кергән, ягъни үзеннән артып калган продукцияне сатуга чыгарган. Ул вакытта бу эш спекуляция турындагы маддәгә туры килгән. Өлкән яштәге кешеләрнең ит яисә бәрәңге сатам, дип милициядән качып йөрүләре – детектив әсәргә торырлык. Альтернатив икътисад серләренә шул рәвешле төшенүе Урта Әләзән халкына авыр туксанынчы елларда коелып төшмәскә ярдәм иткәндер дә, мөгаен: асрый алмыйча, малын суярга мәҗбүр булган күрше-тирә колхозлардан арзан бәягә ит алып, аны зуррак бәягә сата башлаган алар; ватык авыл хуҗалыгы инвентарен төзәтеп-төзекләндереп, аны да яңа хуҗаларга «тапшырганнар». Күп гаилә шул юл белән ярыйсы гына байлык туплаган, йөк машиналары сатып алган. Озакламый ирләр «дальнобойщик» булып киткән яисә уңыш җыеп алу вакытында төрле хуҗалыкларда эшләп, гаиләсен туендырган. Бу һөнәр монда бүгенгәчә популяр: авылда 1500 йөк машинасы һәм 400 җиңел машина исәпләнә.

Алга таба тәкъдим ителәсе мәгълүматлар икътисади актив әләзәнленең гадәти биографиясен чагылдыра: *«Әти миңа йорт салды. Күршеләр булышты. Без дә аларга булышырга йөрдек... Шабашкага йөрдем, шофер булып эшләдем, йөк, төрле товар ташыдым, алыпсатар булдым. Товарыңны бушатып кайтуга, өйдәге эш көтеп тора иде. Урманга утынга барырга кирәк. Ике машина (сүз йөк машинасы турында бара. – Л.С.) алып кайтасың да аннары шуны ярасың. Аннары мал карыйсың. Ике үгез бар иде. Без башка чыккач, әти-әни биргән иде аларны. Кечкенә улыбыз да бар иде әле. <...> Хатын да эшләде, тегү цехында. Мин хәләл көч түгеп кенә акча таптым: печән чаптым, машинада йөк ташыдым. Мәсәлән, Кузнецкидан бер машина арзанлы кирпеч сатып алам да (сарай төзер өчен), бер өлешен авылдашларга сатам. Үз-үзен аклый. Шулай итеп, 26 метрга 5 метрлы сарай салдым, чардагы – печәнлек булды. Мунча җиткердем. Шулвакыт властька Ельцин килде, ике ел эчендә совет властен юкка чыгарачак, дигән сүзләр йөри башлады. Эш бетте. Кешеләрне эштән куарга тотындылар. Бу 1995-1997 еллар иде. Мин ул вакытта автохуҗалыктан машина алып торган идем. Сарапулдан бәрәңге алып кайта идем. Унбер рейс ясадым. Һәр рейстан 200 сум үземә калды. Шул рәвешле 1500-2000 сум акча эшләдем. Аннары эшмәкәрлеккә күчтем. Миңа эшмәкәр булырга киңәш бирделәр. Барып чыкса – эшләрсең, булдыра алмасаң – аннулировать итәрсең, диделәр. Шулай китте инде. Бер ел машинада йөрдем. Совет чорында товар аз иде, сайлау мөмкинлеге күп түгел. Без товар кайтарабыз да, кеше теләгән нәрсәсен ала. Шулай итеп бер елдан «Жигули»лы булдым. <...> Сарай бар, йорт бар – барысы да бар. Улым үсте. Иске йортны сүтеп, кибет төзедек».* (Ир-ат, 59 яшь.)

Дотациядә утырган совет колхозларыннан аермалы буларак, Урта Әләзәндә социаль инфраструктура да халык хисабына, ягъни совхоз үзе эшләп тапкан акчага корылган: хастаханә, мәктәп, клуб, универмаг, куян фермасы, теплица һ.б.

ГАИЛӘ

Урта Әләзән халкында өлкәннәргә карата ихтирам зур. Абыйдан алдан энеләр өйләнми, ападан алдан сеңелләр кияүгә чыкмый. Яшь пар ир-ат яисә аның әти-әнисе йортында яши. Бу «канун»нан тайпылу хурлык санала. Төпчек малай төп йортта кала, әти-әнисен карый. Өлкән малайларга ата-ана йорт салып бирә. Бер яшь хатынның хатирәләренә колак салыйк: *«Ничек тәрбияләндемме? Катгый гореф-гадәтләргә нигезләнгән гаиләдә. Әтинең күзенә туры карарга курка идем. Дискотекага йөрми идек. Урамга чыгып кич утырулар гына булды. Искечә тәрбияләндек инде. Әни сүзеннән*

чыкмадык. Кыска итәк кимәдек. Чалбар да кимәдек. Мәктәптә – мәктәп формасы иде. Хәзер барысы да үзгәчәрәк...»

Авылда әлегәчә кыз урлау гадәте яши. Нигездә, бу эш яшьләр зурлап туй уздырырга теләмәгәндә, ике як үзара килешеп башкарыла. Гаилә корганда никах беренче урында тора: *«Никах укып ярты ел узгач кына, ЗАГСка бардык. Бездә, гадәттә, никахны бала тугач кына рәсмиләштерәләр».* (Хатын-кыз, 28 яшь.)

Күп яшьләр, шәһәргә укырга китүгә карамастан, тиң ярларын үз туган авылыннан табарга тырыша. Читтә төпләнеп калганнар кече ватанында йорт салырга һәм өлкәнәйгәч, һичшиксез, шунда кайтып төпләнергә ниятли: *«Мәгънәсе гади аның – монда тудым, монда минем әти-әни. Бабам монда, аның бабасы монда. Кайда гына йөрсәм дә, барыбер үләргә монда кайтачакмын. Башкалар да шулай. Мәскәүдә яши, Әләзәндә йорт сала. Чаллы шәһәрендә Ринат исемле эшкуар бар. <...> Самара-Мәскәү юлында кибетләре урнашкан. Самарада – КамАЗ кибете. Һәр йөз чакрым саен йорт күтәрә. Ул – Чаллыда иң зур эшкуарлардан, завод карамагындагы цехы бар. Чыгышы белән Әләзәннеке. Менә ул да Әләзәндә йорт салды – бик шәп йорт салды. Безнең халыкның канына сеңгән инде: әти-әни янына, туган җиргә кайтырга телибез. Канга сеңгән: туган җиргә кайтып үләргә кирәк. Яшәгән җирендә яшәр, пенсиягә чыгар, соңгы көннәрен монда кайтып уздырыр...»* (Ир-ат, 39 яшь.)

ИСЛАМ

Күп авыллардан аермалы буларак, Урта Әләзән халкы совет чорында да инкыйлабка кадәр эшләгән мәчетләрен саклап кала алган. Тыюларга карамастан, Аллаһ йорты ябылмаган, кешеләр дини йолалардан ваз кичмәгән. Хәтта совет мәктәбендә белем эстәгән укучылар да ураза тоткан. Тәкъдим ителәсе нарратив бу гамәл (совет идеологиясенә каршы тору) нигезендә дини инану ятуын күрсәтә: *«Кечкенә чакта ураза тотмадым. Алтынчы-җиденче сыйныфтан тота башладым. Башта бер көн тотам, бер көн тотмый идем. Җиңелрәк булсын өчен. Без пионерлар идек. Ләкин Рамазан аенда галстук такмадык – гөнаһ санадык. <...> Галстукны салган өчен сыйныфыбыз белән куып чыгардылар. Ник салдыгыз, дип ачуландылар. Кызыл галстук тагу – гөнаһ, дидек. Кемдер күреп ачуланганчы – саласың, ачулансалар – тагасың инде. Шулай иттек. Малайлар такмады. Без (кызлар. – Л.С.) курыкканга күрә тага идек».* (Хатын-кыз, 28 яшь.)

Бүген, җәмгыятьтә исламның роле арткан көндә, Урта Әләзән халкы мөселман кыйммәтләрен тагын да якынрак, үз күрә. Ислам кануннары, рухи яшәештән тыш, икътисади һәм иҗтимагый яшәешкә дә үтеп керә: *«Безнең кибет бар. Анда төрле кирәк-ярак, хуҗалык товарлары сатабыз. Исерткеч эчемлекләр юк, дөрес, әлегә тәмәке бар, ләкин озакламый аны да сатудан туктарга җыенабыз, чөнки – гөнаһ. Безгә дә, сатып алучыларга да. Аннан кергән акча да – пычрак табыш. Без аны хәрәм күрәбез».* (Ир-ат, 59 яшь.)

Авылда дуңгыз ите сатылмый, берничә колбаса цехы эшли, анда сыер һәм ат итеннән генә продукция җитештерелә. Хәләл азык-төлек Татарстанга, Мәскәүгә, Самарага, Саратовка чыгарып сатыла.

Урта Әләзән халкы белән сөйләшкәндә шунысы ачык сизелә: монда кеше үзен җәмгыять алдында җаваплы тоя. Җаваплылык хисе гаиләдән башлана: әүвәл әти-әни балаларын ничек тә кеше итәргә тырыша, аннары балалары аларны кадер-хөрмәттә яшәтә. Мәчетләр, муллалар – барысы да халык хисабына көн итә. Хәлле әләзәнлеләр ярлы авылдашларына һәм матди, һәм рухи ярдәм күрсәтергә атлыгып тора. Авыл үсә, баеый, матурлана.

Алай да яшәп була икән.

Текстны журналга
***Миләүшә Талипова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

Төркиядәге татар генералы – Мөхәммәтшакир Яваев.

КЫШКАР МӘДРӘСӘСЕ ШӘКЕРТЕ – ГОСМАНЛЫ ГЕНЕРАЛЫ

Ирек Биккинин, Азат Ахунов

Пенза губернасыннан чыккан мәшһүр татар генералы Мөхәммәтшакир Мөхәммәтшәриф улы Яваевның язмышы җәнҗаллы вакыйгаларга гаять бай, аның турында хәтта фильм төшерергә дә мөмкин булыр иде.

Мөхәммәтшакир Чембар өязе, Мочали волостеның Качкару авылында туган. Әтисе Мөхәммәтшәриф Яваев туган авылында мулла хезмәтен башкара. Авылдашлары гына түгел, тирә-як мөселманнары да ил картын ислам динен төпле белгәне өчен хөрмәт итә, аңа киңәш һәм ярдәм сорап килә. Үз мәхәлләсендә ул казый вазифасын башкара, Коръән-хафиз булып таныла, моннан тыш, үләннәр белән дәвалау куәтенә ия, кешеләрнең авыруын һәм күңел хәсрәтен сүрә-аятьләр укып та юкка чыгара. Истәлекләргә караганда, Мөхәммәтшәриф экстрасенслык сәләтенә дә ия булып, каршында

торган кешенең физик һәм рухи халәтен бер карауда әйтеп биргән. Хәзрәтнең дүрт улы һәм бер кызы була, барлык балалары да дини гыйлем ала. Шакир исә Казан артындагы данлыклы Кышкар мәдрәсәсендә укый. Әти кеше зирәк һәм акыллы улын солдатка бирергә теләми һәм якындагы Петровка авылыннан бер егетне яллап, аңа зур суммада акча түли. Әмма егет хәйләкәр була, Мөхәммәтшакир укуын тәмамлап авылга кайтканчы ук, Петербургка чыгып кача.

Истәлекләр Мөхәммәтшакирның Кышкардан киң күкрәкле, таза бәдәнле (120 кг чамасы), зәңгәр күзле, чибәр, җитлеккән ир-егет булып кайтуы турында сөйли. Кайту белән, гаилә корып җибәрә, улы Хәсән туа.

1877 елның 24 апрелендә Россия Төркиягә, Болгария халкын төрек хәлифәте изүеннән коткару сылтавы белән, сугыш башлап җибәрә. Хәтәр еллар була бу. Төрекләр, илне дер селкетеп, һәркемнең шәхси тормышына тыкшынып, тирә-якны шпион-күзәтүчеләр белән чолгап алган «канлы» солтан Габделхәмит IIнең изүеннән җәфа чигә.

Сугыш башлану белән, тиз арада мобилизация игълан ителә һәм Мөхәммәтшакир армиягә алына. Башта ул Петербургтагы гвардия полкында хезмәт итә һәм бу армия, төрекләр Плевнаны штурмлап алгач, шунда юнәлә. Җәяүле сәфәр берничә айга сузылып, күп кенә хәрбиләр юлда төрле һәлакәт һәм авырудан вафат була. Плевна сугышы җиңел генә булмый. 7 июльдә 30 меңлек армиясе белән Осман паша да килгәч, вазгыять тагын да кискенләшә. Мөхәммәтшакир җиңелчә җәрәхәтләнә, әмма лазаретта калмый, «Ак генерал» Михаил Скоблевның армиясендә сугышуын дәвам итә. Август аенда рус отряды крепость эченә үтеп керә, әмма яулаган позицияләрен саклап кала алмый, күбесе әсир төшә. Алар арасында Мөхәммәтшакир Яваев та була.

Шулай итеп, татар егете Госманлы империясе биләмәсенә килеп эләгә. Иңбашы авыр җәрәхәтләнгән, башы канга баткан, пычрак чүпрәк белән уралган Мөхәммәтшакир зинданда уяна – сорау алу, авыр тән җәзалары башлана. Рус армиясенең гади генә солдаты булу сәбәпле, ул төрек офицерларының сорауларына җавап бирә алмый, шулай да үзен тәвәккәл, кыю һәм батыр итеп күрсәтә.

Безнең батырны ярты елдан соң

Плевна крепостен русларга бирү. Әсир төшкән Осман паша генерал Иван Ганецкийга кылыч тапшыра. С.Шамот рәсеме, Б.Браун гравюрасы

иреккә чыгаралар. Курку белмәс, белемле, эрудицияле, җитмәсә, чит телләрне, шул исәптән гарәп, фарсы һәм төрекчәне камил белүче татар госманлыларга, аеруча Осман паша күңеленә бик хуш килә. Нәтиҗәдә, Мөхәммәтшакирга төрек солтаны әләме астында хезмәт итәргә тәкъдим ясыйлар. Рус армиясенең кичәге солдатына ни эшләргә кала соң?! Артка юл ябык, кире кайтсаң, эзәрлекләү башланачак. Шул рәвешле, Мөхәммәтшакирның төрек армиясендәге карьерасы башлана, ул Осман паша гаскәренә хезмәткә күчә. Паша белән ул Плевна крепосте блокадасын өзәргә омтылып карый. Төрек генералы әсир төшә, Мөхәммәтшакир аз санлы отряд белән качып котыла. 1878 елның 31 гыйнварында рус армиясе Истанбулга кадәр барып җитә, март аенда исә, Сан-Стефан килешүе белән, сугыш тәмамлана.

Осман Нури-паша (1832-1900) – легендар шәхес. Зур хәрби җитәкче буларак, ул Кырым сугышында (1853-1856) актив катнаша. 1877-1878 еллардагы рус-төрек сугышы чорында исә Плевна оборонасын җитәкли, рус әсирлегеннән азат ителгәч, берничә мәртәбә Төркиянең хәрби министры итеп билгеләнә. Аның даны Төркиядән еракларга, шул исәптән татарларга да барып ирешә.

Әлеге хәрби башлык җитәкчелегендә Мөхәммәтшакир Яваев хезмәт баскычыннан бик тиз күтәрелә, аңа иң җаваплы хәрби бурычларны да ышанып тапшыралар. Ахыр чиктә ул дәүләтнең югары дәрәҗәсенә – төрек генералына кадәр үсә. Моны аның Төркиядәге карьерасының иң биек ноктасы, дип атарга була. Тарихта сакланган бер кызыклы факт бар. 1938 елгы сорау алу вакытында танылган татар галиме, дин эшлеклесе Әхмәтһади Максуди тикшерүчегә 1894 елда Төркиягә баргач, Константинопольдә милләте буенча татар булган өч төрек пашасы яшәве турында ишетүен әйтә. Бу инде төрек илендә мондый дәрәҗәгә Мөхәммәтшакир Яваев кына ирешмәгәнлеген сөйли. Гәрчә XIX гасыр ахырында теләсә кемне – азәрбайҗанны да, төрекмәнне дә, бигрәк тә Төркиядә һәрвакыт күпләп яшәгән кырым татарын да татар дип атаулары ихтимал.

Мөхәммәтшакир Яваевка өйләнеп кайтыйк. Төрек генералы үз ватанын онытмый, өенә хатлар яза, кыйммәтле посылкалар җибәрә, хатыны белән улы Хәсәнне Төркиягә чакыра, әмма тегеләре баш тарта. Моны алар Мөхәммәтшакирның ватанны ташлап киткәндә туганнары һәм гаиләсеннән рөхсәт сорап тормавы белән аңлаталар. Авылдашлары да аның бу гамәлен төрлечә бәяли: берәүләре, мөселман, төрки кавемнең бер вәкиле буларак, дөрес эшләде, дисә, икенчеләре исә сатлыкҗанлыкта гаепли.

Качкару урта мәктәбенең тарих укытучысы Арифулла абый Кайбелев сөйләвенә караганда, бертуганнары Мөхәммәтһади һәм Закир муллалар төрле вакытта Истанбулга барып, абыйлары Мөхәммәтшакирда кунак була, тормыш-көнкүреше белән кызыксына, аңа авыл һәм өяз хәбәрләрен җиткерә. Энесе Һадинең ялгыз калган җиңгәсенә өйләнгәнен белеп, пашаның кәефе кырыла. Әмма бу никах озын гомерле булмый, тиздән алар аерылыша. Закир мулла Төркиядән абыйсының фоторәсемен алып кайта. Аны Мөхәммәтшакирның оныгы Фатыйма хәзерге көнгә кадәр яшереп саклаган була. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китик: Фатыйма – авылның гаять укымышлы, зыялы хатыны, хуҗалыкларны күмәкләштерү чорының активисты буларак, зур эшләр башкарган шәхес. Кешеләрне дәвалау сәләтенә дә ия булган бу ханым, үзенең улы Сөләйман һәм аның хатыны Сафура гаиләсендә яшәп, бакый дөньяга күчә. Хәзерге көндә Качкару авылында Фатыйманың оныклары Рәмзия Ишмаметова белән Мярьям Белякова һәм башка туганнары яши.

1914 елда башланган Беренче Бөтендөнья сугышына Качкару авылыннан кырыктан артык кеше фронтка

Мөхәммәтшакирның этисе Мөхәммәтшәриф җирләнгән төрбә

китеп, шуларның яртысы һәлак була һәм әсирлеккә төшә. 1918 елда сугыш тәмамлангач, әсирләрне алмашу булмый, россиялеләр Германиядә кала. Ә Төркия белән Германия арасында бу турыда махсус килешү төзелеп, төрекләргә туган илгә кайту мөмкинлеге тудырыла. Ниндидер сәбәп табып булса кирәк, немецларга әсир төшкән Качкару егете Кәрим Чекуряев та төрекләр белән бергә, мөселман буларак, Төркиягә килеп эләгә. Ул, авылдашы Шакир пашаның төрек илендә зур хәрби дәрәҗәгә ия булганын белеп, аның йортын эзләп таба. Йорт янына килү белән сакчылар кулына эләккән Кәрим үзенең генералның авылдашы булуын аңлата. Бу турыда белеп алган Шакир паша: «Әгәр дә ул авылдашым икән, үзенең һәм ике як күршесенең исем-фамилияләрен язып миңа кертсен», – дип боера. Шулай итеп, генерал, авылдашы Кәримне кунак итә, аны Төркиядә калырга үгетли, әмма тегесе каршы килә. Шуннан соң Шакир паша аңа Россиягә кайтырга ярдәм итә.

Большевиклар хакимияте урнашкач, Төркия белән элемтә өзелә. Пенза төбәгенең Мочали авылыннан чыккан әсир бер солдат туган ватанына хәбәр сала. Хатында ул Качкару халкына авылдашлары Мөхәммәтшакир Яваевның Төркиядә вафаты турында белдерүләрен сорый. Шулай итеп, качкарулылар үзләренең данлыклы якташларының

үлеме турында белә. Илдә бу вакытта дәһшәтле Гражданнар сугышы бара...

1980 нчы елларда Үзәк телевидениедә Төркиянең хәрби башлыгы, атаклы шәхес Шакир паша Яваев турында тапшыру булды. Яваев авылдашларының кайберләре бу тапшыруны карый һәм якташлары белән горурлана алды.

***

Улы Мөхәммәтшакир армиягә алынгач, Мөхәммәтшәриф хәзрәт озак яшәми, фани дөньядан китә. Качкару авылының зиратында бер кабер башка мәрхүмнәрнекеннән аерылып тора – ул биек бура белән уратып алынган. Анда атаклы имам, мөхтәрәм шәхес Мөхәммәтшәриф Яваев җирләнгән. ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

АГУЛАНГАН МӘРЬЯМ БӘЕТЕ

Индус Сирматов

Мин бу бәетне беренче һәм соңгы тапкыр моннан 75 ел элек ишеткән идем. Яманаты чыккан кырык беренче елның көзе. Күршедәге Җылан авылында яшәүче Ифаза, Сөн аркылы чыгып, безгә килде. Безнең әткәйләр – Фатих һәм Хәниф – бертуганнар. Икесе дә сугышта. Әткәй, ул елда кайдадыр бозлы окопта ятып, үпкәсенә салкын тидереп, эче китеп, кышын өйгә кайтып егылды. Энесе Хәнифнең (Ифазаның әтисе) – безнең Шәкерт абзыкайның хәбәрсез югалуын соңрак белдек. Мондый кайгылы хәбәрләр, фаҗигале хәлләр ул чорда авылларга көн саен ишелеп-ишелеп килеп тора иде. Шуңадыр, кешеләрнең сөйләгән сүзләре дә, көйләгән көйләре, җырлаган җырлары да гел кайгылы, гел имәнеч була иде. Һәрхәлдә, минем хәтердә шулай калган. Әле дүрте тулып бишенче яше белән генә баручы мин – малай бу хәбәрләрне шулай булырга тиешле гадәти күренеш дип тә кабул иткәнмендер инде. Ә фаҗигалеләре исә, күңелне җәрәхәтләп, хәтер түренә мәңгелек кара таш булып кереп урнашкандыр. Әлеге килүендә Ифаза да шундыйларның берсен алып килгән иде. Миннән олырак булса да, әле алтысын гына тутырган кыз бала кемнән ишеткәндер, ничек хәтерендә калдыргандыр, шундый да озын «Агуланган Мәрьям бәете»н бер сулышта көйләп күрсәтте. Ифазадан азга гына олырак бертуган апам Лена, тагын җырла әле, дип кабат көйләтте. Ифаза каршы килмәде. Әмма апамның һаман-һаман соравы Ифазаны туйдырды, ахрысы.

– Әткәйләр өйдә юк, син һаман Мәрьямне җырлатасың, – дип каршы килде ул.

«Әткәйләр» дигән сүз апама да нык тәэсир итте бугай. Ул, башын иеп бераз басып торды да, пышылдап кына әйтеп куйды:

– Сугыш беткәч, әткәйләр кайта ул... Әнкәй шулай диде... Мәрьям дә кызганыч бит.

Аның тавышы пышылдау гына түгел, җәрәхәтле дә иде. Ифаза да апаның шушы халәтен аңладымы, башка сәбәпләре дә булдымы (сабый күңелен кем белсен!) – болдырның иң аскы баскычына утырды да, ике кулын ике тезе өстенә куеп, тынсыз калды.

– Бүтән сорама!..

Тагын бераздан ул көйли башлады. Ни өчендер аның барлык көйләүләренең шушы варианты истә калган. Тавышындагы сыкрану күңелемне әрнеткәнгәме, әллә, гадәттәгечә, кабатлауларның иң соңгысы хәтердә саклану бер табигый хәлме – әйтә алмыйм. Һәрхәлдә истә калганы болай:

Кич кояшлар баеганда,
Фабрикадан кайтканда
Агуланган Мәрьямкәйне
Илттеләр больницага.

Илттеләр дә больницага
Салдылар караватка;
Ике фельдшер, бер сестра
Килделәр коткарырга.

– Коткармагыз, коткармагыз,
Мин барыбер үләмен,
Дөньялыкта күрәчәгем
Как кабремдә күрәмен.

(Шуннан соңгы берничә куплет истән чыккан).

Беренче көнне әнисе
Килде хәлен белергә.
Аңа фельдшер җавап бирде:
– Мөмкин түгел керергә.

Икенче көнне әтисе
Килде хәлен белергә.
Аңа фельдшер җавап бирде:
– Мөмкин түгел күрергә.

Өченче көн хәл белергә
Килде аның Булаты.
Аңа фельдшер җавап бирде:
– Землянкада ята, – дип.

Монда тагын күп кенә строфа бар иде. Миңа бик үк аңлашылмый торган сүзләр булгангадыр, алары истә калмаган. Эчтәлекләре буенча болайрак булыр: ике гашыйк – Мәрьям белән Булатның фабрикада эшләүләре, икесенең дә хезмәт алдынгылары булып, әледән-әле бүләк алып торулары, икенче бер кызның да Булатка гашыйклыгы, Мәрьям чираттагы хөкүмәт бүләген алгач, теге кызның көнләшүенең соңгы чиккә җитүе һәм Мәрьям туклана торган «ысталауай өстәлендә» агу калдырып китүе. Фельдшер әйткәннән соң Булатның землянкага йөгереп төшүе турындагы куплет та истә калмаган, әмма Булатның землянка ишеген ачып керүе кинодагы кебек күз алдына килә. Безнең күрше авылда да бер гаилә землянкада яши иде.

Ач күзеңне, ач күзеңне,
Мәрьямкәй, ач күзеңне,
Әгәр ачмасаң күзеңне,
Әрәм итәм үземне.

Хәнҗәр шунда ялтырады,
Булат үзен чәнечте. (...)

Мәрьямкәйнең кара чәчен
Тасма белән үрделәр.
Булат белән Мәрьямкәйне
Бер кабергә күмделәр.

Күрәсез, бәетне тулысынча китерә алмадым. Ләкин мин моның өчен дүрт яшьлек малайны гаепләмим. Һәм бүген кулга каләм алуым да бөтенләй башка сәбәптән.

Рухи байлыгыбызның бер өлеше буларак, бәетләр – җыеп туплауга, ныклап өйрәнүгә һәм алдагы буыннарга җиткерүгә лаеклы әсәрләр. Алар «нигезендә кайгылы яисә көлкеле вакыйга» ятса да, бәетләр тормышыбызның төрле тармакларын, төрле якларын тасвирлыйлар, шул бәет чыгарылган чорның иҗтимагый хәлен сурәтлиләр. Бер бәетне искә төшереп кенә дә бер дәвернең тарихын күз алдына китерергә мөмкин.

Шулай ук кайбер бәетләр җәмгыятьнең нинди халәттә булуына бөтенләй бәйләнешсез рәвештә аерым бер шәхеснең фаҗигасен сөйләп бирәләр. Бусы әлеге

лиро-эпик жанрның икенче бер сыйфаты булса, алар икесе бергә бәйләнеп барган бәетләр дә бар.

Әйтик, рус-фрацуз сугышы бәетләре, XIX гасырдагы Ватан сугышының шактый тулы панорамасын яктыртып, иҗтимагый-сәяси мәьәләләргә кереп китсә, Мөхәммәтзәки бәете чабыш аты өстеннән егылып төшү сәбәпле вафат булган авыл егетенә бәйләнешле төстә туган-тумачаларының, дус-ишләренең кайгы-хәсрәтен шәхси планда бәян итә. Яки Лашман бәетләрендә күбесенчә мәгълүм бер заманда ирексез хезмәттән җәфа чиккән ир-атлар тормышы алгы планга куелса, җиде кыз бәетләрендә хатын-кызларның ирексезлеге, изелүе, михнәт чигүенә мөнәсәбәт белдерелә.

Сүз башындагы Мәрьям бәетенә әйләнеп кайтыйк. Бу бәет җәмгыятьнең халәте турында да, шул җәмгыятьтә яшәүче шәхесләр турында да мәгълүмат бирә, минемчә. Күрсәтелгән куплетларга караганда, бу бәхетсез ике гашыйкның, ике шәхеснең – Мәрьям белән Булатның фаҗигасе генә кебек: кыз агуланудан үлгән, ә чарасыз калган егет үзенә-үзе кул салган, үзен хәнҗәр белән чәнчегән. Сөйгән кызының үлеме үзенең дә үлеменә китергән егет турында матбугатта чыккан тагын бер генә бәет бар. Ул, «тәвәккәлләп суга кереп», суга баткан сөйгәне Гайшәне чумып-чумып эзләгән һәм үзе дә салкын суда вафат булган гашыйк Камил бәете. Бу бәет текстында кешеләрнең җәмгыять белән бәйләнеше сизелми, бу хәлнең кайсы чорга туры килүен күзаллавы да җиңел түгел.

Ә менә «Агуланган Мәрьям бәете»нең саран гына сүзләреннән дә вакыйганың кайчанрак һәм кайда барганлыгын күзаллап була. Бу – Бөгелмә, Бәләбәй кебек кечерәк шәһәрләрнең берсендәге хәл, чөнки татарлар тупланып эшли торган фабрика. Вакыйга совет чорында бара, чөнки ир-атлар һәм хатын-кызлар бер цехта (дөрес, цех сүзе телгә алынмый алынуын) эшлиләр, ярышта җиңеп чыгучылар әледән-әле хөкүмәт бүләкләре алып торалар. Ашханәсе (ысталауай) эшли торган фабрика да – совет чоры предприятиесе. Фабрикалы шәһәребез Казан, Уфа кебек әллә ни зур булмаска да тиеш. Чөнки больница дигәннәре дә медпункт кына, анда табиб юк, коткарырга килүчеләр дә «ике фельдшер, бер сестра» гына. Больница каршында морг та юк икән. Мәет «землянкада ята», дип кенә җавап бирәләр. Фабрикада эшләүчеләр тирә-як авыллардан җыелган яшьләр булырга тиеш, чөнки Мәрьямне күрергә әти-әниләре төрле көннәрдә чиратлап киләләр. Шәһәрдә булсалар, шул көнне үк уптым-илаһи килеп җитәрләр иде. Булат кына ни өчен өченче көнне генә килә алгандыр һәм бер чәнчүдә үтерерлек ялтырап торган хәнҗәрне каян алгандыр – җавап бирә алмыйм.

Шулай итеп, тулаем картинаны күз алдына китерү өчен, бәетнең тулы тексты белән танышу зарур. Ә аны кем хәтерли? Апам да, Ифаза да бакыйлыкта. Бәлки аларның яшьтәшләре яки ишетеп истә калдыручылар бардыр? Бәетнең башка варианты булу да мөмкин, чөнки халык иҗатында мондый күренеш еш күзәтелә.

Инде килеп, бу язманы укучыларга мөрәҗәгать итәсем килә: әгәр бәетнең тулы текстын, алай ук булмаса, минеке төсле истә калган өлешен генә булса да редакциягә җиткерсәгез, халкыбыз авыз иҗатының бер әсәре тупланыр иде. Бу исә, алдарак әйтелгәнчә, тарихыбызны, милли мирасыбызны өйрәнүдә кечерәк кенә бер сәхифә булыр иде.

Редакциядән: *Быел танылган язучы һәм журналист Индус Фатыйх улы Сирматовка 80 яшь тулды. Каләмдәшебезне гомер бәйрәме белән котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

ГОМУМРУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫ СЪЕЗДЫНЫҢ КАРАРЛАРЫ

1917 ел, 1-11 май

Моннан нәкъ йөз ел элек Россиядә зур вакыйга – Беренче Бөтенроссия мөселман съезды уза. Шул ук елны «башкаручы комитет» тарафыннан Мәскәү шәһәрендә корылтайның карарлары аерым җыентык булып басылып чыга. Игътибарыгызга өч кенә карарны тәкъдим итәбез, ә калганнарын beznenmiras.ru сайтыннан укырга мөмкин.

Бөтенрусия мөселманнары съезды 1917 елда Мәскәү шәһәрендә 1 майда ачылып, 11 майның төненә кадәр дәвам итте.

Съездга Русиянең төрле җирләреннән (шул җөмләдән Бохара һәм Хивадан) 830 кадәр вәкил килгән иде[1]. Съезд хакыйкатьтә Русиядәге бөтен Русия мөселманнарының гомуми съезды иде. Чөнки аңар катнашкан вәкилләр Идел буе, Сибирия, Кавказ, Кырым, Төркестан, Закаспий һәм Литва кебек мөселманнар тора торган бөтен урыннардан килгән иде. Бу съездга ислам динендә булган Русиядә яшәүче һәр кабилә үз вәкилләрен җибәргән иде. Миллият ягыннан грузин булган аҗәр мөселманнары вәкилләре булуы моңа ачык шаһид булса кирәк. Бу съездга халкымызның һәр сыйныфыннан – сәүдәгәр, крестьян (диһкан), эшче вә муллалардан, шулай ук фронттан килгән әфитсәр вә солдатлардан вәкилләр бар иде.

Съезд, үзенең мәҗлесләрен идарә итеп алып барыр өчен, беренче мәҗлестә бер риясәт (президиум) сайлады. Риясәт әгъзалары ошбу затлардан гыйбарәт иде: **Ибраһим Әхтәмов, Ильяс Алкин, Гаяз Исхакый, Гобәйдулла Хуҗаев, Хәлил Дусмөхәммәтов, Әхмәдбәк Салихов, Галимәрдән бәк Тупчыбашев, Фатих Кәрими, Сәлимә Ягъкуб кызы.**

Съезд өчен алдан «Вакытлы мәркәзи бюро» тарафыннан төзелгән программа бераз үзгәртелеп кабул ителде. Съездда каралып карар чыгарылган мәсьәләләр: **ысул идарә, дини вә милли мәсьәләләремезнең вакытлы тәшкиләте; мәдәният вә мәгариф эшләре; сугышка мөнәсәбәтебез; хатын-кыз мәсьәләсе; эшчеләр мәсьәләсе; йир-тупрак мәсьәләсе; мәмләкәтемездә мөселман гаскәрләренең тәшкиләте; ил корылтаена сайлау алды тактикасы; Русия мөселманнарының шурасын төзү һәм аңар әгъзалар сайлау.**

ЫСУЛ ИДАРӘ ХАКЫНДА

1) Русиядәге мөселман милләтләрнең мәнфәгатьләрен, хокукларын иң киң сурәттә тәэмин итә торган ысул идарә – туфрак (территория) һәм миллият нигезенә корылган халык җөмһүриятедер. Махсус җирләре булмаган милләтләр милли вә мәдәни мохтәрият белән файдаланырлар.

[1] Шуларның 122се – хатын-кыз.

2) Русиядәге мөселман милләтләренең рухани вә мәдәни мәсьәләрен тәртип илә алып бармак вә аларны иттифак илә хәрәкәт иттермәк өчен, гомуми Русия мөселманнары өчен бер мәркәзи оешма ясалыр һәм бу оешма үзенең карамагында улган (рухани-мәдәни) мәсьәләләрдә канун чыгару хокукына ия булыр.

МӘДӘНИЯТ ВӘ МӘГАРИФ ЭШЛӘРЕ ХАКЫНДА

1) Мәгариф һәм мәдәният эшләре һәр милләтнең үз идарәсендә булыр.

2) Һәрбер милләтнең үзе тарафыннан сайланып төзелгән оешмасы кулында булыр.

3) Ибтидаи мәктәпләрдә уку теле һәр кабиләнең үз ана телендә булыр. Урта мәктәпләрдә гомуми төрек телен дәрес итеп укыту мәҗбүри булыр. Гали мәктәпләрдә уку теле төрек-татар кабиләләре өчен гомуми булган төрек теле булыр.

4) Мәгълүм бер яшькә йиткән һәммә балалар өчен ибтидаи мәктәпләрдә уку гомуми, мәҗбүри һәм буш булыр.

5) Ибтидаи мәктәпләр бер генә типта булырлар, дини вә дөньявига аерылмаслар.

6) Мәктәпләремезнең төзелеше ибтидаи мәктәптән урта мәктәпкә, уртадан гали мәктәпләргә имтихансыз керерлек рәвештә булырлар.

7) Мәктәпләремездә рус теле бер тел ителеп кенә укытылыр.

8) Русиядә булган бөтен милләтләрнең укучы һәм укытучылары хокукта һәр җәһәттән тигез булырлар.

9) Һәрбер милләтнең мәдәният вә мәгариф өчен тотылачак чыгымнары дәүләт вә җирле идарәләр тарафыннан тәэмин ителер.

10) Милли урта мәктәпләребезне тәмам иткән шәкертләр рус гали мәктәпләренә имтихансыз керә алырлар.



Гомумрусия мөселманнары съездының карарлары. 1917 ел

11) Мәктәпләргә һәр авылда вә янарында иң кимендә алты дисәтинә йир бирелер.

12) Урынына карап, ир вә кыз балаларның бергә укулары матлубтыр.

13) Башка милләтләр мәктәбендә укучы мөселман балаларның саны сигезгә йитсә, хәзинә вә мәхәлли идарәләр хисабыннан, аларның үзләренә махсус дин вә ана теле мөгаллиме куелыр.

14) Дини мәдрәсәләр шул мәдрәсәләрнең һәят тәгълимияләре (укыту комиссияләре) һәм дини идарәләре нәзарәтендә булырлар.

15) Мөселманнар өчен ачылган хөкүмәт, шәһәр вә земство школалары һәм дә мәхәллә мәктәпләре 1917-1918 уку елының башыннан ук милли мәктәпкә әйләндерелер.

16) Мәктәпкә кадәр һәм мәктәптән тыш тәрбияне алып бару өчен милли оешмалар вә мөселман мәктәпләренә укытучылар йитештерү өчен дарелмөгаллимин[2] вә дарелмөгаллиматлар[3], тәгаллем вә тәрбия курслары ачылыр.

[2] Ир-атлардан укытучылар әзерли торган уку йорты.

[3] Хатын-кызлардан укытучылар әзерли торган уку йорты.

Безнең мирас №6 июнь 2017

17) Мөселманнар өчен ачылган учительская школа вә семинарияләр, курслар, тәгаен ителгән бөтен акча, бина вә милекләре белән йирле мөселманнар кулына алыныр.

18) Мөмкин булган йирләрдә бу елдан мөселман урта мәктәпләре һәм ихтисаси мәктәпләр (профессиональный мәктәпләр) ачылыр.

19) Урта мәктәпләремезгә тизрәк укытучылар йитештерү өчен гали курслар, рус гали мәктәпләрендә кафедралар ачылыр.

20) 1917-1918 уку елыннан милли мәктәпләрнең һәртөрлесендә укытучылар үз дәрәҗәләрендәге рус мәктәпләрендә укытучылар белән хокукта һәр җәһәттән тигез саналып, шулар белән бердәй вазифа ала башларлар.

21) Чит дәүләттән булган укытучыларның мөселман мәмләкәтләрендә укытулары тыелмас.

22) Ил корылтаенда милли, мәдәни мохтәрият һәм федерация мәсьәләсе хәл ителгәнгә кадәрле, вакытлыча земство вә шәһәр мәктәпләрен идарә өчен милли һәятләр төзелер. Бу ике идарә булмаган йирләрдә мәдәният вә мәгариф эшләремезне карау өчен махсус һәятләр мәйданга китерелер.

23) Укытучылар йитештерү өчен ачылган мөәссәсәләрдән (оешмалардан) шәһадәтнамә алган, яхуд шулар вә йә югарыда мәзкүр өч мөәссәсә хозурында ачылган милли һәятләр хосусында сыналган кешеләр генә мәктәпләребездә укытырга хаклы булырлар.

24) Сугыш сафында, тылда һәм оборонадагы мөселман укытучылары хәзердән үк азат ителсеннәр.

ХАТЫН-КЫЗ МӘСЬӘЛӘСЕ ХАКЫНДА

1) Шәригатьнең хитабларында ир белән хатын бер. Хатыннарның сәяси, иҗтимагый эшләргә катышырга шәригать алдында хокуклары бар. Шунлыктан, **хатыннарның сайлау эшләренә катышулары шәригать буенча тиеш**.

2) Хатыннарга хиҗаб шәригатьтә юк. Хатыннары тигез хокуклы булган милләт кенә көчле булып яшәү һәм бу хокукта тигезлекне хатыннарның канун төзи торган мәхкәмәләрдә үзләре хазир булганда гына чынбарлыкка чыгару мөмкин булганлыктан, **мөселманнар бөтен сәяси хокукта ирләр белән тигез булсыннар. Хатыннар ил корылтаена сайлый һәм сайлана алсыннар**.

3) Сайлау вә сайлану эшләре мөселманнар өчен яңа бер эштер. Бердән, хатыннарыбыз моңа кадәр иҗтимагый эшләргә катнашып өйрәнмәгәнлекләреннән, икенчедән, ирләре хатыннарының сайлау урыннарына баруларына каршы тору ихтималы булганга күрә, халкыбызның яртысы булган хатыннарыбызның тавышлары югалмасын өчен: **«Ил корылтаена сайлау вакытында һәрбер мөслимәнең сайлауга катышуы бурыч булсын. Мөслимәләргә тавыш бирү өчен ирләрдән аерым урын билгеләнсен»**.

4) Русия мөселманнары арасында кыз һәм егетнең ризалыгыннан башка никах уку бик күп булып, бу эш гаилә хәятенең тынычсызлыгына вә шул гаиләдә үскән балаларның бәхетсезлегенә сәбәп булганлыктан, **никах вакытында кияү белән кыз үзләре хәзер булсыннар**.

5) Гаиләдә ир белән хатын тату тормаганда, күп вакытларда хатын иреннән аерылып китәргә теләсә дә, аны ире аермыйча газаплап тота. Татулыксыз, гаиләдә кысынкы тормышта тору хатын өчен җәбер, гаиләдәге балаларның тәрбиясе өчен зарарлы булганга күрә, съезд хатыннарның хокукын һәм киләчәк буынның тәрбиясен игътибарга алып, ошбу кararны чыгарды: **«Ошашмаган тәкъдирдә хатынның иреннән аерылып китәргә хакы булуы никах вакытында никах дәфрәтенә кертелсен»**.

6) Төркестан һәм Кавказда һәм шулай ук Казакъстанда 11-12 яшьлек сабый кызларны кияүгә бирү вә гадәт хөкеменә кергәнгә, бу эш хатыннарның зәгыйфьләнүләренә, ва-

кытсыз үлүләренә һәм зәгыйфь балалар йитештереп киләчәк буынсыз, зәгыйфь вә көчсезлегенә сәбәп булганга, съезд, **Русиянең кирәк шималенда (төньяк), кирәк җәнүбендә 16 яшьтән ким булган кызга никах укылмасын**, дигән карарны чыгарды.

7) Милләт балалары таза һәм саглам булсын өчен һәм дә гаилә бәхетсезлекләренең байтагы ир йә хатынның йогышлы авыруларга дучар булуыннан килгәнгә күрә, шул бәхетсезлекләр белән көрәшү өчен съезд: **«Никах вакытында кияүнең дә, кызның да йогышлы авырулары булмавына кулларында шәһадәтнамәләре булсын»**, – карарын кабул итте.

8) Күп вакыт ирләрнең бер хатын өстенә икенче хатын алырга бер уен төсле генә итеп караулары һәм әүвәлге хатыннарын бер дә гаепсез хәлдә аерып җибәрүләре гадәт булып киткәнлектән, бу эшнең урынсыз кылануларга сәбәп булганлыгын да игътибарга алып, съезд: **«Никах вакытында кияүдән бер хатын өстенә икенче хатын алмаска язу алынсын. Әгәр дә инде бер-бер сәбәп белән икенче хатын алса, карт хатынын аерып, аңар нәфәка[4] бирсен»**, – карарын кабул итте.

9) Казакъстанда кыз балаларны аналары кечкенәдән үк калын малына саталар. Соңгы көндә хатын аерылырга теләсә, калын малын кайтарып бирергә мәҗбүр була. Бу калын мәһәрдән башка бернәрсә булып, кызны атасыннан сатып алганда бирелә торган бернәрсә. Шул сәбәпле, съезд, казакъ кызларының хокукларын игътибарга алып: **«Казакъ кызлары кияүгә барганда калын малы алу булмасын. Моңар кадәр калын малы алынып куелган казакъ кызлары, үз ризалыкларыннан башка, әйтелеп куелган кешеләренә бармаска хаклы булсыннар»**.

10) Күп хатыннар төрле сәбәпләр буенча фәхешханәләргә барып керергә мәҗбүр булалар. Кайсылары аннан котылырга чаралар эзләсәләр дә, фәхеш тугрысындагы кануннар сәбәпле, алар гомергә бәхетсезлектә калалар. Шул сәбәптән, **фәхешханәләр һәм фәхеш тугрысындагы законнар бетерелсен**.

Менә бу ун маддәдән гыйбарәт карарлар бөтен килеш кабул ителә.

ГАСКӘРНЕ ТӘШКИЛӘТ ХАКЫНДА

1) Гаскәрлеккә алыну бөтенләй бетерелсен. Һәм нинди генә рәвештә булмасын, милитаризмга каршы тору белән бәрабәр даими гаскәр булып торган вакытта, гаскәр милли булсын.

2) Сугыш беткәч, даими гаскәр булып торган вакытта, аерым мөселман гаскәри фиркаләре төзелсен.

3) Бу фиркаләрнең командантлары, әфитсәрләре мөселманнан булырга тиеш.

4) Бу гаскәрләр үзләренең алынган җирләрендә хезмәт итсеннәр.

5) Хәзердән үк сугыш сафындагы мөселман солдатларының бер дивизиядәгеләре шул дивизиянең бер полкына җыелыр. Тылдагы, гарнизондагы мөселман гаскәрләре дә бер полкка җыелсын, һәрбер полкта мөселман ашханәләре ясалсын.

6) Мөселман гаскәрләре җыелган һәр полкка, полк кешеләре белән бер хокукта полк муллалары сайланып куелсын.

7) Мөселман гаскәренә ярдәм өчен мөселман тыйбби фиркасе төзелсен.

8) Һәр санитарный поездга 2-3 хезмәтче мөселман куелсын.

9) Фронтка якын госпитальләрдә мөселман хәдимнәр булсын.

10) Бу карарларның 5-9 маддәләре бер дә кичектерелмичә, бу көндә үк гамәлгә куелсын. Шуны таләп итеп хәрбия вәзарәтенә мөрәҗәгать ителсен.

Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

[4] Нәфәка – ятимнәргә, аерылган хатыннарга бирелә торган акча.

Безнең мирас №6 июнь 2017

Галимҗан Ибраһимов: «МИН – БӘЙСЕЗ ТОРМЫШ КЕШЕСЕ!»

Гүзәл Төхфәтова

Татарстан Республикасы Милли музее фондында Галимҗан Ибраһимовның тәрҗемәче Гайшә Шәрипова, язучы Хөсни Кәримгә һәм башкага язган хатлары саклана. Алар арасында күренекле татар матбагачысы, нашир, публицист, тәрҗемәче, драматург һәм җәмәгать эшлеклесе Әхмәтгәрәй Хәсәнигә (1883-1933) юлланганнары да бар.

Галимҗан Ибраһимовның Ә.Хәсәнигә 1913 елның 8 сентябрендә язылган хатын музейга 3179 санлы акт белән 1962 елның 30 сентябрендә Зәйнәп Хәсәни тапшыра. Язма хәзерге көнгә кадәр беркайда да нәшер ителмәгән, беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертелә. Ул 22х17,6 см зурлыктагы авыш сызыклы дәфтәр битенең ике ягына язылган.

Хат язучының туган авылы Солтанмораттан җибәрелгән. Г.Ибраһимов авылда июнь урталарыннан сентябрь урталарына кадәр яши. Хатта үзенең тиздән Казанда булачагын хәбәр итә һәм чыннан да сигез көннән соң, ягъни 1913 елның 16 сентябрендә Г.Ибраһимов Казанга килеп җитә. Бу турыда «Йолдыз» газетасының 19 сентябрь санында мәгълүмат басылган.

Г.Ибраһимов Киевта. 1912 ел

Хат Ә.Хәсәнинең Галимҗан Ибраһимовны «Аң» журналына эшкә чакыруына җавап буларак язылган: *«Мөхтәрәм Әхмәтгәрәй әфәнде! Мәктүбегезне алдым. «Аң» кебек куәт вә тәрәккъыйне чындан арзу (омтылыш) иттегез. Бер журналның портфелен тәкъдим итүегезгә, шундый мөһим вакыйгада мине хатлавыгызга рәхмәт»*. Биредә язучының тәкъдим хакында уйлануы күренә.

«Беләсез, мин – хәяте мотлак (бәйсез тормыш) кешесе. Шуның өчен дә күпләрнең тәгаҗҗебенә (гаҗәпләнүенә) каршы, моңарчы «Вакыт» вә «Йолдыз»лар кебек зур вә карт гәзитәләрнең дәгъвәтен (чакыруын) иҗабәт итми (кабул итми) килә идем. Ләкин сезнең дәгъвәтегезне алгач, кырт кисеп рәд (кире кагу) җавабы бирәсем килмәде», – дип яза Г.Ибраһимов.

Г.Ибраһимовны «Аң» редакциясе исеменнән рәсми рәвештә иң элек Фатих Әмирхан чакыра. Ә.Хәсәни дә язучыны берничә тапкыр

«Аң» журналының баш мөхәррире Әхмәтгәрәй Хәсәни

آڭ

بهاسى ١٥ تين.

Такса объявленій въ журналѣ „АНГЪ“:
На обложкѣ, 2-я стран. на 1 разъ за строку петита 40 коп., 3-я и 4-я страница 20 коп., (въ страницѣ столбца).

Казань, контора журнала „АНГЪ“.

«Аң» журналы

хат язып чакырган булса кирәк, чөнки язучы 1913 елның 3 гыйнварында Киевтан Хәнәфи Кайбышевка юллаган хатында: «Монда килгәч, Гәрәй, үзе хат язып, яңадан «Аң»га язышуны үтенде», – дип белдерә.

Г.Ибраһимов 1913 елның 18 октябреннән 1914 елның 13 февраленә кадәр «Аң»ның җаваплы сәркатибе вазифасын башкара. Ул журналның фәнни-иҗтимагый һәм әдәби сыйфатын күтәрергә тырыша. Бу максаттан редакция тирәсенә сәләтле, белемле яшьләрне туплый башлый. Г.Ибраһимов «Аң»да эшләвенең максатын 1913 елның 26 октябрендә Хөсни Кәримгә язган хатында түбәндәгечә аңлата: «Аң»ның секретарьлыгын алдым. Буны, бәлки, ишеткәнсеңдер дә. Яшь фикер, яшь куәт «Аң» тирәсендә җыелсын иде. Чын мәгънәсе илә әдәби вә мәдәни бер мәҗмуга шәкеленә керсен иде, дим». Мөхәммәт Мәһдиев фикеренчә, «Аң»ның сәнгатьне пропагандалаудагы казанышы да анда секретарь булып Г.Ибраһимов эшләгән чорга туры килә.

Татарларны туплау, аларны оештыру һәм милли фирка төзү максатыннан Г.Ибраһимов, журналдагы эшен калдырып, Киевка китәргә мәҗбүр була. Ләкин журнал белән бәйләнеш өзелми, «Аң» битләрендә язучының төрле елларда әдәби, фәнни мәкаләләре басылып килә. Мәсәлән, «Татар имласында яңа агымнар» (1915), «Татар сарыфлары» (1915), «Телләре башка булса да, күңелләре бер» (1916) һ.б.

Ф.Ибраһимова язуынча, «Аң» редакциясе 1914 елның языннан башлап Г.Ибраһимовка журналда басылган һәм басылачак әсәрләре өчен ай саен билгеле бер күләмдә каләм хакы җибәреп торган. Казан




губерна жандарм идарәсе архивында: «Г.Ибраһимов «Аң»нан китсә дә, журналның хезмәткәре булып исәпләнә», – дигән мәгълүмат бар.

Гомумән, төрле фондларда сакланып калган Г.Ибраһимов белән бәйле документ, кульъязма, хатлар тикшерелеп, киң җәмәгатьчелеккә җиткерелергә тиеш. Еллар узуга карамастан, алар актуальлеген югалтмый, язучының тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүдә яңа мәгълүматлар ача.

Мөхтәрәм Әхмәтгәрәй әфәнде!

Мәктүбегезне алдым. «Аң» кебек куәт вә тәрәккъыйне чындан арзу [омтылыш] иттегез. Бер журналның портфелен тәкъдим итүегезгә, шундый мөһим вакыйгада мине хатлавыгызга рәхмәт.

Беләсез, мин – хәяте мотлак [бәйсез тормыш] кешесе. Шуның өчен дә күпләрнең тәгаҗҗебенә [гаҗәпләнүенә] каршы, моңарчы «Вакыт» вә «Йолдыз»лар кебек зур вә карт гәзитәләрнең дәгъвәтен [чакыруын] иҗабәт итми [кабул итми] килә идем.

Ләкин сезнең дәгъвәтегезне алгач, кырт кисеп рәд [кире кагу] җавабы бирәсем килмәде. Озакламый Казанга барам. Шунда тәфсилләп сөйләшербез.

Шартларда килешсәк, уйлаган мөрәттәбә [тәртиптә] вә тәрәккъый бирә алу өчен лөзүм [кирәк] улган әсбаб вә мөәддинең [алып баручының] табылуында әминиять [ышаныч] ала алсак, бәлки бергә эшләп тә китәрбез...

Һәр нә күрешкәч мәгълүм булыр.

Хәзергә хөрмәт вә сәлам:

Галимҗан – Солтанморат
1913-сентябрь 8. ■

1. Әхмәтгәрәй Хәсәни: Фәнни-популяр җыентык / Д.Ф.Заһидуллина, А.Д.Батталова, Л.Н.Йөзмөхәммәтова. – Казан: Җыен, 2011. – 408 б.
2. Ибраһимов Г. Әсәрләр. 9 томда. – 9 Т.: Хатлар һәм документлар / Төз. Ф.Ибраһимова. – Казан, 2000. – 464 б.

РИВАЯТЬКӘ ЛАЕК ГОМЕР

Илдус Фазлетдинов

Хафиз Хәбибуллин хатыны Сәлимә (уңда), кызлары Рокыя (сулда) һәм Разия (уңнан икенче) белән

1897 елның язы... Елгалар боздан арчылган, бар дөнья яңарыш кичергән мәл... Хәер, сәүдәгәр өчен монысы әллә ни зур әһәмияткә ия түгел, иң мөһиме – тиздән Караидел буйлап Санкт-Петербургка иген төялгән баржалар кузгалачак. Кыш буе якын-тирә авылларда яшәүче татар-башкорттан җыелган икмәк башкалага юл алачак. Бу эшне биредә Хафиз бай башлап җибәрде.

Әлек халыкка игенне козгын кебек төрле яклардан ябырылган алыпсатарларга бик арзан хакка тапшырырга туры килә иде. Алар исә, икмәк хакын икеләтә-өчләтә арттырып, Русиянең төрле төбәкләренә илтеп сатты. Хәзер инде эш җиңеләйде. Хафиз байның тырышлыгы аркасында, халыктан җыелган игенне саклау өчен ике катлы келәт булдырылды, Франциядән иген киптерү җайланмасы кайтарылды һәм, иң мөһиме – Устьмаш авылы янында пристань төзетелеп, анда баржалар ясау эше дә җайга салынды. Хафиз байның күзәтүеннән башка бер генә киселгән бүрәнә дә эшкә җибәрелми хәзер, бай үзе дә эш эчендә кайный.

Менә, ниһаять, яңа пристаньнан иген төялгән баржаларның Петербургка кузгалыр вакыты да килеп җитте. Тирә-яктагы авыл-шәһәрләрдән Устьмашка төрле милләттәге сәүдәгәрләр, алыпсатарлар җыелды. Барысының да башында тик бер генә уй кайный: «Кем икән ул Хафиз бай дигәннәре? Башкарган эшләренә караганда, черегән байдыр, башкалар белән үзен бик һавалы тотадыр инде». Сәүдәгәрләр дүрт күз белән байның пристаньгә килүен көттеләр. Ләкин яллары алтын укалар белән бизәүле атлар җигелгән кыйммәтле фаэтон да, бай киемле кучер да, үзен патшалар кебек дәрәҗәле тоткан Хафиз да күзгә чалынмады.

Ә пристаньда исә эш кызганнан-кызды. Җилкәләренә капчык-капчык арыш күтәргән таза гәүдәле йөкчеләр әле келәткә, әле баржага ашыктылар. Көрәк сакаллы, мускуллары уйнаклап торган берсе аеруча тырыш: башкалар бер капчык иген күтәргәндә, ул киң җилкәсенә икене сала һәм, «ых» та итми, аны баржага илтеп тә куя. Күпне күргән сәүдәгәрләр дә аңа сокланып, тел шартлатып карап тордылар. Шулай итеп, баржалар төялеп бетте һәм аларны тартып алып баручы пароход, соңгы гудок биреп, башкалага таба юл алды.

– Кара әле, – дип сөйләштеләр үзара сәүдәгәрләр, – бу Хафиз бай дигәннәре, чынлап та, бик һавалы икән, үз игенен башкалага озатканны карарга да килеп тормады.

Шулчак теге көрәк сакаллы йөкче гади генә бер арбага менеп басты да, атын куалый-куалый, Олы Ака авылы ягына чаптырып алып китте. Маңгай тирен күлмәк чабуы белән сыпыра-сыпыра сәүдәгәрләр яныннан үтеп баручы бер эшче, аның артыннан карап калып:

– Бигрәк тынгысыз кеше дә инде бу Хафиз бай. Әле генә безнең арада гади эшче кебек иген ташып йөри иде, хәзер сәүдә эшләре белән туган авылына кайтып та китте. Тырышлыгына таңнар калырлык, – дип, баш чайкап куйды.

Үзләрен бу дөньяда бернәрсә белән дә гаҗәпләндереп булмавына ышанган сәүдәгәрләр телсез калдылар. Теге көрәк сакаллы, тәнендә мускуллары уйнаклап торган «йөкче», чынлыкта, даны бөтен тирә-якка таралган миллионер Хафиз Хәбибуллин булып чыкты...

...Бу риваятьне миңа миллионерның туган ягы – Башкортстанның Мәчетле районы Олы Ака авылында яшәүчеләр авызыннан ишетергә туры килде. Шунда ук хәтергә Алексей Толстойның «Петр I» романыннан бер күренеш килеп төште. Яшь патша Голландиянең Амстердам верфьләрендә кораб төзү эшләренә өйрәнеп йөри: гади эшчеләр белән нарат каезлый, мачта күтәрә, идән җыя. Аны күрергә дип килгән югары дәрәҗәле хөкүмәт вәкилләре исә Петр патшаны очрата алмыйча тәмам гаҗиз булалар. Чөнки алар аны кыйммәтле ефәк-парчаларга төренгән, урыныннан да кузгалырга иренгән, көрәк сакаллы бер ир итеп күз алларына китерәләр. Ә, чынлыкта исә, Петр I кара эштән курыкмаган, теремек гәүдәле, сызылып киткән кара мыеклы яшь егет булып чыга. Шулай итеп, хөкүмәт әһелләре урыс патшасын озак көтсәләр дә, очрата алмыйча, күңелсезләнеп, кыйммәтле кареталарына утырып кайтып китәргә мәҗбүр булалар.

Хафиз Хәбибуллинның кереме зур була. Октябрь инкыйлабы алдыннан гына ул үзенең шәхси банкын ачып җибәрә, аның еллык әйләнеше 6,2 миллион сум тәшкил итә. Ләкин бу акчаның зур өлешен ул җәмәгатьчелек өчен сарыф итә. Мәчет-мәдрәсәләр генә түгел, Красноуфимск шәһәрендә ул христианнарга да зур чиркәү салып бирә.

«Бөеклек – гадилектә», – ди халык. Югарыда китерелгән ике эпизод та бу сүзләрнең дөреслеген раслый. Чынлап та, кешенең рухы никадәр бөегрәк булса, ул шулкадәр гади, тирә-яктагыларга ихтирамлы була. Моны бөек әдибебез Габдулла Тукай мисалында да ачык күрергә мөмкин. Кызганыч ки, зур дәрәҗәләргә ия булып, үзен Аллаһының кашка тәкәсе урынына күргән зур корсаклы, тар маңгайлы түрәләр арабызда күпкә артык шул... «Энҗе бөртекләп табыла», – дигәннәре дә шуннандыр инде...

* * *

Уйлап караганыгыз юкмы: Хафиз бай яшәгән төбәк ни өчен Мәчетле дип атала икән? Юкка түгел бу. Безгә калса, моны хәзерге Мәчетле районы җирләренең XIX гасыр азагында Дуван-Мәчетле волостена каравы белән генә аңлату да дөреслеккә туры килеп бетми. Сер тирәндәрәк ята. Һәм ул язмабызның каһарманы Хафиз Хәбибуллинның тормыш юлы белән турыдан-туры бәйле булырга тиеш.

Эш шунда ки, 1850 елда Казан губернасының Мамадыш өязе Оры авылында дөньяга килгән бу шәхеснең ата-анасы ифрат дини җанлы була. Алар балаларында да исламга мәхәббәт, шәригать кануннарына ихтирам тәрбияләргә тырыша. 1861 елгы реформадан соң, Хафизның атасы Хәбибулла абзый гаиләсе белән Пермь губернасының Красноуфимск өязенә караган Урта Ака, ә соңрак Олы Ака авылына күчеп утыра.

Ата-анасындагы асыл сыйфатлар – ислам диненә, туган милләтенә булган ихтирам хисе нәсел буенча Хафизга да күчә. Җирле халыктан ашлык сатып алуны оештырып, тернәкләнеп китү белән, Хафиз Хәбибуллин мәчет салдыру эшенә керешә. Билгеле, бу – һәр мөселман өчен иң изге гамәлләрнең берсе. XX гасыр башында Олы Акада Хафиз бай акчасына төзелгән өч мәчет һәм мәктәп бер-бер артлы күтәрелә! Хафиз Хәбибуллин аларны тулысынча җиһазландыра. Тиздән авылда хатын-кызлар өчен беренче мәктәп тә эшли башлый. Ул гына да түгел, Хафиз бай хәзер Мәчетле районына караган күпчелек татар һәм башкорт авылларында мәчет салдыруны да үз өстенә ала. Менә кайда ята икән ул район атамасының тамырлары! Әллә нинди этимологик сүзлекләр актарасы да юк. «Мәчетле авылда җан бар», – дигән ата-бабаларыбыз. Хафиз байның туган якларына сәяхәтебездә мин бу сүзләрнең дөреслегенә тагын бер тапкыр инандым. Очрашкан һәрбер кешенең күзләрендә Хафиз бай җанының бер өлеше – ул салып калдырган илаһи очкын яна иде...

Ул өяз үзәге – Красноуфимск каласында да мәчет белән мәктәп салдыра. Шунысын да әйтик, патша түрәләре моңа төрлечә аяк чалырга тырыша. Алар мәчет төзү өчен җирне шәһәрнең читеннән, бик уңайсыз урыннан бүләләр. Ләкин Хафиз бай аптырап калмый, 3000 сумга икенче урын сатып ала һәм мөселманнарга бүләк итә. Инде төзелеш эшләре башланды гына дигәндә, Пермь православие консисториясе: «Шәһәрдә мөселманнар аз яшәгәнлектән, мәчетнең кирәге юк», – дип, югарыга бер-бер артлы шикаять яудырырга керешә. Моңа җавап йөзеннән, шәһәрдә Ислам дине тотучылар шактый зур сан – ирләр генә дә 225 кеше тәшкил иткәнлеген исбатлап, мөселманнар хат оештыралар.

Безнең мирас №6 июнь 2017

Шулай итеп, төрле ызгыш-гаугалар аркасында, мәчет-мәдрәсә тик 1916 елда гына төзелеп бетә.

Хафиз бай чит төбәкләрдә дә мәчет-мәдрәсәләр салдыруга зур өлеш кертә. Мәсәлән, ул Ярослав губернасының Рыбинск каласында җамиг мәчете төзү өчен 8000 сум акча бүлә, 1911 елда купец В.А.Аксеновтан Черемха елгасы буенда урнашкан ике матур җир участогы сатып ала. Ләкин «татар башын татар ашар», дип юкка гына әйтмиләр шул. Мәчет салу эшләрен башлау өчен, төрле даирәләрдән күп санлы белешмә-рөхсәтләр алырга кирәк була. (Нишлисең, Русиядә бюрократия һәр заманда да зур көчкә ия...) Ни гаҗәп, бу юлы инде Уфадагы Үзәк диния нәзарәте әлеге изге эшкә төрлечә аяк чала башлый. Нәтиҗәдә, мәчет төзү эшләре кичектерелә килеп, мәсьәлә 1918 елда гына уңай хәл ителә. Ләкин бу вакытта инде илдәге хакимиятне большевиклар үз кулларына алган, дин «халык өчен әфьюн» дип игълан ителеп, Русиядә сугышчан атеизм хакимлек итә башлаган була. Кыскасы, изге эш башлангычында ук үтерелә...

Халык хәтерендә Хафиз байның мәчет төзүдәге эшчәнлеге, юмартлыгы турында тагын бер кызыклы риваять саклана. Аның Петербург сәүдәгәрләре арасында дуслары, танышлары күп була. Шулай берчакны алар, җыелып, башкалада җамиг мәчете төзү турында сөйләшә башлыйлар, хәйрия фонды оештыралар. Һәр сәүдәгәр, хәленнән килгәнчә, бу фондка акча кертә. Зур гына сумма җыела. Иң азакка булып Хафиз бай сүз ала:

– Барлыгы күпме акча җыелды? – дип сорый ул.

Фонд рәисе җавап бирә. Шулчак Хафиз бай кесәсеннән акча янчыгын чыгара да, барлык сәүдәгәрләр керткән суммадан артыграк акчаны өстәлгә китереп сала.

– Монысы миннән булыр, – ди ул.

Сәүдәгәрләр «аһ» итә... Күренүенчә, Хафиз байны һич кенә дә саран дип әйтеп булмый. Юкса, дистә еллар буена алып барылган коммунистик үгет безнең көннәрдә ялган фикер тудырды. Яхшы кеше мотлак ярлы гаиләдә туып, авыр гомер кичерергә тиеш, бай кеше исә канэчкеч, саран, ул бары тик башкалар җилкәсенә утырып, аларның «канын» суырып кына, байлык туплый ала, имеш. Шушы принциптан чыгып, дистәләгәнчә татар әдипләренең исемнәре әдәбият дәреслекләреннән сызып ташланды, аларга «мулла малае», «кулак куштаны» дигән ярлыклар тагылды. Мисал өчен ерак йөрисе юк, Дәрдемәнд, Галимҗан Ибраһимов, Фәтхи Бурнаш, Гаяз Исхакыйларның язмышларын искә төшерү дә җитә...

Чынлап та, Хафиз Хәбибуллинның кереме зур була. Октябрь инкыйлабы алдыннан гына ул үзенең шәхси банкын ачып җибәрә, аның еллык әйләнеше 6,2 миллион сум тәшкил итә. Ләкин бу акчаның зур өлешен ул җәмәгатьчелек өчен сарыф итә. Мәчет-мәдрәсәләр генә түгел, Красноуфимск шәһәрендә ул христианнарга да зур чиркәү салып бирә. Аның планнарында бу шәһәрдә зур капчык тегү фабрикасын ачу, Ака елгасы аша чуен күпер төзү һәм хәтта Красноуфимскидан Уфага кадәр тимер юл салу да була. Аяныч ки, Октябрь инкыйлабы бу ниятләрнең һәммәсен дә чәлпәрәмә китерә...

Хафиз Хәбибуллин 1911 елга кадәр II гильдия сәүдәгәре булып исәпләнә, ә инде аннан соң I гильдия таныклыгын ала. Тормышта бик гади, тыйнак, юккабарга кызмый торган салкын акыллы кеше булса да, ул туган теленә, диненә тел тидергәнне кичерә алмый. Туган як тарихын тикшерүчеләр – тарих фәннәре кандидаты Булат Дәүләтбаев һәм Мөхәммәтнур Муллануровның 2000 елда Казанда нәшер ителгән «Хафиз бай Акалы» китабында аның милли җанлылыгын исбатлаган бер риваять китерелә.

Красноуфимскида узган сәүдәгәрләр җыелышында берәү, Хафизның урыс телендә авыррак сөйләшкәнен күреп,

«гололобый татарин», дип, аңардан көлә башлый. Күрәсең, ул Мөхәммәтхафизның зур дәрәҗәле, шөһрәтле кеше икәнлеген белмәгәндер инде. Шулчак милләттәшебез тун изүен ачып җибәрә һәм тегеңә I гильдия сәүдәгәр билгесен чыгарып күрсәтә. Урыс, аптырап, катып калган, ди, чөнки I гильдия сәүдәгәрләре Русиядә бармак белән генә санарлык була. Хафиз аяк киемен салган да, моңа: «Целуй ногa!» – дип кычкырган, имеш. Бөгелгән теге...

Менә шундый гади, әмма горур кеше булган ул Хафиз Хәбибуллин. Аның юллавы буенча, Акада Беренче Бөтендөнья сугышы елларында кызыл кирпечтән хастаханә төзелә. Шулай ук ике катлы кызлар гимназиясе дә сафка басарга тиеш була, ләкин аның аскы каты гына төзелеп бетә. Барысына да Октябрь инкыйлабы комачаулый...

Революциядән соң, Хафиз Хәбибуллинга алтынлата 125 мең сумлык контрибуция салына. Бу сумманы берсүзсез түләвенә карамастан, большевиклар аны төрмәгә утырталар һәм аңардан калган акчасын, алтын-көмешләрне таләп итеп, авыр тән җәзалары аша үткәрәләр. Байны, Стәрлетамакта яшәүче кияве Мостафа Үтәмешев килеп, зур күләмдәге йолым түләп кенә үлемнән коткарып кала һәм яшәргә үзе янына алып китә. Хәер, аның йорты да «кызыллар» тарафыннан тартып алынган була инде...

Шулай итеп, Хафиз Хәбибуллинның гомер буена тупланган бар милке Советлар кулына күчә. Тормышының бар мәгънәсе – планнары, изге башлангычлары, мөлкәте бер мизгелдә юкка чыккан Хафиз бай, төрмә тәэссоратларыннан арына алмыйча, чиргә сабыша. Кызы Рокыя әтисен мунчада яткырып дәвалый. Ләкин үлемне җиңеп булмый шул...

Атаклы сәүдәгәр 1919 елда 68 яшендә Стәрлетамакта вафат була. Аны татар зиратына җирлиләр һәм өстенә бик матур кабер ташы куялар. Ләкин яңа хакимияткә Хафизның үзен юк итү генә түгел, исемен дә халык хәтереннән җуеп ташлау кирәк була. Сугыштан соң, әлеге зират юкка чыгарылып, барлык кабер ташлары да төзелә башлаган һөнәри училищеның нигезе астына салына... Бәлки чагыштыру урынлы да түгелдер, бу хакта ишеткәч, Казан шәһәрен урыслар тарафыннан яулап алу хөрмәтенә төзелгән чиркәү астында калган мөселман кабер ташлары хәтеремә килеп төште. Җиңелгән халык язмышы кебек шул татар зиратларының язмышы – кайда да аяк астына салып таптыйлар...

Хафиз Хәбибуллинның язмышы бөек шагыйребез, алтын приисклары хуҗасы Дәрдемәнднең тормыш юлына охшаш. Алар икесе дә Башкортстан җирләрендә хәләл көч белән үз эшләрен башлап

Атаклы сәүдәгәр 1919 елда 68 яшендә Стәрлетамакта вафат була. Аны татар зиратына җирлиләр һәм өстенә бик матур кабер ташы куялар. Ләкин яңа хакимияткә Хафизның үзен юк итү генә түгел, исемен дә халык хәтереннән җуеп ташлау кирәк була. Сугыштан соң, әлеге зират юкка чыгарылып, барлык кабер ташлары да төзелә башлаган һөнәри училищеның нигезе астына салына...

җибәрәләр, икесе дә керемнәренең зур өлешен халыкка аң-белем кертүгә, мәчет-мәдрәсәләр ачуга юнәлтәләр. Гомерләре дә бер үк төрле тәмамлана: бар мөлкәтләрен большевиклар тартып алып, төзегән мәчетләренең манараларын кисеп, гомер буена табынып яшәгән идеалларын җимерүгә чыдый алмыйча, алар чиргә сабышалар һәм өч ел ара белән бер-бер артлы вафат булалар. Нишлисең, бөекләрнең язмышы шулдыр инде. «Нет пророков в своем Отечестве», – дигән бит шагыйрь. Кешенең кыйммәтен үзе үлгәч кенә аңлыйбыз шул...

Хафиз байның аяныч язмышы аның кызлары Рокыя белән Разияга да тәэсир

Хафиз Хәбибуллин (уртада) Санкт-Петербург сәүдәгәрләре арасында

итми калмый. «Кызыл террор»дан башларын саклап калу өчен, Мостафа Үтәмешев хатыны Рокыяны Ташкентка алып китә. Алар бергә 33 ел гомер кичерәләр. Мостафа – 1942 елда, ә Рокыя 1980 елда дөнья куя. Балалары булмый.

Шулай да, атаклы якташыбызның нәсел-нәсәбе әле дә дәвам итә. Моны Хафиз байның Ташкентта яшәүче бердәнбер оныгы Гүзәл Әхмәтҗанованың Мөхәммәтнур Муллануровка язган хатыннан белеп була. Ул үзенең әнисе, Хафиз Хәбибуллинның кече кызы Разиянең язмышы турында менә нәрсәләр яза: *«Минем әнием картәни белән Акада яшәгән. Мәктәп директорына кияүгә чыккан, үзе шул ук мәктәптә укыткан. Ике балалары туган, әмма авырып үлгәннәр.*

Хафиз Хәбибуллинның язмышы бөек шагыйребез, алтын приискалары хуҗасы Дәрдемәнднең тормыш юлына охшаш. Алар икесе дә Башкортстан җирләрендә хәләл көч белән үз эшләрен башлап җибәрәләр, икесе дә керемнәренең зур өлешен халыкка аң-белем кертүгә, мәчет-мәдрәсәләр ачуга юнәлтәләр. Гомерләре дә бер үк төрле тәмамлана: бар мөлкәтләрен большевиклар тартып алып, төзегән мәчетләренең манараларын кисеп, гомер буена табынып яшәгән идеалларын җимерүгә чыдый алмыйча, алар чиргә сабышалар һәм өч ел ара белән бер-бер артлы вафат булалар.

1933 елда, әниемнең иренә, «миллионер кызына өйләндең», дип бәйләнә башлагач, алар аерылышканнар. Әнием бик елаган, раскулачивать итеп, бөтен әйберен талап алганнар, ул бернәрсәсез калган. Ярый әле кулга алыр алдыннан качып, Ташкентка апасы янына барып сыенган. Трамвай йөртергә укыган, 1937 елда трамвай паркында эшли башлаган. Шунда әнием бер эшче белән танышып кияүгә чыккан, мин дөньяга килгәнмен. Әнием 1991 елда вафат булды... 1970 елда без авылга кайтып килдек, әниемнең туып-үскән йортында булдык».

Менә шундый язмышлар... Миллионер кызы, гомерен туган якларыннан меңнәрчә чакрым читтә үткәреп, трамвай йөртүче булып эшләрмен, дип беркайчан да уйламагандыр, мөгаен. Бу юлларны укыгач, дөньяның фанилыгына тагын бер тапкыр ышанасың... Хафиз байның оныгы Гүзәл ире Габдеррафикъ белән өч кыз үстерә. Аларның зурысы – Гөлнара һәм уртанчысы – Динара гаиләләре белән Ташкентта яшиләр, ә кечесе – Әлбинә ире Дамир белән Төмән өлкәсендә көн күрә. Кыскасы, Хафиз байның нәселе дәвам итә.

Система ничек кенә оныттырырга тырышмасын, атаклы якташларының исеме акалыларның күңелендә әле дә саклана. Аны халыкка кире кайтарулары өчен, беренче чиратта Олы Ака егете, тарих фәннәре кандидаты Булат Сабирҗан улы Дәүләтбаевка һәм Урта Богалыш авылында туып-үскән һәвәскәр язучы Мөхәммәтнур Муллануровка зур рәхмәтләр юлларга кирәк. Алар, архивларда казынып, авылның өлкән кешеләре белән очрашып, Хафиз байның шәҗәрәсен, эшчәнлеген тулы яктырттылар. 2000 елда Казанда «Хафиз бай Акалы» исемле китап чыгарып, данлыклы якташлары белән Башкортстан халкын гына түгел, ә аның тарихи Ватаны – Татарстан укучыларын да якыннанрак таныштыра алдылар. Булат Дәүләтбаевның 1992 елда Уфада нәшер ителгән «Большая Ока» китабында да Хафиз Хәбибуллин эшчәнлегенә махсус бүлек багышлана. «Татар халык иҗаты» күптомлыгының 1987 елда дөнья күргән «Риваятьләр, легендалар» китабында да Хафиз бай турында халык хәтерендә уелып калган риваятьләр урын алган. Кыскасы, Хафиз бай әле дә якташлары күңелендә яшәвен дәвам итә.

Ул гына да түгел, заманында Хафиз бай акчасына төзетелеп, аннан соң большевиклар тарафыннан тартып алынган, манаралары киселгән элекке Красноуфимск мәчете өстендә дә изге ай халыкка яңадан илаһи нурларын сибә башлады. Моның өчен, җирле татар җәмәгатьчелегенә Хафиз Хәбибуллин 1911 елда мәчетне төзеткәндә үткән сынаулар аша кабаттан узарга туры килә. Шул ук хатлар, кире кагулы резолюцияләр, яңа хатлар... Мәчетне шәһәр мөселманнарына кире кайтару кирәклеген хакимият башлыкларына аңлатыр өчен, имам Нәҗип Садыйковка халыкны Красноуфимск шәһәр советы алдына чыгарып, шунда гает намазы укырга туры килә. Халык ташкынын күргәч кенә, чиновниклар, буш торган мәчет бинасын мөселманнарга кире кайтарып бирергә кирәк, дигән карарга киләләр. Бу вакытта мәчет бинасында искиткеч җимереклек хөкем сөргән була. Җылылык та, су да, тәрәзәләр дә булмый, тишек түбәдән тамчы тамып тора. Ләкин бердәмлек барысын да җиңеп чыга. Энтузиастлар хәтта Хафиз бай үзе эшләткән тәрәзә рамнарын да эзләп табалар һәм аларны яңадан мәчеткә куялар. Хафиз байның рухы варисларының бу изге эшләренә бик шатлангандыр, дип уйлыйм.

Форсаттан файдаланып, районның хакимият органнарына да мөрәҗәгать итәсем килә. Хафиз Хәбибуллинның Мәчетле районы Олы Ака авылындагы йортында музей ачып, аның истәлеген мәңгеләштерергә иде ләбаса! «Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге дә юк», дигән мәгълүм гыйбарәне онытмасак иде... ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

НУГАЙ КАЗАКЛАРЫ

Рөстәм Әминов

1745 елда 504 нугай Казан губернасыннан Оренбург төбәгендәге Сакмар елгасы буена, әүвәлге Нугай Урдасы, ягъни кайчандыр үзләренең борынгы әби-бабалары җирләренә яңадан күчеп утыра[1], Кундрау дигән хәрби бистә барлыкка килә. 1747 елда нугайлар казакъ даласына качып киткәннән соң, анда яшәүче халыкның саны 25 гаиләгә, ягъни 138 кешегә кими. Безнең фикеребезчә, качкынлыкның сәбәбе нугайларның православие динендәге казаклар белән күрше яшәргә теләмәүләре булса кирәк. 1760 елда исә, Кундрауда нибары 60 хуҗалык кына исәпләнә. 1773-1775 еллардагы Е.Пугачев җитәкчелегендәге Крестьян сугышында катнашкан өчен, аларның башка казаклар ия булган өстенлек һәм дәрәҗәләре юкка чыгарыла.

Нугайлар 1768 елда Казан губернасыннан Оренбург төбәгенә тагын күчерелә. 200 гаилә – барлыгы 1044 кеше Сакмар елгасы буенда – Чишмә һәм Алексеевск полкларыннан бушаган җирләргә төпләнә. Шулай итеп, Воздвиженск крепостенда – 110, Никитин редутында – 50 һәм Сары

[1] Нугайлар Казан артыннан күчеп киткән булырга тиеш, әмма тарихи чыганакларда бу турыда әйтелми. Ә Казан губернасына исә Әстерхан төбәгеннән күченгәннәр, монысы документлар белән раслана.

редутында 40 гаилә яши башлый. Алдагы унъеллыкта нугайлар Идел-Урал татарлары белән кушыла, ә инде XIX гасырда алар татар казакларыннан әллә ни аерылмый башлый. Безнең уебызча, нугайларны Сакмар буена күчерүгә төп сәбәп – алда әйтелгән урыс полкларының чик буен һәм тирә-яктагы җирләрне күчмә кавемнәр һөҗүменнән сакларга сәләтсез булуы. Шуңа күрә дә хөкүмәт бу җирләргә күчмә төркиләрнең телен һәм гореф-гадәтләрен яхшы белгән, аек акыллы, хәрби эшкә оста нугайларны күчерүне кулай күрә.

1795 елгы V халык санын алу кенәгәләрендә әлеге дүрт авылда 1836 нугай казагы яшәве теркәлгән. Шунысын да әйтергә кирәк: Воздвиженск крепостенда, нугайлардан кала, 227 башкорт та яшәгән. Вакытлар узу белән, хакимият башка халыкларны да күчерү сәбәпле, бу авылларда этник һәм дини состав төрлеләнә. Мисал өчен, 1830 нчы елларда Сары редутына Самара тирәсеннән утызлап мукшы гаиләсе килеп төпләнә. Соңрак, 1832 елда нугайлар үз җирләрен Курск төбәгеннән күчерелгән 712 урыс крестьяны белән уртаклашырга мәҗбүр була, шуның өстенә, күрше-тирәдә яңа өч урыс авылы барлыкка килә. Казакларның ризасызлыгына карамастан, җирле хакимият һәм соңрак Финанс министрлыгы крестьяннарны нугайларның җирләрендә калдыра.

XIX гасыр башында хакимият Оренбург казак гаскәрендәге татарларны, шул исәптән нугайларны да башкорт гаскәре составына күчерү сәясәтен башлап җибәрә. Шулай итеп, 1816 елгы VII халык санын алу кенәгәләрендә казак гаскәриләре составында – Воздвиженск крепостенда – 65, Сары редутында – 13, Никитин редутында – 35, Кундрау бистәсендә – 19; барлыгы 132 нугай калганлыгы теркәлгән. Ә башкорт гаскәре составына кергән нугайлар саны – Воздвиженск крепостенда – 782, Сары редутында – 401, Никитин редутында – 401, Кундрау бистәсендә – 471; барлыгы – 2055.

XIX гасырның икенче яртысындагы вазгыятьне дә күзәтик. Бу чордагы документларда Югары һәм Түбән Чебенле, Воздвиженск крепосте, Сары һәм Никитин редутлары, Кундрау бистәсе «башкортлары», ягъни Оренбург казак гаскәренә кире керергә теләмәгән 1083 кеше теркәлгән. 1840 елгы «Нигезнамә»нең 28 нче пункты нигезендә, казак сословиесенә кермәгән кешеләр казнаның буш җирләренә күчерелергә тиеш була. 3 нче полк «башкортларын» Оренбург өязенең Тук елгасы буена күчерү, әмма җан башына нибары 15 дисәтинә генә җир бирү мәсьәләсе карала.

Шулай итеп, 1852 елның 5 июлендә Хәрби шура Оренбург казак гаскәре станицаларында яшәүче нугай «башкорт»ларына күченү өчен ике ел вакыт һәм кайбер ташламалар бирә. Күченү турындагы карарны түрә-карага белдерми генә, алар казак булып саналган һәм шулай итеп, икееллык ташламалардан бик оста файдаланган. Архив документларыннан күренгәнчә, 1853 елда Новоздвиженск крепосте, Сары һәм Никитин редутлары һәм Кундрау бистәсе халкы Оренбург казак гаскәре составында да, башкорт гаскәрендә дә саналган, ягъни нугайларның Оренбург гаскәренә кире кайтулары бу вакытка әле хәл ителмәгән. Ә инде 1865 елда башкорт гаскәре бетерелгәннән соң, Оренбург казак гаскәрендә 2660 нугай казагы (1343 ир-ат һәм 1317 хатын-кыз) теркәлгән. Авылларның этник составы да төрле булган. Әйтик, Воздвиженскида рус казаклары күбрәк яшәгән, 1867 елда аларның 53 проценты христиан, 47 проценты ислам динендә булган. Мөселманнардан Сары редутында нугайлар күбрәк булса, Воздвиженск станицасында татар казаклары сан ягыннан өстенлекне тәшкил иткән.

XX гасыр башында Воздвиженск поселогында яшәүче 122 татар һәм нугай гаиләсе күршедәге Кырык Күкәй пүчинкәсенә китеп төпләнергә һәм шунда җамигъ мәчетен дә күчерергә рөхсәт сорап гариза яза. Документтан күренгәнчә, мөселманнар үзләренең планда каралган җирләрендә яшәми икән. Сакмар елгасы

Безнең мирас №6 июнь 2017

буенда ук яшәгәнлектән, һәр яз саен елга ташкыны ярны юа, шул сәбәпле якындагы йортларга җимерелү куркынычы туа. Шуның өстенә, өйләр бер-берсенә терәлеп үк урнашу сәбәпле, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре дә бозылган. Кырык Күкәй пүчинкәсенең тарихы 1883 елдан, бирегә татар һәм нугай халкы килеп төпләнгәч башланып китә. XX гасыр башына кадәр ул Воздвиженск составында теркәлгән.

Шунысын искәртик, XVIII гасыр башында Кундрау бистәсендә, шул исәптән башка авылларда да нугайлар өстенлекне тәшкил итсәләр, 1916 елга исә алар нибары 30,8% кына кала. Ә православие динендәгеләр гомумхалыкның 68,9 процентын, баптистлар исә 0,3 процент тәшкил иткән. Сары поселогында мөселманнар белән православие динендәгеләрнең саны тигез булган диярлек – 50,4% һәм 49,6%.

1876 елга кадәр нугайларның төп вазифасы – Оренбург чигендә хезмәт итеп, урыс дәүләтенең куркынычсызлыгын тәэмин итү. Алар ел саен 16 майдан 16 ноябрьгә кадәр гаять авыр, куркыныч булган каравыл һәм разведка хезмәтен башкарган.

17-55 яшь аралыгындагы нугай казагының акчалата һәм натураль түләргә тиеш булган бурычларын да әйтеп үтик. Беренче категорияне губерна һәм гаскәр, ә икенчесен, нигездә, станица дәрәҗәсендәге бурычлар тәшкил иткән. Губерна йөкләмәсенә юлларның төзеклеген кайгырту, юл буендагы корылмаларны, станцияләрне, ветеринария пунктларын тәэмин итү өчен акча җыю кергән. Хәрби бурычка килгәндә, бирелә сүз земство җыемы турында бара. Гаскәриләрнең Оренбург, Югары Урал һәм Троицк калаларыннан хәрби эш белән киткәндә тотылган чыгымнарын каплау, эш урыннарын, төрле биналарны җылыту өчен һәр казактан айга 51,4 тиен акча алынган.

Оренбургның нугай казаклары, болар өстенә, тагын натуралата да йөкләмә үтәгән, ягъни үз мал-мөлкәтләрен сарыф итеп, аерым хезмәтләр башкарган. Бу өчкә бүленгән: хәрби, гомумземство (гаскәр һәм губерна буенча) һәм станица йөкләмәләре. Беренче төркемгә станицада яшьләр белән кышкы күнекмәләр үткәрү, казакларны хәрби кием, кирәк-ярак белән тәэмин итү һ.б. карый. Икенчесенә юлны карау, торак, әсирләрне этап, почтаны конвой белән тәэмин итү, урман һәм далада янгын сүндерү керә. Соңгысы исә, иң күбе – почта йортүдә атлы хезмәт күрсәтү, станица идарәләрендә, икмәк кибетләрендә, урманда, мәктәп һәм чиркәүләрдә каравыл тору, терлекне аталандыру пунктларын, юл, паром, кичү урыннарын, көймәләрне, станица һәм поселок идарәләрен карап тору, корткыч хайван һәм бөҗәкләрне юк итү, җәмәгать биналарын төзү һәм төзекләндерү һ.б.дан гыйбарәт. Күп кенә казак авылларында почта йөртер өчен ямчылар ялланган, моңа, олы юлның торак пункттан ераклыгына карап, һәр нугайдан ел саен 3 сумнан 16 сумга кадәр акча алынган. Болар өстенә, казаклар урман кисү һәм сумала кудыру белән дә шөгыльләнгәннәр.

Шулай итеп, тарихи документлардан күренгәнчә, Оренбург казак гаскәрендәге нугайларның саны 1795 елдан (1836 кеше) 1865 елга (2660 кеше) ике мәртәбә диярлек, ягъни 44,9 процентка арта. Бу елдан соңгы документларда алар «мөселманнар» дип кенә теркәлә һәм аерым милләтләрнең санын Оренбург губернасының торак пунктлары турындагы һәм башка статистик мәгълүматлар ярдәмендә ачыкларга мөмкин. Нугайлар башка казаклар башкарган барлык төр йөкләмәләрне дә карусыз үтәгән, аеруча Россия дәүләтенең иминлеген, аның чик буендагы куркынычсызлыгын тәэмин итүдә зур хезмәт куйган.

Хәзерге вакытта Оренубрг өлкәсендә нугайлар Куандык районының Дубиновка станциясендә, Юлгут, Чулпан һәм Тау асты авылларында, Саракташ районының Никитин, Сары, Чишмә һәм Ирек авылларында яши. Ә Воздвиженск бистәсендә һәм кайчандыр үзләре үк нигез салган Кундрау авылында бүген нугайлар яшәми. ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

Ир-егетнең йөрәгендә иярләгән ат ятар!

Илдар Сафин

Атны беренче иярләгән халык безнең бабаларыбыз, төрки-татарлар булган. Мәгълүм ки, ат – заманында күчмә тормыш алып барган төркиләрнең аерылгысыз юлдашы. «Алар якты дөньяга ат иярендә туа, ат иярендә үлә яисә һәлак була. Аларның туган җире – ат ияре», – дигәннәр татарлар турында.

Татар аты башка токымнардан нәрсә белән аерыла соң? Беренчедән, тышкы кыяфәте үзгә. Татар атының биясе ачык-кола төстә, ак яллы һәм ак койрыклы була. Айгырның төсе – караңгы-кола, төгәлрәге, гәүдә буйлап алтынсу төсмерләр йөгергән ачык-туры төстә. Әлеге атлар, барыннан да бигрәк, үрчемле булулары белән аерыла. Аларның күкрәге киң, муены юан, башы зур, гәүдәсе саллы, аяклары кыска. Биеклеге – 135-145 см чамасы. Европа стандартлары буенча исә атның биеклеге 160-175 см булырга тиеш. Татар аты зәмһәрир суыкларны һәм 40-45 градуслы чилләне дә җиңел кичерә, алар өчен махсус ат фермалары да кирәкми. Шуның өстенә азыкка да талымсыз: кышын да тоягы белән тибенеп, кар астыннан үлән табып ашый ала. Татар аты, 7-8 сәгать дәвамында өзлексез хәрәкәт итеп, көненә 150-200 чакрым араны узарга сәләтле. Кыскасы, ерак арага чабышта аларга тиңнәр юк. Атилла белән Чыңгыз хан җайдакларының ияре астында шундый атлар булмаса, белмим, бөтен галәмне дер селкетүче каһарманнар турында без, гомумән, ишетер идекме икән?!

Революциягә кадәр татар атын «нугай аты» дип тә йөрткәннәр. Рус крестьяннары, аз ашый, дип, татар атларын сатып алырга тырышкан. Көненә 1-2 кг гына солы ашау өстенә, йоны тыгыз бу атлар сирәк авырган, әйткәнемчә, салкынга да бирешмәгән. Россиягә, Петр Iдән башлап, Европа атлары кертә башлыйлар. Зур, биек атлар исә көненә 5-6 кг солы һәм шул ук күләмдә печән ашый.

XX гасырның 30 нчы елларында, хуҗалыкларны күмәкләштерү чорында, колхозларга көчле атлар кирәк, дип, татар атларын сугымга җибәрәләр. Совет чорында Балтыйк буеннан, Европадан зур гәүдәле, авыр йөк атлары кайтарыла. Бүгенге көнгә кадәр сакланган колхоз атлары шуларның токымы була да инде. Узган гасырның 60 нчы елларында исә татар атлары да, бер үк вакытта «татар аты» исеме дә юкка чыга.

Бөгелмә районында яшәүче фермер Фәрит Мисбах улы Нәбиуллин, республикабызда беренче булып, татар атларын үрчетү белән шөгыльләнә башлады. Тарих укытучысы буларак, татар аты миндә дә зур кызыксыну уятты һәм фермердан 6 айлык тай алып кайттым. Хәзер аңа 2 яшь тула, аны атланып һәм җигеп йөрергә өйрәтә башладым.

Киләчәктә татар аты 20, 40, 100 чакрымлы ат чабышы бәйгеләрендә, Сабан туенда катнашыр, татарның, хәзергечә әйтсәк, «бренды» булыр, дип өметләнәм «Ир-егетнең йөрәгендә иярләгән ат ятар!» – дигән бит борынгылар. Нинди акыллы сүзләр! Милли гореф-гадәтләребезне саклау һәм яңарту эшенә керешәбез икән, әйдәгез, татар атларына да юл бирик!.. ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

ГОСМАНЛЫДАН ХИКӘЯЛӘР

СОЛТАН МОРАД БЕЛӘН ТИРЕ ОСТАСЫ

Көннәрдәнбер көнне Солтан Морад Хан IV[1], садразамы[2] белән бергә, башка киемнәр киеп, халык арасына базарга йөрергә чыккан. Болар бер кечкенә генә остаханә – кибет алдында туктаганнар. Остаханә бик ярлы халәттә, аның хуҗасы – тире остасы да бик карт вә мескен күренә икән.

Ошбу картлач – тире остасы кибет алдындагы кечкенә урындыкта утыра иде.

Падишаһ:

– Сәламуналәйкүм, тиречe, – диде.

[1]Солтан Морад Хан IV – 11 яшендә тәхеткә утырган, Госманлының 1623-1640 нчы елларда хөкемдары булган 17нче падишаһы.

Оста, килгәннәргә күз атып, тиз генә өстен башын төзәтеп:
– Аләйкүмсәлам, әй, Җиһан-ы Сәрдар[3], – диде.
– Җәйне кышка бер дә кушмадыңмы?
– Куштым, әмма берни килеп чыкмады.
– Яхшы, төннәрен бер дә тырышмадыңмы?
– Тырыштым, ләкин чит кеше алды...
– Ярый, сиңа бер каз җибәрсәм, йолкыйсыңмы?
Тире остасы:
– Йолкырмын, – ди. – Тавышы да чыкмас хәтта...
Падишаһ, тире остасы белән саубуллашып, кире сарайга кайта. Садразам, түзә алмыйча, әйтеп сала:
– Хөрмәтлем, – ди. – Тире остасы белән сөйләшүегездән берни аңламадым.
Падишаһның ачуы чыга, садразамга борылып:
– Син нинди садразам инде, шул әңгәмәне дә аңламагач?! – ди. – Хәзер үк ул оста янына бар, ни сөйләшкәнебезне сора. Әгәр аңлый алмасаң, тиз вакытта башыңны кистерәм! – ди.
Куркуга төшкән садразам, ашыгудан тыны кысылып, оста янына барып җиткән. Тире остасы да, садразамның килүен күргәч:
– Хуш килдегез! – дигән.
– Падишаһ белән ни сөйләшкәнегезне миңа тиз аңлат!
– Аңлатам, ләкин бер касә алтын бирәсең.
Садразам, башы киселү куркуыннан ризалашып:
– Әйт әле, килүченең падишаһ булуын каян аңладың? – ди.
– Падишаһ кыяфәтен алмаштырган иде, ләкин җиңсезен алмаштыруны бәлки оныткандыр, өстендә бик затлы тиредән җиңсез кием бар иде, андый җиңсезне падишаһ кына кия ала.
– «Җәйне кышка кушмадыңмы»сы – ни димәк?
– Аңлатам. Вәләкин тагын бер касә алтын бирәсең!
Садразам, мәҗбүр калып, монысын да кабул кылды.
– Падишаһ: «Җәйне кышка кушмадыңмы?» – дип сорады, ягъни җәй-кыш тырышып эшләмәдеңме, нигә кибетең болай ярлы диярга теләде. Мин дә: «Тырыштым, ләкин уңышлы килеп чыкмады», – дидем.
– Яхшы, – ди садразам. – «Төннәрен бер дә тырышмадыңмы?» – дип нәрсә сорады?
– Аңлатам, ләкин тагы бер касә алтын бирәсең!
Садразамның ачуы чыга, ләкин чарасы юк – кабул итә.
«Ягъни төннәрен тырышып, бала-чага үстермәдеңме, бигрәк тә, сиңа ярдәм итәргә улың булмадымы?» – дип сорады. Мин дә: «Тырыштым, ләкин улым булмады, кызым бар иде, аны да чит кеше кияүгә алды», – дидем.
– Яхшы, – ди садразам. – Падишаһ сиңа: «Бер каз җибәрсәм, йолкый аласыңмы?» – дип сорады. Монысы нәрсәне аңлата?
Карт оста, кулындагы касәләрне бераз өскә чөеп:
– Хе-хе-хе, анысын инде үзең аңла, садразамым! – дигән.

Cuma Vural, «Osmanlı'dan Hikayeler»,
Panama yayınları, Ankara, 2013.

*Төрекчәдән **Рәсим Хөснетдинов** тәрҗемә итте.* ■

[2] Садразам – баш вәзир, хәзергечә – премьер-министр.

[3] Җиһан-ы Сәрдар – Җиһанның баш гаскәре.

Безнең мирас №6 июнь 2017

БЕЗ – КӨРӘШЧЕЛӘР КАВЕМЕННӘН!

Айрат Галимҗанов

«Татар көрәше». XIX гасыр. Ф.Солнцев рәсеме

Көнчыгыштан килгән каратэ, кун-фу, токвандо, муай тай, вьет-во-дао Рәсәй һәм БДБ илләрендә модага әйләнгәч, кайберәүләр шул көрәшләргә нигезләнгән «борынгы» славян көрәшен уйлап чыгардылар (мәсәлән, «русский стиль», «челдон», «славяно-горицкая борьба» һ.б.). Бу ялган стильләр турында данлыклы ниндзя А.Тарас үз вакытында ачыктан-ачык язган иде.

Кун-фу мәктәпләре белән атаклы кытайлылар һәм төрки кабиләләр еш кына үзара сугыша торган булганнар.

Татар көрәшенең дошманны билдән тотып ыргыту алымын без кун-фуда «агач сындыру» исемендә таба алабыз...

Күчмә төрки кабиләләре, дәүләтчелекләрен алмаштырып, бер-берсе белән кушылып, аралашып яшәгәннәр.

Шуңа күрә дә нугай, башкорт, кырымтатар, казакъ, каракалпак кабиләләрендә бер үк ыру исемнәрен (кыпчак, мангыт, коңрат һ.б.) дә очрата алабыз...

Бу уртак төрки ырулар «казанында» яңа көрәш алымнары да туа. Нигә соң әле без бүген, урыс фальсификаторлары кебек, көрәш стильләрен уйлап чыгарырга тиеш, ди?!

Чынбарлыкта төрки кабиләләр көрәштә шулхәтле фәкыйрь булганмыни? Әлбәттә, юк!

Борынгы заманнардан хәзерге вакытларгача төркиләрдә сакланган көрәш төрләренә дикъкать итсәк, шөбһәләнүләребез шундук бетәчәк.

Татар эпосында көрәшчеләр шулай күрсәтелә:

«Яурыны киң олпатлы,
Суймырыктай сымбатлы,
Арбадан киң күкрәге,
Арыслан юан беләге».

(«Идегәй» дастаны, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1988, 111 бит.).

Халык дастанында Идегәй катнашкан бик күп җыен вә Сабан туе ярышлары һәм уеннары күрсәтелә. Бер бәхәстә Идегәй үзе турында шулай ди:

«Гөрелдәсәм, сугар яшенмен,...
Көрәшсәм, сине егармын,
Йөгерсәм, сине узармын».

*«**Идегәй уеннарын** ... бөтен җәмәгатьчелек хәл кылырга тиешле – безнең карашка, Татарстан Республикасы төзелү көненә туры китерергә мөмкин булыр иде».*

(Д.Р.Шәрәфетдинов, «Сабан туе», 1997, «Гасырлар авазы» редакциясе, Казан, 251 б.).

Татарлар кебек үк, һун-болгарлардан килеп чыккан балкар һәм карачайларның көрәш төрләре Төньяк Кавказ халыкларының көрәшенә нигез биргән.

Төркиләрнең һәм кавказлыларның Русия казаклары көрәшенә ясаган йогынтысы турында «Боевое искусство планеты» журналында (№8-10, 1993, 71 бит) шулай язылган: *«Рядом с казаками всегда жили «инородцы», то есть люди, казаками не являющиеся. Многие из них владели приёмами кулачного боя, перешедшими в «арсенал» казаков».*

Әүвәле **«тутуш» (тотыш)** көрәшендә иң беренче рольне көч куллану уйнаган – кем кемне көчлерәк кыса!

Көрәшкәндә көрәшчеләр үз көчләрен билгә бәйләнгән кушакка (сөлгегә) юнәлтәләр.

Һәр көрәшче бер кулын көндәшенең култык астына тыга, ә икенче кулы белән аркасындагы кушагын тота.

Хөкемдар сызгыргач, партнёрны башкача тотарга мөмкин, әмма бер кул һаман аның кушагын тотарга тиеш (киемнән тоту рөхсәт ителми).

Көрәшчеләр палас өстендә диаметры сигез метрдан да ким булмаган түгәрәк эчендә көрәшергә тиеш.

Көндәшне түгәрәктән тышка атып бәрү әле җиңүгә саналмый.

«Тутуш» алымнары төрле һәм бик күп: хәтта аяктан эләктереп егулар да бар (фәкать куллар белән генә көндәшнең аягын тотарга рөхсәт ителми).

Әдәбиятта карачайлар турында болай языла: *«Не было праздника без ... национальной борьбы «тутуш».*

Перед началом схватки борцы, подпоясанные ремнём, становились лицом к лицу, по сигналу захватывали друг друга за пояс и начинали борьбу. В процессе схватки борцам разрешалось освобождать от захвата одну лишь руку и применять ею любые захваты выше пояса, броски, перебрасывание противника через спину и т.д. ... можно было применять подножки и зацепы, подсечки и пр., не допускались только грубость и нечестность в поединке.

Боролись и стоя, и на одном, и на двух коленях, с захвата накрест на поясе и одной рукой через плечо». («Карачаевцы», Карачаево-Черк. отд. Ставропольского книж. издательства, Черкесск, 1978, отв. ред. док. ист. наук Л.Н.Лавров, историко-этнограф. очерк, стр.298). Гадәттә, көрәш, кагыйдәләренә карап, җиде минуттан да күбрәккә сузылмаган. «Тутуш» көрәшенең максаты – аякка басып калып, көндәшне аркасына салу (ташлау).

Карачай-балкар көрәшенә охшаган һәм Иделдән Уралга кадәр таралган татар көрәше дә бар, ләкин анда бик актив аяк хәрәкәтләре юк, ә билдәге сөлгене сул һәм уң яктан да тота алалар. Көрәшчеләр йомшак аяк киеме, киң чалбар киеп, күлмәк белән яисә күлмәксез дә көрәшә алалар. Татар көрәшенең максаты – «дошман»ны аркасына салу. Көрәш сигез минут дәвам итә ала.

XIX гасырда Казан татарлары тормышы белән танышкан алман галиме Карл Фукс болай язган: *«Татары, разумеется, из простонародия, также большие охот-*

ники до кулачного боя... Весною и осенью, в хорошую погоду, под вечер, собираются на берегу озера Кабана кулачные бойцы. Татары с криком толпою нападают на русских, и тут атаки их редко проходят без окровавленных лиц. Я заметил, что в этом боксировании татары имеют преимущество перед русскими бойцами...» (Карл Фукс, «Казанские татары», 21 стр.).

Әстерхан һәм Ставрополь өлкәләрендә, Чечня вә Дагыстанда яши торган нугай татарлары хакында болай хәбәр ителә: *«Большой популярностью среди детей и юношей пользовалась борьба* ***«куьрес»****. Боролись на поясах. Схватка проводилась на травяной площадке и продолжалась до победы одного из борцов. Ногайская национальная борьба «куьрес», как и у многих других народов, проводилась без учёта весовых категорий соревнующихся. В национальную борьбу входили различные подножки и зацепы, броски стоя и с падением, многочисленные повороты и «кружение» противника. Победителем считался тот, кто заставлял противника коснуться лопатками земли (шалкасыннан салув)»* («Проблемы этн. истории народов Карачаево-Черкессии», «Традиционные виды игр у ногайцев», Б.Х.Калмыков, Черкесск, 1980, стр. 151).

Тува (Тыва) төркиләре февраль аенда үз Яңа елларын каршылаганда да көрәш ярышлары уздыралар. Буддачы һәм шаманчы тувалылар өчен көрәшү осталыгы бик әһәмиятле, хәтта моның йогынтысы тувалылар фольклорында да чагыла. «Аю улы» әкиятендә, мәсәлән, Аю улы ике дошманны җиңәр өчен ике мәртәбә йөз иллешәр көн (!) көрәшә. Тувалылар үзләренең **«хүреш»** дигән көрәшләрен бик ярата. Көрәшче киеме: тиредән тегелгән плавки, тире һәм комачтан тегелгән куртка («содак»), милли йомшак итекләр.

Көрәшү алдыннан көрәшчеләр **«дәүеш» (бөркет)** дигән матур бию бииләр. Бу бик тиз һәм кызу биюдә көрәшчеләр үз тизлеген, көчен күрсәтергә тиеш.

«Хүреш» кагыйдәләре буенча көрәшкәндә кулларга да, аякларга да, плавкига да, курткага да тотынырга рөхсәт ителә. «Хүреш» 6 минут дәвам итә, ә финалда – 10 минут. Җиргә атылган яисә тезе җиргә тигән көрәшче «җиңелгән» дип санала. Җиңүче җиңелгән көрәшчегә җирдән күтәрелергә булыша һәм аннары «дәүеш» (әдип Рабит Батулла Татарстандагы Дәвеш авылының исеме бу төшенчәдән чыгу ихтималын белдергән иде) биюен биеп чираттагы көндәшенә юнәлә.

Кайбер галимнәрнең (мәсәлән, Әбрар Кәримуллинның) исбатлавынча, борынгы бабалары төркиләр булган Төньяк Америка индеецларында да көрәш биюләре бар. Мисалга, пикуни һәм шауни исемле кызыл тәнле кабиләләрдә **«бөркеткә каршы аю»** дигән бию бар. Мондый биюләрдә, көрәшчедә берәр (алар өчен изге булган) хайван җанын уяту өчен, шаманчылык чаралары кулланыла. Ирокезлар Лигасында да бәрүсез көрәш бар («Кэмпо» журналы, Минск, 1996, №6).

Саха-Якут илендә исә милли **«хапсагай»** көрәше һәм кушакларда көрәшү киң таралган. «Хапсагай» якут көрәше хакында якут риваятьләре һәм әкиятләрендә бик күп сөйләнә, җөмһүриятнең мәшһүр шагыйрьләре һәм язучылары бу хакта күп язалар. «Хапсагай» сүзенең тәрҗемәсе – җитезлек. Якут көрәшенең кагыйдәләре буенча, көрәшчеләр «ровдуга»дан (йонсыз поши тиресеннән) ясалган бандаж кебек плавки һәм йомшак итекләр кияләр. Көрәшкәндә аякларны да, һәр әгъзаны да тотарга рөхсәт ителә. Ике көрәшче каршы почмакларга баса. Арбитр сызгыргач та, бер-берсенең кулларын кысып, артка икешәр адым атлап, көрәшне башлыйлар. **«Вольная борьба»** дигән көрәш якутның «хапсагай»ыннан үзенә күп алымнар алган: «аяк эләктерү», «кул астына чуму», «үзе егылып, партнерны да ташлау» һ.б. Көрәшнең максаты – көндәшне ике кулы яисә тез белән җиргә (келәмгә) тидерү. Әгәр көрәшүчеләрнең икесенең дә куллары, яисә тезе берүк вакытта җиргә тисә, көрәшне яңадан башлыйлар. Көрәш 10 минут дәвам итә.

Н.М.Галковский классификациясе

буенча, саха-якут «хапсагай»ы һәм тува көрәше бер үк төркемгә – «актив аяк хәрәкәтләре һәм бил астында тотулар белән торып көрәшү» төркеменә карый.

Казакъларның **«күрес»**ендә көрәшчеләр бер-берсенең кушакларын тотып көрәшәләр. Аяк чалулар рөхсәт ителә. Көрәш киеме: кушак белән трусик яисә күлмәк белән милли халат (бишмәт). Көрәшнең максаты – көндәшне аркасы белән җиргә (келәмгә) салу. Көрәш 15 минут дәвам итә.

Кыргызларның **«күреш»**ендә көрәшчеләр бер-берсенең кушагын бер кулы белән тотып (көрәш дәвамында кул кушактан ычкынмаска тиеш) көрәшәләр. Икенче кулы белән исә билдән югары теләсә кайсы урынны тотарга мөмкин. Кием: йомшак кушаклы милли кыргыз халаты. Көрәшнең максаты – көндәшне аркасына аударып салу. Көрәш 15 минут дәвам итә.

Төрекмәннәрнең **«гөреш»**е дә шулай үтә: партнерлар бер-берсенең кушагын һәм билдән югарырак тотып көрәшәләр, көндәш аякларына хәрәкәт (эләктерүләр) рөхсәт ителә. Кием: тезгә кадәр кыска милли халат (бишмәт). Көрәшнең максаты – көндәшне аркасы белән җиргә ташлау (өч ноктасы белән җиргә, келәмгә тидерү).

1403-1406 елларда Урта (Үзәк) Азиядә булган испан илчесе Рюи Гонсалес де Клавихо төрки көрәшчеләрнең хан алдында көрәшүләрен болай язып калдырган: «Хан каршысында җиңсез күн җилән кигән ике көрәшче чыгып басты. Алар озак кына көрәштеләр, тик берберсен ега алмадылар... Ниһаять, берсе икенчесен җиргә егып, аны торалмастай итеп тотып торды. Әгәр дә ул торса, көрәш яңадан башланачак иде».

Күргәнебезчә, төрекмәннәрнең «гөреш»е, нугайларның «куьрес»е, казакъларның «күрес»е, кыргызларның «күреш»е һәм балкар-карачайлыларның «тутуш»ы бер үк төркемгә карый.

Азәриләрнең **«гюлеш»**ендә партнерларга чалбарларны, гәүдәнең теләсә кайсы урынын да тотарга рөхсәт ителә. Кием: йомшак кушак белән тездән бераз төшебрәк торган каты чалбар. Төркия һәм Азәрбайҗанда көрәшчеләр кайвакыт тәнне май белән сөртәләр. Көрәшнең максаты – көндәшне аркасы белән келәмгә «яткыру». Көрәш 10 минут дәвам итә.

Төркиядә борынгы **«аба гүреши»** (Aba güreşi; Turkish jacket wrestling) буенча ярышлар үткәрелә; аларны оештыра торган активистлар – Лютфю Саваш (Doç. Dr. Lütfü SAVAŞ, Antakya Belediye Başkanı) һәм Ибрахим Озтек (İbrahim ÖZTEK).

Үзбәкләрнең (Фирганә кагыйдәләре буенча) **«кураш»** дигән көрәшендә партнерлар көч кулланып (әмма актив аяк хәрәкәтләре ясамыйча гына), кушакларга тотынып көрәшәләр. Көндәшнең кушагын уң кул белән (көрәш дәвамында!), ә сул кул белән киеменең теләсә кайсы урынын тотарга мөмкин. Кием: йомшак билбау белән озын милли үзбәк халаты. Көрәшнең максаты: партнерны җирдән күтәреп аркасына ташлау. Көрәш дәвамында милли көй уйнатыла. Көрәш 10 минут дәвам итә. Үзбәк «кураш»ы татар-башкорт көрәше белән бер үк төргә – «аяк хәрәкәтләреннән башка һәм аякны кул белән тотмыйча үткәрелә торган көрәшләр» төркеменә керә.

Үзбәкләр көрәшне бию-разминкадан соң гына башлыйлар (бу кагыйдә Тува төркиләрендә дә бар). Нугайлар белән бер төбәктә яшәгән мөселман чеченнарга дикъкать итсәк, аларның **«зикр»** биюе, медитация буларак, көрәшүчене психологик яктан бик әйбәт әзерли һәм ике яисә берничә (!) сәгать дәвам итә ала; кайвакыт «зикр»дә хатын-кызлар да катнаша. Үткән гасырда татар яшьләренең **«Азатлык»** берлеге татар көрәше буенча ярышлар оештыра иде. Килер вакыт, бәлки, бөтен төрки халыкларының көрәшләрен дә кертеп, төрки Олимпиадасын да үткәрә алырбыз. 2011 елда Бөтендөнья көрәш чемпионатына башкалабыз Казанга күп дәүләтләрдән спортчылар килгән иде: Казакъстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Молдова, Беларусь, Иран һ.б. ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Семипалат мәчете

ҖИДЕТАШ – СЕМИПАЛАТ

Алма-Атадан соң Капал, Аягүз (Сергиополь) калаларын үтеп, Семипалат шәһәренә килеп җиттем. Бу ике төбәк арасындагы җирләрдә күчмә тормыш белән көн итүче казахлар яши. Күчеп килеп утырган христиан авыллары да очрый, ләкин алар аз санлы. Биредә дә ногайлар, сартлар, кытай-дунганнар бар. Ләкин күпчелекне барыбер казахлар тәшкил итә һәм төбәкнең төп хуҗалары булып алар санала.

Семипалат атамасы «җиде таш» дигәнне аңлата. Бу шәһәр урнашкан җирдә җиде таш булган, дип сөйлиләр. Бүгенге көндә Семипалат урынына Семи атамасын кулланучылар да бар. Халык, үзара сөйләшкәндә, шәһәрне бары тик Семи дип кенә атый. Җидеташ атамасы бөтенләй кулланылмый. Ләкин шул ук вакытта мөселманнар арасында Семиречинскины Җидесу өлкәсе дип атау киң таралган.

Семипалат халкы моннан 40-50 еллар элек бөтенләе белән мөселман булган, болар Казаннан һәм Русиянең эчке төбәкләреннән күчеп килеп утырган нугайлар икән. Бары тик бер мәхәлләдә генә Бохарадан күчеп килеп утырган халык яшәгән. Бүгенге көндә исә, Семи-

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

палатта руслар бик күп, мөселманнар белән чагыштырганда сан ягыннан өстенлек алар ягында.

Мөселманнар арасында да бай һәм акчалы кешеләр күп, алтын приискалары тотучы мөселманнар да бар. Ләкин шулай булса да, бу эшләрне йөртүче кешеләрнең күбесе христиан. Мөселманнарның бер өлеше суфыйлык, икенче өлеше исә сәрхүшлек аркасында байлыкны кулларыннан ычкындыралар, бөтен байлык чит халык кулына күчеп бетеп бара.

Кызганыч, йөз, мең тапкыр кызганыч, Семипалат кечкенә генә шәһәрчек булса да, бүгенге көндә биредә алты зур сыра заводы эшли. Болар пар һәм электр көченнән файдаланып, көнетөне, өрөзлексез сыра эшләп чыгарып торып та, Семипалат халкына чак-чак кына җиткереп баралар. Семипалат заводлары җитештергән сыраның бер тамчысы да читкә җибәрелми, хәтта җәй көннәрендә, киресенчә, бирегә сыраны читтән дә китертәләр. Күп вакыт, бигрәк тә бәйрәмләрдә кайбер йортларда бу заводларның акрын эшләвеннән зарланучылар да була икән.

Семипалат мөселманнары дингә шактый нык бәйлеләр һәм элекке заманнардан калган гадәтләрнең үзгәртелүен, бозылуын һич тә яратмыйлар. Хатыннары хәтта 35-40 дәрәҗә эссе җәй көннәрендә дә кыйммәтле кеш, кара төлке, тиен тиресеннән тегелгән өс киемнәре кияләр һәм моның белән горурланалар. Колакларына катлы-катлы алкалар асалар, бармакларына әллә ничә йөзек-балдак кияләр һәм өс-башлары төрле-төрле зиннәтле бизәнү әйберләре белән туп-тулы була. Ә инде гыйлем һәм мәгарифкә килсәк, берни юк. Мәктәп тә юк, мәдрәсә дә юк, дисәк тә дөрес булыр. Израиль улларыннан калган мөселман кирәк булса, нәкъ менә Семипалатта эзләп таба аласыз.

Тик соңгы биш ел эчендә Семипалат мөселман яшьләре кинәт кенә рус мәктәпләренә кереп тулганнар. Моннан ун еллап элек рус мәктәпләрендә бер генә мөселман баласы да булмаган, хәзер исә 30-40 бала рус мәктәпләрендә укый икән. Семипалат мөселманнарын әхлак бозыклыгыннан коткарып калачак әфәнделәр менә шулар инде.

Семипалат шәһәре Иртыш елгасы буена, шактый уңдырышлы җирләргә урнашкан. Бу төбәктән җыеп алынган ашлык бөтен Русиягә, хәтта Аврупага кадәр җибәрелә. «Сырьё»[1] дип йөртелә торган төрле хайван тиреләре белән сәүдә итү Русиянең иң зур сәүдә төрләреннән берсе булып тора. Бу сәүдә дә тулысынча Себер татарлары кулында.

Семипалат каласында мөселманнарның тоткан урыннары нык, киләчәкләре якты. Ләкин бу хөрмәтле урыннарын саклап калыр өчен, холык-табигатьләренә акрынлап сеңә барган әхлак бозыклыгын һәм исерткеч эчемлек куллану кебек начар гадәтләрне мөмкин кадәр тизрәк юк итәргә тырышырга кирәклеге көн кебек ачык. Биредә, кайчандыр бик бай булып та, бүген әхлак бозыклыгы аркасында банкротлыкка чыккан кешеләр дә очрый. Әлегә эшләре бер җайга бара торган байлар исә, болардан гыйбрәт алып, үз киләчәкләрен уйлап, үлчәп, фикер йөртеп карарга тиешләр.

ТАРА

Семипалаттан Иртыш елга юлы буйлап, Коряков (Павлодар) һәм Омск шәһәрләрендә туктый-туктый, туган җирем һәм төп ватаным булган Тара каласына килдем. Тара – алты мең тирәсе кеше яши торган кечкенә генә шәһәрчек. Болар арасында мөселманнар иң күп дигәндә 200-300 йорттыр, мөгаен.

Чынбарлыкта, Тара – бик борынгы кала, кайчандыр сәүдә үзәге дә булып торган. Тарадан Кызылъяр (Идел), Акмолла (Астана), Төркестан юлы белән Бохарага һәр ел саен хәтта кәрваннар барып кайта торган булган. Мәшһүр шәркыять белгече Ядренцев Себер татарлары хакында мәгълүмат биргәндә, Тара

[1] Бу сүзне «сыромять» урынында кулланган булса кирәк (тәрҗ. иск.).

Тара

сәүдәгәрләренең Себердән Әҗәмстан (Персия, Иран) юлы белән Һиндстанга кадәр барулары турында яза. Моннан тыш, сәясәтчеләрдән һәм икътисадчылардан торган бер төркемнең 1664 нче елларда Мәскәү хөкүмәте тарафыннан Пекинга җибәрелгәнен һәм бу төркемдә Тара сәүдәгәре Абин дигән кешенең дә булганын искә алып үтә. Сәүдәгәрлектә алга киткән булганга, Себер татарларын әле ул заманнарда ук гаскәри хезмәттән азат итү, салымнарын азайту турында хөкүмәт карары кабул ителгән була. Әлеге карарның салымга кагылышлы өлеше үзгәргән булса да, гаскәри хезмәт белән бәйле өлеше бүгенге көнгә кадәр үзгәрешсез кала килгән.

Хәзерге көндә бөтен Көнбатыш Себернең, бигрәк тә Тара каласының, ни икътисади, ни сәяси яктан, бернинди әһәмияте дә калмаган. Тимер юл челтәреннән еракта калуы сәбәпле, инде бу төбәк бөтенләй көчсезләнеп бара.

Тара төбәгендә 35-40лап мөселман авылы бар иде, инде алар да Төркиягә күчеп китәргә карар кылганнар. Әгәр дә алай була калса, Тара белән моннан соң бөтенләй бәйләнешебез калмаячак. Бары тик ватаныбыз булганга, ап-ак яуган кар өстендә яхшы атлар белән айлы төннәрдә икешәр-өчәр йөз километр араларны узып ил гизүләребез, манаралар кебек күкләргә сузылган төз нарат агачлары арасында бик күп тапкырлар җәнлек аулауларыбыз, җәй көннәрендә Иртыш елгасы буйлап зур-зур пароходларда сәяхәтләребез бераз вакытлар хәтерләребездә сакланыр, дип уйлыйм.

Менә шул төп ватаным булган Тара каласында өч атналап яшәгәннән соң, гаиләмне алып, барыбыз бергә Тобольск, Төмән, Пермь юлы белән Казанга килдек. Мин төп зур сәяхәтемне биредән башлаячакмын. Казанда бер өй арендалап, балаларны шунда калдырырга уйладым. Киткәнче, өйгә әйберләр алып калдырырга кирәк иде. Тырыша торгач, бар нәрсә дә булды.

Бу эш-мәшәкать белән бергә, күңелдә озак вакытлы сәяхәт планы да төзелеп ята иде. Гаиләмне, җан ияләрен ризыкландыручы һәм көч-куәт иясе Хак Тәгаләгә тапшырып калдырып, шактый озак вакытка чит җирләргә китәчәкмен. Аерылып китүне үзем өчен генә сайламавымны, балаларымны да туган җирдән еракларда калдырып китәчәгемне уйлап, шуларны күз алдына китерә идем.

Озак вакытка сузылачак сәфәргә китәм. Өй кирәк-яраклар белән тәэмин ителде. Бер айлык аренда акчасын да түләдем, гаиләмә көн итәр өчен түләнә торган акча мәсьәләсе дә хәл ителде. Ләкин үзем өчен сәфәргә чыгарлык акча таба алмавым юлны тоткарлап тора иде. Бурычка алырга дигән карарга килдем дә бер дустымнан 20 сум акча алдым. Башка берәр төрле комачау туганчы тизрәк юлга чыгарга кирәк, дип тырыша идем. Ул көнне Русиянең башка-



«Россия» кунакханәсе. Омск. 1907-1910 еллар

ласында чыга торган газеталар Дәүләт Думасының шәрекъ мәсьәләсе буенча катгый карар кабул итәчәген хәбәр итте. Ислам дөньясында моннан тыш та өметсезлектән башка берни юк иде. Төркиядәге инкыйлабның нәрсә белән тәмамланачагы ачык билгеле. Без дә, уйлана торгач, тәкъдирдә язган бу шәрекъ мәсьәләсенең бер нәтиҗәгә китереләсенә инанган идек. Ләкин шул ук вакытта мин Госманлы каһарманнарының һичшиксез соңгы сулышкача җаннарын фида кылачакларын күз алдында тота идем. Шул фикергә нигезләнеп, мин дә карлыгачның авызына кабып Нәмрут утына су ташуын искә төшердем дә Ерак Көнчыгышка таба хәрәкәт итүне кирәк дип таптым. Озын сәяхәткә чыгарга, дип, күңелемнән хәл итеп куйган идем һәм бу хакта миннән башка беркем дә белми иде. Гаиләм дә хәтта сәфәремне Уфада, иң ерагы Омскида тәмамланачак дип белә иде. Мин исә, аерылу хәсрәте белән тарткалаша-тарткалаша, әледән-әле *Нар-ы фиркатьлә дөнүп пәрванәйә, бәнзәдем һәр хәл илә диванәйә* «Аерылу ялкыны тирәли әйләнә-әйләнә очкан төн күбәләгедәй, бөтен хәлторышым белән диванага әйләндем» юлларын кабатлап тора идем.

Беркөнне улым Әхмәтмөнир, хәлне сизгән кебек, борчулы тавыш белән: «Әткәем...», – дип, кулындагы акчаларны миңа бирергә теләде, күзләре яшьле иде. Минем дә күз алларым караңгыланып китте. Акчасы күпме булгандыр, аны белмим: «Улым, сеңелләреңне ташлама ...» дидем, башка сүз әйтергә хәлем калмады. Икенче ягымда кызларым, һичбервакыт еламаган балалар, ул көнне көне буе елаштылар.

Шулай итеп, мөбарәк рамазан-ы шәриф аеның 4 нче көнендә юлга чыгачакмын. Юлга вак-төяк, кием-салым хәзерләнде. Кызым Кадрия атлы арбачы чакыртты, арбага әйберләремне урнаштырдылар. Мин, тере мәет кебек, капкадан чыгам, ике кызым муеныма сарылып елашалар иде.

Утырам дигәндә, Кадриям: «Әти, 4 сум акча кирәк», – диде. Юлга дип әзерләнгән 20 сумнан 4 сумын алып, кызымның кулына тоттырдым. «Аллага әманәт булыгыз», – дип, арбага менеп утырдым да кузгалып китеп бардык.

Юлда барганда, кая китеп баруымны һәм нәрсә өчен баруымны уйлый идем. Әйләнеп кайта алырмынмы, юкмы – ул да билгеле түгел. Атлы арбада пристаньга килеп җиткәндә инде пароход хәзер иде. Пароходка утырып, хәзер үк Уфага китеп барачакмын.

Төрекчәдән
Асия Рәхимова тәрҗемәсе. ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

РАМАЗАН РУЗАСЫ

Мулла Галимҗан бине Мөхәммәдҗан әл-Баруди

Бәндәнең вазифасы – үзенең бәндәлеген тану. Ялгыз тел белән икърар кылу гына түгел, ә гамәлләре белән үзен Аллаһының колы итеп күрүдер. Бәндәнең үз дәрәҗәсен тануы – аның өстенлеге вә изгелегедер. «Кем үзен белсә – Раббысын таный алыр», – дигән мәшһүр мәкальнең дә (гәрчә хәдис булмаса да) хикмәтле сүз булуы аңлашыладыр. Бәндәнең хуҗасы, барлыкка китерүчесе, Раббысы, Илаһысы булган охшашсыз һәм тиңдәшсез Аллаһы – рәхимле вә хикмәтледер. Аллаһы һәркайсы мәхлукына миһербанлыдыр. Һәр бәндәсе үз әсәре, үз иҗаты булганга, һәркайсына да хәерхаһтыр. Бигрәк тә, аның илаһилыгын таныган, берлегенә ышанган бәндәләренә, аны дус таныганнары һәм коллык килешүләрен саклаганнары өчен, һәрвакыт рәхмәт карашын салучы, аларны һидаяте вә гүзәл тәүфыйгы белән бәхетле итүчедер.

Аллаһы – бәндәләренә миһербанлыдыр, аларның мәңге бәхетле булуларын теләүче, аларга даими рәвештә шул бәхет юлын күрсәтүчедер. Мәңгелек бәхетнең юлы – Аллаһы күрсәткән рәвешчә рухны тәрбияләү вә аны гәүдә әсирлегеннән коткару һәм шул гәүдә белән капланган изгелек һәм бөеклек мөмкинлекләрен ачу вә арчу юлыдыр. Һәм, гомумән, рухның дошманнары – гәүдә хезмәтчеләре вә ярдәмчеләре булган начарлыкка чакыручы нәфес һәм шәйтан тозакларыннан аны коткарып, Коръән идарәсенә бирү юлыдыр. Бәндәне Аллаһының ризасына ирештерә торган юл – ошбу юл гына. Бәндә бәхетне шушы юлда гына таба ала. Үзенең Раббысына, хакыйкый хуҗасына, кәфил-әмине булган Мәүләсенә[1] тәмам тапшырылуда, аны тәмам тыңлауда гына таба ала. Аллаһының боерыгы вә тәрбиясе каршысына үз фикерен, үз акыл әсәрен куйды исә – начарлыкка өндәүче нәфсесе вә шайтанның фикерләрен катыштырган булып, дөрес юлдан тайпылган, һәлак вә бәхетсезлек юлын тоткан буладыр. Аллаһы сакласын!

Аллаһының Ислам өчен булган биш нигезе – тәүхид, намаз, руза, зәкәт, хаҗ – бәндә өчен иң мөкатдәс вазифа, бәндәлек өчен иң олуг билге вә галәмәттер. Бигрәк тә, ошбу көннәрдә бөтен ислам галәмен зурларга торган рамазан рузасы бәндәнең сәгадәте, рухын куәтләндерү һәм яхшы тәрбияләү өчен иң файдалы булган, илаһи бер сер булган мөкатдәс гыйбадәттер. Рухның тәрбиясе, калебнең сафа вә сәламәте, аларны гәүдә хуҗалыгыннан чыгарып вә хезмәтчелек дәрәҗәсеннән күтәреп, хуҗалык дәрәҗәсенә ашыру вә күтәрү белән генә була. Шунлыктан, Аллаһы Тәгалә Үзенең мәрхәмәте вә хикмәте белән бәндәләренә ошбу рузаны васыять иткән, вакытлы рәвештә тәнне чикләп, рух вә калебне тәрбия итү юлын күрсәткән. Бу рузада булган файдалар

---

* Автор язганча бирсәк, хәзерге заман укучысына аңлау-төшенү катлаулы булу сәбәпле, текст тулысы белән татар әдәби теленә күчерелде, әмма авторның вәгазь стиле сакланды.

[1] Кәфил-әмине булган Мәүләсенә – Аллаһның сыйфатлары һәм исеме.

«Иманлы авыл хатыны кызу һәм озын көннәрдә руза тотып иген эшен башкара...»
Уфа губернасы крестьяннары. М.А.Курковский фотосы. XX гасыр башы

кеше үзе аңлап бетермәслек дәрәҗәдә булганга күрә: «Руза – Минем өчен, аңа бүләкне мин Үзем әзерлим», – дигән ишарәсе белән чикләнеп, үзен чын бәндә итеп таныган, Аллаһының үзенә илаһ икәненә ышанган калеб ияләренең игътибарларын җәлеп иткән. Аңлаганнар никадәр бәхетледер!

Руза – ашау-эчү кебек нәфсе ләззәтен вә тән тәрбиясен, Аллаһы ризасы өчен, вакытлы калдырып торудыр. Бар уе вә тормышы тамак вә шәһвәт өчен булган кешегә бер дәрәҗә авырлыктыр. Ләкин бәндә үзенең барлыкка китерүчесен һәм Раббысын таныса, аның бөеклеге вә фәрманы алдында тез чүгәчәк, муенын иячәк, Аллаһы тарафыннан бирелгән куәт вә тәкатен Аның ризасы юлында сарыф итәчәк, үзенең мөселманлыгын исбат итәчәк.

Руза бу елларда бик озын көннәргә туры килә, Аллаһы шундый озын көннәрдәге мәшәкатьле вакытлардагы руза белән бәндәсен имтихан итә вә аннан итагать һәм буйсыну көтә, Үзе

Көннәрнең озынлыгы һәм кызулыгы, эшләрнең күплеге һәм авырлыгы – руза боерыгын җилгә очыртырлык, һәр бәндә өчен яхшылык теләүче Аллаһының боерыгын игътибарсыз калдырырлык гозерләр түгелдер.

биргән көч-куәтне Үзенең ризалыгы юлына сарыф итүне тели, бәндәнең шул авыр көннәрдә сабырлыгына, итагать вә яхшы буйсынуына каршы чиксез әҗер вә саваплар, ялгыз үзе генә белә торган серле әҗерләр әзерли. Бер вөҗданлы кеше үзенең берәр дусты өчен авырлык күтәрергә, аның күңеле өчен шактый фидакярлек кылырга әзер тора һәм шул хезмәтеннән вә хөрмәтеннән үзе куана, бер кешелек вазифасын үтәгәнгә йөрәгендә байтак рәхәтлек таба.

Инде бәндәнең барлыгын, бөтен кыйммәтле әгъзаларын, тормышы өчен кирәк нәрсәләрне Аллаһы Тәгалә биргән, башыннан аягына кадәр бәндә Аның нигъмәтенә гарык булган, сәгать саен,

Синең руза сәбәпле башың авыртсын, хәлең азайсын яки һушың китсен – бу хәлләр кем өчен булган, кемнең ризасы юлында булган? Шуны уйла да, куан, бу хәлеңә шөкер ит.

хәтта һәр сулышында йөз вә мең яктан Аның караш вә шәфкатенә мохтаҗ булып тора.

Хәл шулай икән, чын изгелек теләүче вә дусты булган Раббы, һәр эштә ярдәмчесе булган Халик вә Мәгъбүд[2] бу зәгыйфь вә кимчелекле бәндәгә карап: «Мин биргән көчеңне минем юлымда сарыф ит, минем дошманым булган шайтан вә нәфескә каршы тор, бер ай кадәр руза тот, шул сәбәпле рухыңны, йөрәгеңне төзәтерсең, мәңгелек бәхеткә ирешерсең», – дип әйтә. Инде бәндә нинди йөз белән ошбу боерык вә олуг әмерне җиңел тота, илтифатсыз каршы ала? Нинди вөҗдан вә инсаф белән үзен бу изге боерыктан читтә калдыра? Төрле шайтан котыртуына бирелә, юкбар хыялларны үзенең нәфсе теләгенә сәбәпче итә? Укымаган-пешмәгән ярты муллаларның, диннән чын ләззәт алмаган бозыкларның, Аллаһыга бәйләнештән бихәбәр булган бозучыларның тавышларына колак салып, тозакларына эләгеп, бөек сәгадәттән мәхрүм кала?

Көннәрнең озынлыгы һәм кызулыгы, эшләрнең күплеге һәм авырлыгы – руза боерыгын җилгә очыртырлык, һәр бәндә өчен яхшылык теләүче Аллаһының боерыгын игътибарсыз калдырырлык гозерләр түгелдер. Бәндәдә иман булса, һәр авырлыкны да күтәрә, бәлки аннан ләззәт ала, үзендә иман әсәрен күреп куана. Иманлы авыл хатыны һәм ире кызу һәм озын көннәрдә руза тотып иген эшен башкара, чиксез авырлык килердәй булса, сәхәрдән көн кызганчы эшләп, кызуда ял итә, дөнья эше бар, дип, динен бозмый, диннең бер олуг терәгенә хыянәт итми. Безнең аз-маз укыган, дин һәм милләт исемнәрен телләренә күп алган, алдагы көндә өметле яшьләребездә һәм кайбер ялкау картларыбызда шулкадәр иман юкмы? Шул авыл хатыны кадәр дингә гайрәтлелек юкмы? Диннең бер олуг рөкенен сакларлык тырышлык, чыдамлык һәм омтылу юкмы?

Синең руза сәбәпле башың авыртсын, хәлең азайсын яки һушың китсен – бу хәлләр кем өчен булган, кемнең ризасы юлында булган? Шуны уйла да, куан, бу хәлеңә шөкер ит. Аллаһы ризалыгы, боерыгын һәм шәригатен җиренә китерү юлында башың авырткан, һушың киткән. Ай-һай! Чын иманлы бәндәләр Аллаһы ризасы өчен каннарын агызганнар, җаннарын биргәннәр, мал-мөлкәтләрен корбан иткәннәр. Син исә аз-маз авырлыкны сылтау итеп, шәригатьнең рөкенен, Аллаһының боерыгын җимермәк буласың, нәфсең рәхәте, шайтан хезмәте һәм хөрмәте өчен төрле вәсвәсәләрне игътибарга аласың, шөбһәсез ачык булган бер хөкемне караңгы шөбһәләргә кертеп, бичара мөселманнарга шикләндерү саласың. Гайрәт кирәк, ышанган динеңне саклау кирәк, ышанган Раббың һәм Мәгъбүдең боерыгын сакларга һәм саклатырга иҗтиһад кирәк.

Рамазан аенда хуҗаларга, ислам шәрәфен саклаган байларга хезмәткәренә мәрхәмәт итү кирәк. Шулай ки, хезмәтләрен мөмкин кадәр җиңеләйтү, ашау-эчүләрен яхшыландыру, эш хакларын арттыру яки бүләкләр вә мөкәфәәтләр (премия) белән шатландыру тиеш.

Аллаһы динен хөрмәтләгән вә дин эшендә ярдәмче булган кемсәләргә рәхмәт кылгай.

«Әд-дин вә әл-әдәб» – 1916. – №11

Текстны басмага ***Фатих Хәбиб*** *әзерләде.* ■

---

[2] Халик вә Мәгъбүд – Аллаһының исемнәре.

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН гыйбарәләре

• Ирләрнең хезмәтләре өй тышында булса, рәхәтләре вә күңел ачулары үз гаиләләре янында, өй эчендә булырга тиешле.

• Инсаннарның гомерләре сәүдәгәрләрнең капиталына охшый. Сәүдәгәрнең мал-мөлкәте күп булса, шул нисбәттә файдасы да күп, әмма капиталы аз булса, шул нисбәттә файдасы да аз була. Адәмнәр гомерләрен зая итсәләр, мал-мөлкәтләре, шуңа күрә файдалары да заигъ буладыр.

• Әгәр дә иман рәсми калимәләрне генә телдән укудан гына гыйбарәт булса иде, бу көндә имансыз адәм булмас иде.

• Бурычны сораган вакытта йомшаклык вә шәфкать күрсәтергә кирәк.

• Каберләр хөрмәтле тотылырга тиешле.

• Ялкаулык – вакытны, форсатны исраф итү. Малны исраф кылу бозык эш булса, вакытны вә форсатны исраф итү бигрәк тә бозык эш булыр.

• Комсызлык вә дөньяның затын сөюлек кайгы вә хәсрәтләрне арттыруына шөбһә юк.

• Малны табарга мөмкин, әмма үтеп киткән вакыт вә форсатны кире кайтарып алырга мөмкинлек юк.

• Аз ашау вә аз йоклауның файдалары күп. Шул файдалардан бере исә вакыт күбәюдер.

• Вакыт бик күп, гомер бик озын, ләкин бу вакытлар вә гомерләрне без файдасыз вә мәгънәсез нәрсәләргә сарыф итәбез. Әгәр дә сарыф итә белеп сарыф итсәк иде, вакытның иркен вә гомернең озын икәнлеген хәтта үз күзебез белән күргән дәрәҗәсендә булыр иде.

• Һәркем үз ризыгын үзе табарга тырышмавы вә туксан кешенең ун кеше өстенә йөк булуы сәбәбеннән, милләтебез байый алмый.

• Дөньяда сәламәтлек кадәр олуг нигъмәт булмаса кирәк. Фигыль вә гамәл белән сәламәтлек саклау кагыйдәләрен үтәмәгән хәлдә, тел белән генә дога кылудан күп хикмәт булмас.

• Усал галимнәр белә торып гөнаһ кылалар. Белә торып гөнаһ кылучылар исә белмәгәнлек сәбәбеннән гөнаһ кылучыларга күрә кабахәтлерәкләрдер.

• Бездә ир белән хатын арасында булган мөнәсәбәт хуҗа белән хезмәтче арасындагы мөнәсәбәттән аерылмый.

• Гаилә төзек булуга беренче сәбәп – ир булган кеше үзенең хатынын үзенә иптәш вә үзе юк вакытта үз урынында торучы хуҗа, дип белергә, өй идарәсен бөтенләй аңа тапшырырга вә иркенлек бирергә тиешле.

• Зәкәт – милләтнең иҗтимагый хәятен юлга куярлык бер чишмә.

• Дөньяда маңгай тире агызып вә кул көче сарыф кылынып табылган икмәк кадәр ләззәтле икмәк булмас.

• Үз гаепләрен күрә алмаган кешеләрнең бөтен гамәлләре кеше гаебен тикшерү буладыр.

• Үз күзе белән гаебен күрә алучы адәм, әлбәттә, бәхетле бер кешедер.

• Сүзнең артыгы афәт булып, адәм баласы өчен зарардан башка нәтиҗәсе күрелмәс.

• Күңеле пакь кеше һәрбер мәхлукны Аллаһы Тәгаләнең әсәре вә һәрбер агач вә үлән яфрагын Аллаһ сүзе язылган кәгазь дип белер. ■

Рәүфә ханым Әмирханова гаилә архивыннан ире, тарих фәннәре докторы Равил Әмирханның (1946-2006) әтисе, озак еллар Ульяновск өлкәсе ***Иске Кулаткы районы*** *авылларында укытучы булып эшләгән мөхтәрәм шәхес* ***Госман Әмирхановның****(1904-1983) тууына 100 ел тулуы уңаеннан 2004 елда язган мәкаләсен табып, редакциябезгә алып килде. Аны, бик теләп, сезнең хозурга да тәкъдим итәбез.*

Ул – Әмирханнар нәселеннән!

(Педагог Госман Әмирхановның тормыш юлы)

Равил Әмирхан

Госман Әмирханов – Иске Кулаткы районы укытучысы

Госман Әмирханов хезмәттәшләре белән

Тарихтан билгеле булганча, татар халкы элек-электән грамоталы, укуга һәвәс, гыйлемгә, китапка күңел куючанлыгы белән аерылып торган. Белемгә омтылышны һәм аннан гамәли яссылыкта файдалану кебек хасиятләрне – мәгърифәт таратуны үзләренең төп максаты итеп куйган милләтпәрвәр затлар тәрбияләгән. Аларның байтагы бу изге эш белән гасырлар буе шөгыльләнгән нәселләргә нисбәтле булган. XVIII гасырдан башлап хәзерге көнгә чаклы тоташтан халык арасында аң-белем тараткан шушындый нәселләр арасында Әмирханнар да күренекле урын тоткан һәм тотып килә.

Морат, Сәфәр, Әмирхан, Хөсәен, Мөхәммәтзариф, Мөхәммәтнәҗип хәзрәтләр алдынгы мәктәп-мәдрәсәләр җитәкләп, халыкны гасырлар дәвамында агарту белән мәшгуль булып кына калмаган, бәлки балаларына һәм ерак оныкларына да бу саваплы шөгыльне васыять итеп калдырган. Эстафета гел ышанычлы кулларга тапшырылып килгән, практик гамәл чылбыры беркайчан да өзелмәгән һәм хәзер дә үзенең эзлеклелеген саклап килә. Әйтик, **Мөхәммәтзариф**ның педагогик эше белән **Бибисәгадәтбану**, **Фатих** (ягъни Фатих Әмирхан), **Ибраһим** кебек һәр өч баласы шөгыльләнсә, энесе **Мөхәммәтнәҗип**нең бу игелекле юлын ике баласы (**Зәйнәп** һәм **Госман**) сайлый. Госман дигәне инде безнең әтиебез, бу мәкаләнең төп каһарманы була. Төрле төбәкләрдә яшәвенә нисбәтле рәвештә ул «Осман», «Усман» булып та йөри.

Үз чиратында мөгаллимнәрнең яңа «шытым»ына башлангыч биргән Госман Мөхәммәтнәҗип улы Әмирхан Чистай шәһәренең имам-хатыйбы һәм мөдәррисе гаиләсендә 1904 елның 26 августында дөньяга килә. Беренче сабакларын әтисеннән алганнан соң, бабасы Мөхәммәтзакир нигез салган «Камалия» мәдрәсәсендә укый. Сәләтле һәм зиһенле малай, әлбәттә, алдынгы шәкертләрдән санала, үз чорына хас дини гыйлемне дә, дөньяви белемне дә ныклап үзләштерә.

Октябрь революциясе мулла гаиләсе

тормышының астын-өскә китерә. Инде дини гыйлемнең генә түгел, мәдрәсәнең дә кирәге калмый. Җан асрау, башны саклап калу үзе бер проблемага әйләнә. 1917 ел революциясе чорында унөч яшьлек малайга, биштәр асып, ерак төбәкләргә, Уфа тарафларына чыгып китәргә туры килә. Ашау-эчүдә зур кытлык кичергән 9 кешелек гаилә аның, нәрсәләрнедер алмашу бәрабәренә, икмәк-он алып кайтуына өметләнә. Олырак кешеләрне атлаган саен тентеп-тикшереп, хәтта «расход»ка чыгарып торган заманда бу эшкә Госман яшендәге «мужик» кына кулай була. Бәхеткә, сәфәре шактый уңа.

Нәҗип мулла улы Госманның яшәү перспективаларын дөньяви яссылыкта күрә. 1919-1920 елларда Госман Чистай авыл хуҗалыгы техникумының әзерлек бүлегендә укый, урысчага осталыгы сәбәпле, анда да төшеп калганнардан саналмый. Әтисе вабадан кинәт вафат булгач (1921), гаилә белән Казанга күчеп килә, 1921-1924 елларда наркомзем каршындагы Казан авыл хуҗалыгы техникумында белем ала. Өс-баш шактый өтек, ашау-эчүягы такыррак булса да, егет бирелеп укый, урысчасы тагын да шомарып китә. Шул чорларда үзенә якыннан таныш булган Кави Нәҗми, Һади Такташ, Гадел Кутуй һ.б. яңа дәвер каләм осталарының чат саен чыгышларына, иҗади талпынышларына шаһит була. Әлбәттә, Яңа икътисади сәясәт (НЭП) чорының барлык әкәмәтләрен, коточкыч инфляция белән бәйләнгән бөтен хикмәтләрен үз җилкәсендә татып яши.

Шул дәвердә Госман тормышында истәлекле бер вакыйгага булып уза: 1923 елның көзендә ул, Татарстан делегациясе составында, Бөтенрусия авыл хуҗалыгы һәм вак сәнәгать күргәзмәсенә бара, анда туганнан туган абыйсы Фатихның өс-башын, ашау-эчүен карап, көпчәкле арбасын этеп йөртә, үзе дә күргәзмәдән зур гыйбрәт алып кайта.

1924 елның җәендә тормыш җилләре булачак педагогны Баку шәһәренә илтеп ташлый. Аны анда бертуган апасы Зәйнәп җәлеп итә. Төрле кыенлыкларны җиңгәннән соң (ни дисәң дә, мулла малае!), Азизбеков исемендәге политехник институтның авыл хуҗалыгы факультетына укырга керә. 1931 елның февралендә югары уку йортын кыр агрономы («агроном-полевод») буларак тәмамлый. Госман институтта уку белән генә чикләнми, бәлки педагогик стажын да башлап җибәрә. 1924 елның 1 октябреннән ул параллель рәвештә Баку шәһәренең I нче баскыч 2 нче совет мәктәбендә төгәл фәннәр буенча дәресләр бирә, берара уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли. Югары уку йортында белем алу белән мәктәптә эшләүне чиратлаштырса да, һәр җирдә уңыш казана, коллективта үз кеше була.

Дипломлы яшь белгечне 1931 елның февралендә Азәрбайҗанның Маразы авылына агроном итеп җибәрәләр. Бер үк вакытта ул наркомзем челтәрендәге агроуполномоченныйлар курсларында лектор вазифасын да үти. Әлбәттә, чорына хас күмәк хуҗалыклар төзүдә катнаша, шунда хәнҗәр белән коралланган башкисәрләр һөҗүменә юлыга. Аны бары тик «мөселман» булуы һәм бөтен шартын туры китереп намаз укып күрсәтүе генә коткарып кала. Халыкны күсәк белән колхозларга куып кертүдән гайрәте чиккән партиясез агроном үз гомерен тулаем педагогик эшкә багышларга карар бирә.

1932-1934 елларда Госман инде Төркмәнстанда. Ул бер-бер артлы яисә параллель рәвештә Ашхабад индустриаль техникумында, Төркмәнстан халык хуҗалыгы идарәсе каршындагы уку-укыту комбинатында, Ашхабад наркомфины каршындагы финанс-исәпләү техникумында, Ашхабад наркомпросының үрнәк мәктәбендә укыта, математика, физика, механика, физик география буенча дәресләр бирә. Ләкин менә бәла! Инде илдә тынчуланып килгән сәяси атмосферада аның кебек кадрларның

Госман Әмирханның улы Равил Әмирхан гаиләсе. Сулдан: хатыны Рәүфә ханым – табиб, кызлары Гөлназ Бельгиянең Санкт Убер шәһәрендә педагог, олы кызлары – Миләүшә. 1996 ел

социаль чыгышында казынулар көчәя, тырнак астыннан «кер» эзләүләр торган саен киңрәк колач ала башлый. Госманны да сыйнфыйчылык иләгеннән иләүдән бушамыйлар, шомлы 30 нчы һәм аннан соңгы елларда даими төстә киеренке хәлдә тоталар, хәтта эзәрлеклиләр, өстеннән төрле әләк-шикаятьләр язалар. Шуңа да карамастан, Г.Әмирхан тоткан юлыннан тайпылмый, үз эшен намус белән, вөҗданы кушканча дәвам иттерә, күп санлы укучыларының, коллегаларының ихтирамын казана.

1934-1936 елларда Госман Әмирханның эшчәнлеге Үзбәкстан белән бәйле. Сәмәрканд шәһәрендә ул параллель рәвештә узпромсовет, педагогика, индустриаль техникумнарында математика буенча дәресләр бирә, биредә дә үзен әзерлекле, киң эрудицияле белгеч, яшьләр психологиясен тирәнтен аңлаучы педагог итеп таныта. Ил өстендә репрессияләр аҗаганы уйный башлагач, шомлы вазгыять аны тиздән, Үзбәкстанны калдырып, Башкортстанга юнәлергә мәҗбүр итә. 1936-1937 елларда ул башта Дүртөйле районының Яңа Кәңгеш, аннары Бишбүләк районының Ает җидееллык мәктәпләрендә математика укыта. Дәресләрне әйбәт, хәтта үрнәк дәрәҗәдә бирсә дә, педагогка бу төбәкне дә ташлап китәргә туры килә.

Сталин заманында социаль чыгышы белән мактана алмаган Госман Әмирханга инде Самара өлкәсенә барып чыгарга туры килә (1938). Биредә ул Самара өлкәсенең (аннары Ульяновск өлкәсенә керә) Иске Кулаткы районында төпләнә, гаилә корып җибәрә (1939). 1938-1944 елларда шул районның Иске Мастяк, Урта авыл, Карамалы авылларында төгәл фәннәр укыта, 1944-1946 елларда инде район колхоз урта мәктәбендә (РКШ) эшли. Күзләренең зәгыйфьлеге сәбәпле, гаскәри хезмәткә алынмый, ачлыктан интегеп булса да, ишәеп барган гаиләсен кешечә асрарга тырыша. Шунысы гаҗәп: ул чорларда бөтен Иске Кулаткы районында фәкать ике-өч кенә югары белемле кеше исәпләнә, аның да берсе Госман Әмирхан була.

Сугыш афәте артта калгач (ачлыктан 40 яшьлек ирнең бик күп тешләре какшый, ул аларны алдырырга мәҗбүр була), 20 ел стажлы укытучы үзенә булган әлеге дә баягы кырын карашлардан һәм ачлы-туклы тормыштан качып, дүрт баласы белән яңадан Урта Азиягә барып чыга (1946). Анда Үзбәкстанның Пахтакор районына кергән Зиадин станциясендә Каганович исемендәге 14 нче урта мәктәптә өч ел буена физика, химия, астрономия укыта. Югары белемле педагог буларак, ул үзбәк кышлакларына да барып йөри, укытучыларга методик ярдәм күрсәтә, балаларны мәктәпкә җәлеп итә. Ләкин анда да тернәкләнә алмый, эзәрлекләнә, авырый, нәтиҗәдә, 1949 елның җәй азагында яңадан Иске Кулаткы районына кайтып сыена.

1949-1954 елларда Госман Әмирхан Муса авылы җидееллык мәктәбендә математика һәм физика укытучысы булып эшли, ә 1954-1961 елларда шул ук районның Иске Атлаш җидееллык мәктәбендә төгәл фәннәр өстенә рәсем һәм хезмәт буенча дәресләр алып бара. Район мәктәпләренең 50 нче еллар азагынача югары белемле укытучыларга кытлык кичергәне мәгълүм. Мәшһүр шагыйребез Сәгыйт Сүнчәләйнең туган авылы Иске Мастяк урта мәктәбендә дә шундый ук хәл. Менә шушы шартларда чыгарылыш имтиханнарында тиешле дәрәҗәне тәэмин итү өчен югары белемле укытучыларны бөтен төбәктән бөртекләп җыялар. Табигый, бу «урак өсте»ндә Госман Әмирхан иң кирәкле шәхесләрнең берсенә әйләнә: Атлаш авылыннан 12 чакрымдагы Иске Мастяктан аны алырга дип тарантас җигелгән махсус ат җибәрәләр. Бу сәфәрләр югары белемле яшь алмаш өлгергәнче, берничә ел буена дәвам итә.

1961 ел керә. Иске Мастякта урта мәктәпне тәмамлаган улларының югары белем җәһәтеннән киләчәген уйлап, өлкән педагог Казаннан якынрак җиргә барып төпләнергә карар бирә һәм шул ук елның җәендә унбер кешелек гаиләсе белән Татарстанның Биектау районындагы Татар Әйшәсе авылына килеп урнаша. Әйшә сигезьеллык мәктәбендә ул төгәл фәннәр, сызым, хезмәт, рәсем дәресләре алып бара, өлкән балаларны югары уку йортларына әзерли.

1963 елның җәендә гомер сукмаклары аны гаиләсе белән яңадан Иске Атлашка алып кайта. Инде унъеллык булып киткән мәктәптә ул, гадәттәгечә, математика дәресләре алып бара, 60 яшен тутырганнан соң, 1964 елның ноябрендә, лаеклы ялга китә. Ләкин тәҗрибәле педагогтан аерыласылары килмичә, аны берничә тапкыр ата-аналар комитеты рәисе итеп сайлыйлар. Шунысы кызык, 20 нче елларда ук укытучылык эшен башлаган Госман Әмирханга үз гомерендә өч төрле графика нигезендә дәрес бирергә туры килә. Ул гарәп имласы белән дә, яңалиф һәм кириллица белән дә бердәй җиңел, заманга ярашлы итеп гамәл кылган сирәк педагогларның берсе була.

Дүрт дистә ел буена төрле уку йортларында дәрес биргән укытучының шәкертләре арасында бихисап күренекле шәхесләр бар. Азәрбайҗан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Башкортстан, Татарстан, Ульяновск өлкәсендә аларның байтагы җитәкче постлар били, райком секретарьлары, РОНО мөдирләре, мәктәп директорлары, инженер-техниклар, табиблар һ.б. югары квалификацияле белгечләр булып җитешә. Бу кадрларның исәннәре үзләренең остазларына бүгенгәчә зур ихтирам саклый, аны рәхмәт хисләре белән искә ала. Рәхмәт, ихтирам, димәктән, бу хасиятләр бигрәк тә анык булып Иске Кулаткы районында сизелә. Район күләмендә аның абруе, гомумән, зур булып, аны белмәгән, тәкъдир итмәгән кеше калмаган, дисәң дә ялгыш булмастыр. Бу гаҗәп тә түгел: үзе укыткан предметларны да, балаларны да бик ярата торган кеше иде ул.

Госман Әмирханның укытучылык эшеннән башка тагын берничә сыйфатын искәртергә кирәктер. Урысчасы бик әйбәт булганлыктан, ул авылдашлары үтенече буенча төрле даирәләргә, өлкә үзәгенә, Мәскәүгә хәтле хатлар яза, җавап мәктүпләрен укып аңлата, яңадан яза, әлеге яки башка мәсьәләләрдә аңа киңәш сорап килүчеләрнең гозерләрен бервакытта да кире какмый. Зур стажлы, киң карашлы педагог буларак, ул К.Д.Ушинский, аеруча А.С.Макаренко эшчәнлеген һәм иҗатын хөрмәт итә, әсәрләрен туплап, өйрәнеп тора, төп фикерләрен үз эшендә иҗади файдалана белә.

Өлкән педагог үз балаларының кыйблаcын билгеләргә, киләчәк тормышларына һәрдаим мәгълүм бер юнәлеш бирергә тырышкан максатчан шәхес була. «Күктән йолдыз санау»га да, чынга ашмас хыяллар белән әвәрә килүгә дә каршы була ул. Төп шигаре исә моңа кайтып кала: «Галиҗәнап Халыкка хезмәт итегез!»

Халыкка хезмәт итүнең иң кулай ысулларының берсе итеп ул укытучылык эшен саный. Алты баласына (**Илдус, Расим, Равил, Наил, Сафия, Фәрит**) югары, өчесенә (**Флора, Гания, Мөнирә**) махсус урта белем алуга ярдәм итеп, ул гыйльми-педагогик эстафетаны ышанычлы кулларга, ягъни үз балаларына тапшыра: Илдус (1941), Расим (1942), Равил (1946), Наил (1949) төрле елларда укытучылык эше белән шөгыльләнә. Кайберләре, инде пенсиядә булуга карамастан, буыннан-буынга күчә килгән бу игелекле гамәлне бүгенгәчә дәвам итә. Әйтик, өлкән улы **Илдус**, татар милли хәрәкәтен әйдәүчеләрнең берсе булудан тыш, «Мәгариф» ассоциациясенең эшлекле әгъзасы, мәктәп һәм гимназия директоры булды, милли мәгариф һәм гаиләгә кагылышлы бихисап кануннамә һәм низамнамәләр иҗат итте, бүгенге көндә «Колшәриф» университетының ректоры вазифасын үти. **Равил**, докторлык диссертациясе яклап, Татарстан Фәннәр Академиясе Тарих институтында тарих бүлеген җитәкли, Мәгариф министрлыгы, «Мәгариф» журналы белән тыгыз элемтәдә тора (редколлегия әгъзасы), аспирантура аркылы фәнни алмаш әзерләүгә үзеннән өлеш кертә, берничә китап, биш йөздән артык мәкалә авторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. **Расим** озак еллар дәвамында Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшләде, **Наил** Казан дәүләт университетында җаваплы административ пост били, педагоглар, студентлар белән тыгыз хезмәттәшлек кыла. **Флора** белән **Мөнирә** – медицина, балалар тәрбиясе өлкәсендә нәтиҗәле эшләде һәм эшләп килә. **Сафия** белән **Фәрит**, университетны тәмамлап, инженер дипломына ия булды. Моннан тыш, Фәрит Татарстан Республикасының банк-финанс системасында зур дәрәҗәләргә, казанышларга иреште, югары квалификацияле, абруйлы хезмәткәрләрдән санала[1].

Кыскасы, балалары әтиләренең дә, нәселләренең дә рухына күләгә төшерми, йөзенә кызыллык китерми. Үзе исән вакытта ук олуг ихтирамга лаек булган укытучы-педагог 1983 елда улы Расим гаиләсендә 79 нчы яшендә вафат була.

Гомеренең кырык елдан артык өлешен яшь буынны тәрбияләүгә, төрле һөнәр буенча өметле белгечләр әзерләүгә багышлаган Госман Әмирхан мәгарифебез һәм милли мәдәниятебез тарихында якты эз калдырган шәхесләрнең берсе булды. Беркайчан да арзанлы популярлыкка омтылмаган, данга-шөһрәткә битараф булган бу тыйнак милләт хадиме бүгенге заман укытучыларына бик күп җәһәтләрдән үрнәк була ала.

13.05.2004 ■

---

[1] Хәзерге вакытта Госман Әмирхановның улы Фәрит финанс системасында эшләвен дәвам итә, мәкаләнең авторы Равил Әмирхан 2006 елда вафат, ә калган балалары лаеклы ялда.

Безнең мирас №6 июнь 2017

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Ул көнгә калдырма – эшеңне бетер,
Кичерер азапны вакытында кичер».

Янә әйтте ул: – И, ваемлы кардәш,
Синең артыңнан мин күп калмам, кордаш.

Сиңа бераз сөйлим үгет сүзләрен,
Син аны онытма, мин үлгәч, җәрен.

Сиңа миһербаным мин үлгәннән соң,
Бар байлыгым ошбу сүзләрдә калсын.

УЙГЫРМЫШНЫҢ ҮГЕТ-НӘСЫЙХӘТЕ

Бу сүзләрне, кардәш, арзан дип белмә:
Яман эшкә гомер һәм көчең бирмә.

Тугры бул, югалтма тугрылык юлын,
Теләккә ирешерсең, барсаң туры.

Рәхимле бул барча тере-җанлыга,
Күңелең киң булсын, һәрчак кыл дога.

Кайгы ташкыныннан намаз кичерер,
Ярсуда сабырлан, утыңны сүндер.

Үлемне онытма – хәзерлеген кыл.
Үзеңне онытма – асылыңны бел.

Сагаеп күз атма дөнья малына:
Үкенеп еларсың – калыр бары да.

Һәрхәлдә сабыр бул, тәкъдирем, диген.
Халыкка файда кыл – күтәреш йөген.

Дөресен сөйлә һәм кайтма сүзеңнән,
Кыек сөйләүчеләр – ялганчы, түбән.

Көләч йөзең, җылы сүзең, гамәлең
Өчен ырыс һәм кот бирер сәламен.

Бул юмарт һәм алчак, икмәк-тоз җийдер,
Кеше гайбен ачма – син өртеп җетер[1].

Рәхимле бул барча тере-җанлыга,
Күңелең киң булсын, һәрчак кыл дога.

---

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.
[1] Өртеп җетерү – «сүз ачмыйча хәл итү».

Һаваңны бас, үпкәң булса, түз, тыел,
Күңлең кәкре юлга китсә, тап төз юл.

Үз файдаңнан алда күзәт илнекен,
Илеңә йөк булма – күтәр ил йөген.

Малың булса, үзең өчен бир йолым:
Бар халык сөенсен, и, күңле олуг!

Ни шәп әйткән, күр, бер атаклы белкә
(Башы тулган булган аның белемгә):

Файдалы кеше ул – инсан асылы,
Миһербанлы кеше – инсан матуры.

Кешелек ул ике юлдан кәш торыр[2]:
Берсе – шәфкать, берсе матди байлыктыр.

Тагын да яхшырак, күр, гыйлем юлы,
Гыйлем юлын тотсаң, файдасы мул ул.

«Юмарт, юмарт», диләр, кем соң чын юмарт?
Халыкка җан фида кылган асыл зат.

Кешегә өләшү юмартлыкмыни?
Чын юмартлык илгә җаныңны бирү.

Юмарт ир халыкка өләшсә товар,
Халаек эркелеп җыелыр аңар.

Ике шәйдән тәшкил дөнья кызыгы:
Берсе аның мөлкәт, берсе – йөз суы.

Бу икене табып яшәсәң, мең ел,
Үлем соңгы кызык булыр иде ул.

Бийләр биегәер ил имин булса,
Тезген тоту җиңел – өзәңгең булса.

Бу хәлгә ирешү – төп максат бийгә,
Ирешелсә дә ул тик картлык килгәч.

Үзең күчмән, атың синең – күчкен ул,
Үлем юлда килү – ахыргы көн ул.

Күчүчеләр салмас һич урда-сәрай,
Йөремсәкләр калмас бер җирдә ел-ай.

[2] Кәш – «состоит (из)...» (ни-нәрсәдән тора).

Үз файдаңнан алда күзәт илнекен,
Илеңә йөк булма – күтәр ил йөген.

Үзеңне юлчы дип уйла, кардәшем,
Сөенмә, тип-тигез торсын күз-кашың.

Бу дөнья – узгынчы, дөнья – тезгенсез,
Син үлемле, үлем көнең билгесез.

Тырнагын чыгарган үз әҗәлең дә,
Эләктерер саксыз йөргән мәлеңдә.

Бу дөнья бер аш ул. Ашка килгәннең
Исемен сорама, үзен беләсең.

Нәфес кума, саклан һаваланудан,
Кешене сөйләмә – телсездәй кылан.

Ни, ди, күңле уяу, үзе сак кеше
(Аныңча эш итсәң, мәшәкатьсезсең):

«Бүген теләгәнчә яшәү – бик татлы,
Ләкин киләсе көн сорар ич хакын».

Татлыга татсыз бар, төчегә – ачы,
Үрләүгә – төшү һәм ябуга – ачу.

Кыланышы кызлар шикелле дөнья:
И, холыклым, сине сихерләп куяр,

Дөнья күп синдәйне җилгә очырган,
Күп илбикнең башын җиргә төшергән.

Дөнья, туры карап, сезгә кул бирде.
Тик син гафил булма, и, холкы ипле.

Ничек биргән булса, шулай ала ул,
Җыя һәм тарата, гүя җил-давыл.

Кайда шатландырса, шунда елатыр,
Кайда төзгән булса, шунда кыйратыр.

Кылыгы җәфадыр, кылмышы – утын,
Яхшылыгы азрак, күбрәге – төтен.

Бизәнеп күрсәтер кешегә үзен,
Күңел бирдең исә, терәр ишеген.

Бийләр биегәер ил имин булса,
Тезген тоту җиңел – өзәңгең булса.

Агулау алдыннан бирер ул шикәр,
Дөньяның кылыгы менә шул, белкә.

Ни, ди, идарәче киңәшче башы,
Уйла, и, дәүләтнең ирәне кеше:

«Бу фани дөньяга бик күңел бирмә,
Җәфага булыр ул, и, сабыр ирән[3].

Сәгать күләгәсе кебек бу дөнья:
Көн эчендә капма-каршы борыла[4]».

Динеңне кыйммәт бел, дөньяны – арзан,
Динең, и, гыйлемлем, саклар бәладән.

Рәхәткә бирелеп, гамьсез булма син,
Аллага гыйбадәт онытылмасын.

Исертмәсен сине дәүләт, и, кардәш,
Аек хәлдә тулсын күзләреңә яшь[5].

Ни, ди, ишет, халык биебез үзе
(Сынап, уйлап әйткән булыр ул сүзен):

«Әгәр тәхтендә хан исереп ятса,
Айнып, үзен күрер ул былчыракта».

Куәт байлык, бийлек килсә бик иртә,
Сөчек[6]-аракылар бийне исертә.

Йоклый торган булса, бер шәп эчкече:
Исреп йоклар, айнып торыр ул кеше.

Ә дәүләт исертсә – бүтән айнымас,
Үлеме җитсә дә, хәтта, уянмас.

Исемең бий икән – кол эшен кылма,
И, изгем, коллыгын кылсын ул коллар.

Күп калмаган инде тереклек көне,
Бик озакка китмәс олуглык өне.

Мең яшәгән зат та бер үләчәк ич,
Тән һәм җан арасы өзеләчәк ич.

Ишет инде бер сүз – бик бап биредә
(Хәтереңдә калдыр, йөзең чөермә):

«Барча теләкләргә ирешсәң дә син,
Тере суын табып, чөмерсәң дә син,
Кулларың җитсә дә күк гөмбәзенә,
Башың күккә тисә дә – бу җирдә син».

Турысын сөйлимен сиңа, кардәшем,
Нигә яшерерим – син фикердәшем.

Кем сөймәс соң, күр, бу дөнья нигъмәтен,
Тәмле аш, гүзәл яр, кадер-хөрмәтне.

Бу рәхмәтлекләргә мин кул селтәдем,
Чөнки дөнья япты күп ишекләрен.

Алладан качыра дөнья кешене,
Тыя һәм аера изге эшендин.

Акылдарлар, качып шундый хәтәрдән,
Дөнья гизеп йөри хурлыклы хәлдә.

Каюсы тауларда, өе – өңгердә,
Ашы – үләннәрдән, суы – яңгырдан.

Каюсы япанда каңгырып йөрер,
Ходайдан куркынып, кайгырып йөрер.

Кайсы чикмән киеп, аркасын бөгеп,
Сукыр булып йөри, күз яшен түгеп.

Бу дөнья – узгынчы, дөнья – тезгенсез,
Син үлемле, үлем көнең билгесез.

[3] Йосыф хасс хаҗип, матди байлыкка һәм хәрби куәткә уңай караган хәлдә, һәрвакыт дөньяның фанилыгы турында сүз куерта. Моны авантюралардан сакланырга чакыру, дип уйларга ярый. Ләкин аның сәрайлар, ныгытмалар төземәгез, диюе белән килешеп булмый. Гомүмән, бу хасс хаҗипнең дәүләтчелек карашлары каршылыклы тар вә таркау. Бу хәл XI гасырдагы төрки дөньяның таркаулыгына тәңгәл. Һәм менә шул хәл XIII гасыр башларында төркиләрнең тарихта иң зур фаҗигасенә – монгол яуларыннан җиңелүгә китергән дә.
[4] Сүз сәгатьне багана күләгәсенә карап билгеләү турында бара. Сәгать сүзе үзе асылда «багана».
[5] Сүз дини хисләрдән елау турында.
[5] Сөчек (борыңгы Болгарстанда сыҗу) – «аракы, шәраб төре, кымыз». Белгечләр әйтүенчә – «молочная водка».

Каюсы ач тора, яши азапта,
Кайсы һич тә ятмый, йоклый аякта..

Бу төрле кешеләр – уянган затлар.
Без исә йоклыйбыз: «Ни булса булыр».

Син исә үзеңне сакла, и, кардәш,
Дөнья синекедер, үзең булдың баш.

Нәфес һәм һәвәснең муенын сындыр
(Чын ирнең нишаны – билгесе шулдыр):

Бу ике шәй белән ир көчен жуя,
Азапланыр полын булса ул шуңа.

Менә хәзер синнән аерылам, китәм,
Синең юлың бүтән – игелек көтәм.

Яманга катылма, күңлең изге тот,
Ике дөньяда да яманлык ул – йот.

Ни, ди, ищет, күңлен баскан бер кеше
(Үлеменнән алда бетереп эшен):

«Жинаять жиңел эш, диеп уйлавың –
Асылда үзеңә төрмә буравың».

И, син – киң акыллы халык үктәме.
Үлем бозачактыр тереклек тамын»[7].

И, син – мин, мин диеп йөрүче кемсә:
Хәзерлән, нишләрсең син үлем килсә?

И, син, ачкүз, дөнья колы, аз гына
Күзеңне ач – үлем килә яныңа.

Тагын әйтте: – Үләм, туган, моңымда,
Ике нәрсәгә бик ачынамын ла:

Бере – кала тагать, гыйбадәт миннән,
Икенчесе – «Алла!» сүзен әйтәлмәм.

**«Сәгать күләгәсе кебек бу дөнья:
Көн эчендә капма-каршы борыла».**

**Рәхәткә бирелеп, гамьсез булма син,
Аллага гыйбадәт онытылмасын.**

Бүген йә иртәгә йомылса күзем,
Догагызга мохтаҗ буламын үзем.

Догадан калдырма, кардәш, мине син,
Соң, үзең эземнән тиздән килерсең...

Менә күрәсең ич минем хәлемне,
Сиңа булсын гыйбрәт; алдан кыл имне.

Үлем килеп тотты – китәм моң белән.
Сиңа да киләчәк – шуңа хәзерлән.

Аерылам синнән кайгы-моңымда.
Күрешсә көнебез Алла кулында.

Ни, ди, күр, үлемгә йөз тоткан кеше –
Бәхилләшеп, җиргә салынган башы:

«Үкенечтә үләм, яшь тулы күзем,
Татлыны татлыксыз кыла бу үлем.

Үлемнән соң ике юл көтәр мине,
Шуларның кайсыннан китәрмен инде».

Моңа өстәп әйтәм: – Рәхимле кардәш,
Минем кайгым белән кайгырма бер дә!

Елама, күңлеңне юкка сындырып,
Сабырлан, дога кыл. Хәтта, бул кырыс.

Сыгыт[8] кылып торма һәм бул түземле,
«Ходай биргән үлем», дип кис сүзеңне.

Йөре, кайт инде син, үз өеңә бар.
Сагыш, кайгы белән күңлең кылма тар.

Кирәгенчә әйттем сүземнең барын,
Онытма сүземне, и, игътибарлым.

Соңгы сәламемне илбиккә җиткер.
Әйбәтләп әйтерсең, и, зиһне үткер.

Дәвамы бар ■

[7] Там – «эстинә, дивар», кайбер татар (Әстерхан) сөйләшләрендә – «балчык сарай».
[8] Сыгыт – «кеше үлгәндә аның өчен елау мәрасиме».

Нечкә күңелле һәм горур кеше иде

Нурихан Фәттахның вафатына да – 13 ел. Кульъязмаларын тәртипкә китереп утырганда бер язмага тап булдым. Укып чыктым да аптырап калдым. Ул бит шигырь бәйрәменә барырга, шунда үз сүзен әйтергә әзерләнгән булган. Нигә бармаган, ник әйтмәгән үз фикерен?!

Язучы Нурихан Фәттахны Тукай бүләгенә өч тапкыр тәкъдим иттеләр. Өчесендә дә Язучылар берлегенең идарә утырышында фикер алышып, тикшереп, карар чыгарганнар. Беренчесе кайчан булгандыр, анысын мин хәтерләмим. «Миңа ул бүләкне алырга иртәрәк әле», – дип, үзе баш тарткан, имеш. Шулай булгандыр. Ни өчен дигәндә, ул һәр эшнең сыйфатлы, җиренә җиткән булуын ярата иде. Мисал өчен, Язучылар берлегенә дә шактый соң гына керүен әйтергә була. Икенчесендә, 1989 елда, ул вакытта инде вафат булган Фаил Шәфигуллин файдасына, дип, үз кандидатурасын алган. Монысын мин әллә белми калганмын, әллә онытканмын. Шуны Фаил Шәфигуллин турындагы «Сагынырлар әле безне таулар» дигән китаптан укып белдем.

Өченче тапкырында, 1994 елда, язучыга 66 яшь тулганда, 1988 елда басылып чыккан «Сызгыра торган уклар»ны Тукай бүләгенә лаек дип таптылар.

Бармады Нурихан шигырь бәйрәменә. Бу яшьтә премия алуның аның өчен куанычы калмагандыр, дигәнрәк фикерләр ишетелде. Мин үзем дә шулайрак уйлаган идем ул вакытта. Шигырь бәйрәмен карарга дип телевизорны кабызып куйгач, тузынып, өйдән чыгып киткәненә гаҗәпләнеп калган идем. Нуриханның бөтенләй көтмәгәндә кәефе үзгәрүенә күнеккән булсам да, хәтер калды билгеле. Нурихан Фәттах килмәгән дип тормаганнар, бәйрәм гөрләп тора. Аның фамилиясен игълан иткәч, ул вакытта Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев, як-ягына карангалап алды да: «Нурихан абый чирләп тора иде, килә алмады», – дип куйды. Мин өйдә үзем генә идем. Телевизорга карап:

– Чирле түгел лә ул, яңа гына урамга чыгып китте! – дип куйдым.

Ул көннәрне Нурихан бик ачулы йөрде, бер сүз әйтеп булмый, кабынырга гына тора. Премия акчасын сберкассага җибәрмәсеннәр өчен пенсия килә торган кенәгәсен яптырды, пенсиясен почтага барып ала башлады. Ул акчаны алгандырмы, юкмы, әлегә кадәр белмим. Чөнки ул турыда сүз кузгатсаң, зур тавыш чыгармыйча гына, бер-ике сүз белән «өтеп» аласын көт тә тор. Бәлки, алучы булмагач, бюджетка киткәндер...

Бәлки, иртәгә бәйрәм дигән көнне кичтән яки иртән Язучылар берлегеннән котлауларын, бәйрәмгә чакыруларын көткәндер. (Бәйрәмгә читтән килгән кунаклар күп иде, бәлки, Н.Фәттахны онытканнардыр.) Нечкә күңелле һәм горур кеше иде шул, мәрхүм. Юкка гына Туфан Миңнуллин үзенең истәлекләрендә: «Дәрәҗәләр даулап, шау-шу куптарып йөрмәде. Дәрәҗәләрне аның өенә китереп диярлек бирделәр», – дип язмагандыр.

Әлеге ыгы-зыгылардан соң дүрт ел узгач, 1998 елда, Нуриханга 70 яшь тулу уңаеннан юбилей кичәсе уздыру-уздырмау турында сөйләшер өчен Язучылар берлегенә бардым. Монысында үзе җибәрде. Шунда, сүз арасында Ринат:

– Руфина апа, Тукай бүләгенең документлары миндә ята, алып китегез, – диде.

– Ринат, хөкүмәт бүләге ришвәт түгел бит, аны кешедән яшереп бирмиләр. Һичюгы идарә утырышында үзенә тапшырсагыз, күңеллерәк булыр иде, – дидем. Алмадым.

Шул ук 1998 елның 10 декабрендә Нурихан Фәттах белән Шәүкәт Галиевкә 70, Ринат Мөхәммәдиевкә 50 яшь тулу уңаеннан, өчесен берьюлы Президент Минтимер Шәймиев кабул итәчәк, дип өйгә шалтыраттылар. Ул көнне, эштән рөхсәт сорап, юбилярны каршы алырга чаптым – Президент резеденциясенең капка төбендә боларның чыкканын озак кына көтеп тордым. Берзаман чыгып киләләр өчәүләшеп – йөзләре балкыган, кулларында зур-зур чәчәк бәйләмнәре. Кремльдән, Язучылар берлегенең «Волга»сына утырып, Мөштәри урамына киттек. Ринат бүлмәсенә Илдар Юзиев белән Әхмәт Гадел дә килеп керде. Ринат ирләрне коньяк белән сыйлады, аннары, Тукай бүләгенең дипломын һәм түшбилгесен алып, Нуриханга тапшырды.

Нуриханның көндәлегеннән: «Минем өчен тарихи көн бүген. Иртән 8.30лар тирәсендә УАЗ машинасы белән Данил Салихов килеп алды (ул вакытта Данил Ринат Мөхәммәдиевнең урынбасары иде . – Р.Ф.). Союзга бардык. Иртә килгәнбез. Ринат анда иде инде, бераздан Шәүкәт тә килде. Өчәүләшеп, тоткарлыксыз, патша йортына барып кердек. Кемнәрдер каршы алды. Аерым залга кереп утырдык. Мин түргә туры килдем, тәрәзә янына. ТВ, радио журналистлары төшерәләр, сөйләштерәләр. Берзаман, шәп-шәп атлап, Минтимер Шәймиев килеп керде. Башта Шәүкәт Галиев, аннан минем белән, аннан соң Ринат белән күреште. Каршыга утырып әкрен генә сөйли башлады. Илгиз Хәйруллин, мәдәният министры Марсель Таишев аның уң ягында утыралар. «Татар милләтен без уятмасак, башка беркем дә килеп уятмас», – диде. Мине телгә алды, тарих, тел... «Моңарчы мөмкин булмады, хәзер мөмкинлек ачылды, эшләп калырга кирәк!» – диде. Мин: «Сездән җылы караш, шундый сүз ишетү – безнең өчен куаныч. Минем үземә күп нәрсә кирәкми – ягымлы караш булса, кайбер нәрсәләрдә бераз ярдәм итсәгез, соңгы көчемә кадәр эшләячәкмен», – дидем.

Аннан Шәүкәт сөйләде. Ринат та үз сүзен әйтте. Гайнуллин фамилияле эш башкаручы һәрберебезгә конверт бирде. Бик җылы, эчкерсез очрашу-сөйләшү булды. Барыбызның да күңелләр күтәрелде. Очрашу сәгать тә унбиш минут барган. Башкаларны 40 минуттан артык тотканы юк, имеш.

Залга керер алдыннан Шәймиевнең ярдәмчесе сорау бирде:

– Тукай бүләгенең дипломын алдыгызмы?

– Алдым, – дидем.

– «Мәдәни җомга»да «алмаган», дип язганнар иде, – ди.

– Журналист халкы яза инде ул, – дип кенә куйдым».

Ә хәзер Нуриханның теге вакытта, 1994 елда Тукай бәйрәмендә сөйләргә уйлап та сөйләми калган сүзләрен игътибарыгызга тәкъдим итәм:

«Хөрмәтле дуслар, каләмдәшләр, милләттәшләр!

Тукайга, Туфанга, Сәйдәшкә һәм халкыбызның теленә, моңына, мәңге сүнмәс иҗат рухына тугрылыклы булуыбызны исбатлап, шушы язгы, матур көндә менә тагын бергә җыелдык.

Быел Сезнең алда сүз әйтү хокукы миңа бирелде. Габдулла Тукай исемендәге бүләкне быел шагыйрьгә түгел, прозаикка бирәләр. Хикмәт нидә? Минемчә, кандидат прозаик, кандидат шагыйрьдән өлкәнрәк яшьтә. Бездә хәзер шундыйрак традиция барлыкка килде: әдәби бүләкне яхшырак әсәр өчен түгел, картлык өчен бирәләр. Әйтик, берәр ярышта җиңеп чыккан спортчыга: энем, син җиңүен җиндең, ләкин син әле яшь, бүләгеңне 40-50 елдан соң алырсың, дисәләр...

Шул ук вакытта бер мәртәбә бүләкләнгән өлкән язучы да үзеннән яшьрәкләр белән ярышта катнашырга һәм әсәренә күрә яңадан бүләкләнергә хаклы, дип исәплим.

Гыйбрәтле бер мисал китерим әле: борынгы грек шагыйре Софокл 92 яшькә кадәр яшәгән. Шул гомер эчендә 120дән артык тра-



гедия язган. Иң көчле трагедияләреннән берсе – «Эдип в Колоне» дигәнен йөзенче яшендә иҗат иткән. Софокл үз гомерендә 24 мәртәбә әдәби ярышта җиңеп чыккан.

Мин, Татарстан дәүләте тарафыннан үземә бүләк итеп бирелә торган Тукай бүләге акчасын тулысынча татар мәктәпләре өчен дәреслекләр бастырып чыгара торган «Мәгариф» нәшриятына бүләк итеп бирергә булдым. Вакытлы матбугатта, радио, телевидениедә минем кандидатлыкны яклап чыккан барлык иптәшләргә, каләмдәшләргә, Тукай бүләге комиссиясе әгъзаларына, дәүләтебез, хөкүмәтебез җитәкчеләренә чын күңелдән рәхмәтемне белдерәм.

Шушы уңайдан файдаланып, ирекле Татарстан гражданнарын, барлык сөекле милләттәшләремне яз бәйрәме, татар әдәбияты бәйрәме белән котларга рөхсәт итегез!

23.04.1994 ел».

Язманы Нурихан Фәттахның хатыны
***Руфина Фәттахова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

МАВЫКТЫРГЫЧ ШӨГЫЛЬ

Эльмира Шәрифуллина

Очрашулар вакытында еш кына: «Бу шигыремезне язарга нәрсә сәбәп булды?», «Ул сезнең биографиягә кагылышлымы?», «Язу өчен материал каян аласыз?» кебек сораулар бирәләр. Билгеле инде, бигрәк тә зур әсәрләрне язганда, ниндидер этәргеч булмый калмый. Әмма аңа кадәр сине борчыган теманың нигезе күңелеңне дулкынландырып, уйландырып йөрергә тиеш. Ә инде языла башлау көнен, бик гади итеп аңлатканда, мөлдерәмә тулы чиләккә соңгы тамчы килеп төшкәннән соң, суның ташып чыгуы, агып китүе кебек итеп күз алдына китерергә мөмкиндер.

«Мордар» поэмасы, мәсәлән, минем күңелемдә шулай туды. Һәм ул кисәк-кисәк булып, ягъни тулыландырыла-тулыландырыла язылды.

1982 елда, көтмәгәндә-уйламаганда, типсә тимер өзәрлек киявебез мордар китте. Аның ачысыннан айнырга өлгермәдек, өч ай үтәр-үтмәстән, яраткан ирем – язучы Фаил Шәфигуллинны кыйнап үтерделәр. Ике гаиләгә – дүрт үксез, берсеннән-берсе кечкенәрәк балаларыбыз ятим калды. Фаилнең вафатына кадәр бер ел тирәсе элек өченче кызы-

быз – Фирүзәмне җирләгән идек. Шулай итеп, иңнәремә күзләрне ачып булмас дәрәҗәгә җиткергән кайгы төялде... Гаҗизләнү, балаларны кимсендермәскә тырышу, эчтән: «Ни өчен болай?» – дигән сорауга җавап таба алмыйча газапланулар, ачыргаланулар – «Бер кычкырды кәккүк» исеме белән кәгазьгә төште. Ул, минем карашка, һәркайсы аерым шигырьләрдән торган туплама кебек иде. 1984 елда нәшер ителгән «Яңгыр җиле» исемле җыентыкка да шулай, ягъни җанры билгеләнмичә кереп китте. Ә инде китабымны яратып кабул иткән, бәя биреп, тәнкыйть фикере әйтүчеләр аның поэма дип аталырга хаклы булуы турында яздылар.

Менә, үзе дә шагыйрь, гомере буе татар теле һәм әдәбияты фәнен укыткан Әзһәр Габидинең «Татарстан яшьләре» газетасының 1984 ел санында чыккан «Күңелендә яңгыр җиле...» дигән мәкаләсеннән бер өзек: «... Инде җыентыкның ахырына урнаштырылган «Бер кычкырды кәккүк» әсәренә тукталыйк. Автор, тыйнаклык саклап булса кирәк, аның җанрын күрсәтмәгән. Ул, төзелеше белән, беренче карашка шигырьләр циклы булып күренсә дә, чынлыкта үзенең эпик гәүдәләнеше белән поэма булып саналырга хаклы. Анда лирик геройның кичерешләре, эпик күренешләр белән чиратлашып, тыгыз итеп үрелеп баралар һәм әсәрнең тотрыклы сюжетын, ныклы композициясен тәшкил итәләр. Поэмадагы һәр юл автор тарафыннан күтәрелгән олы мәхәббәт алдында үлем көчсез, дигән фикерне ачып бирүгә юнәлдерелгән. Шул нигездә ул сөйгәнен югалткан хатынның һәм фаҗигагә тарып үлгән ирнең драмасын җанны тетрәндерерлек итеп сурәтли һәм аларның җанлы образларын күз алдына китереп бастыра алган. Бу исә шагыйрәнең өлгергәнлеген, поэма жанрында да эшләргә сәләтле булуын күрсәтеп тора».

Монысы – шагыйрь Камил Мостафинның 1989 елда «Социалистик Татарстан» газетасында чыккан, «Гөлләр елы» исемле китапка язган «Очар кош булып...» дигән бәяләмәсеннән: «...Югарыда әйтеп үтелгәнчә, шагыйрә үзенең лирикасыннан аерылгысыз язмышы, мәхәббәте турында сөйли. Бүгенге көндә бу лирика – Эльмира Шәрифуллина шигырьләренең иң көчле, иң әһәмиятле өлеше. Аны укыгач, зур кайгының да гүзәл поэзия була алуына ышанасың. Дөнья әдәбиятында да мондый поэзиянең үрнәкләре бар. Шулар арасында бөек итальян шагыйре Франческо Петрарканың «Лаура ханымның үлеменә» дип исемләнгән сонетлары һәм Чили шагыйрәсе Габриела Мистральнең «Үлем сонетлары» күпләргә таныш.

Сүз уңаенда шагыйрәгә бер киңәш бирәсе килә: әгәр шушы лирик цикл тулыландырылса һәм җентекләбрәк тупланылса (циклның бер өлеше «Яңгыр җиле»нә дә кергән), аны укучыларга аерым бер әсәр итеп тәкъдим итәргә мөмкин булыр иде».

Шунысы кызык, поэмага кергән «Безнең күңел» дигән шигырь, Фаилне көтеп, йоклый алмый пошыргаланып утырганда, аның кыйналып авыр хәлдә ятуыннан һич кенә дә хәбәрдар булмаган вакытта язылган. Ниндидер шөбһәләнү белән: «Гарасатка кереп югалмыйча, Гөнаһларга гына уралмыйча Бәхет йөрсә икән...» дигән теләкләр белдереп; «Тик дөньясы гына әллә ничек, Сабырлыклар бирсен, Түз йөрәк!» дип инәлеп сораган ялвару белән... Ул явыз төн – 1982 елның 5есе тәмамланып, 6сына күчкән октябрь ае иде...

Билгеле, бөтен гомергә җитәрлек бу тетрәнү поэмадагы 11 шигырьгә генә сыеп бетә алмады. Санасаң, ихтимал, йөзгә дә җиткәндер инде хәзер. Әмма кемнәрнеңдер эчен дә пошырды бу тема. «Һаман ирең турында язуыңны ташла инде», – диючеләр дә булды. Тик: «Толлар турында болай үзәккә үтәрлек итеп язган кеше юк иде», «Нәкъ минем

Фаилнең тууына – 50 ел. Яшел Үзәндә.Сулдан: Азат Вергазов, мин, Камил Кәримов. 1989 ел

күңелемдәгесен әйткәнсез», кебек бихисап күп рәхмәт сүзләре – әдәбиятта бу теманың да урыны булырга тиешлеген раслады.

Гомумән, әсәрләрнең берничә варианты туу – табигый күренештер, мөгаен, чөнки күңелдә кайнаган хисләрне кайчагында бер жанр гына сыйдырып бетерә алмый кебек. Әйтик, минем дә «Бер кычкырды кәккүк» дип аталган шигъри әсәрем, параллель рәвештә үк дип әйтерлек, «Мизгел» исемле повесть булып та яралды. «Җанлыдан җан яралгач» исемле повестем дә, шигырьләр, очерклар, пьеса рәвешендә, кабат-кабат мәйдан сорады. Аларның «Рәнҗү», «Дала уртасында мәңгелек ут», «Кыл уртада басып тора Ана» ишеләрен яттан өйрәнеп, укучылар театр училищеларына керү имтиханнары вакытында сөйләделәр, төрле конкурс-смотрларда катнаштылар. Бу хакта миңа шул елларда жюри әгъзалары булган Шәүкәт Биктимеров, Гөлсем Исәнгулова, Ирек Баһмановларның әйткәне булды.

Тугансың икән, хәтта Коркыт карт кебек тырышсаң да, үлемнән качып булмый шул. Җан яралу шатлык китерсә, җир куенына озату – кайгы. Кеше күңелендә буранлаган әнә шул бихисап хисләр шигырь дә, җыр да, бәет тә, чәчмә әсәрләр дә булып туа. Ә инде дөньядан фаҗигале рәвештә китү, үзең теләп тормыштан баш тарту – исәннәр күңеленә гаять зур газап сала!

Әйткәнемчә, «Мордар» поэмасына Фаил исән чагында ук нигез салынган иде. Гөрләп яшәгән вакытта «әти» сүзеннән мәхрүм ителгән сабыйлар, җир читеннән алып кайтып, җиде юл чатында адаштырып калдырылган яшь хатын, киләчәктә караучым булыр, дип,

өметләнеп яшәгән карт ата... Шундый хыянәтне башка сыйдырырга мөмкинме? Кем гаепле? Сәбәп нәрсәдә? Менә шундый уйлар өермәсендә йөргәндә, мөлдерәмә тулы чиләккә соңгы тамчы булып, әнкәйдән хат килеп төште: «Күршебез Равил, биш баласын калдырып, асылынып үлде!..» Аннан алда гына авылыбызда (әллә ялгыш, әллә махсус) агу эчеп дөньядан китүчене җирләгәннәр иде.

Поэма тәмамланган кебек булгач, мин аны татар теле һәм әдәбияты укытучысы, 40 еллап укыту тәҗрибәсе булган, классик шагыйрьләрнең, бигрәк тә Такташның барлык шигырьләрен диярлек яттан белүче дустым Роза Кушминага күрсәттем. Ул, укып чыккач: «Кара төн уртасында таягына таянып, юл кырыйларыннан, чокыр-чакырлардан улын эзләп йөрүче ана образын да керт», – диде.

Таягымны юлдаш итеп,
Җиде төннең уртасында,
Улым, тагын сине эзлим,
Бәгыремне кортасың ла.
Кайда аунап ята тәнең
Бер кадерсез бәндә булып?
Өйдән чыгып киткәндә ук
Күзкәйләрең бетте тонып... –

дигән бүлек әнә шулай туды.

Бөегебез Габдулла Тукай турындагы «Без – Тукайлы халык!» поэмасының башлангычы исә 1984-1985 елларга карый. 1986 елда Мәскәүдә үткәрелгән «Татар әдәбияты көннәре» декадасына мин аның «Якты исем» һәм «Язы барның» дигән бүлекләрен, берләштереп һәм кыскартып, укырга әзерләгән идем. 1988 елда нәшер ителгән «Гөлләр елы» исемле китабымда, «Без – Тукайлы халык!» дигән баш астында алар шулай ук туплама рәвешендә чыкты. Тупламага кергән, Тукайның әнисенә багышланган «Бибимәмдүдә» шигыренең, беркайда да басылмаган тагын берничә варианты бар. Ә инде:

«Без – бәхетле,
Без – шагыйрьле халык,
Без – Тукайлы халык мәңгегә!»

– дигән юллар, байтактан канатлы сүзләргә әйләнеп, Тукайга багышланган кичәләрнең сценарий нигезен тәшкил итә, мәктәп сәхнәләренең түренә девиз рәвешендә язылып, эленеп куела башлады.

«Без – Тукайлы халык!» биографиясендәге вакыйгалар байтак. Шуларның тагын берсе турында журналист Нәсим Акмал үзенең «Шагыйрә имтихан тотты» дигән, 2002 елда «Шәһри Казан» газетасында басылган мәкаләсендә менә ничек язган иде: *«Татар шагыйре өчен иң катлаулы сынау нәрсә? Үз шигыреңне Тукай алдында сөйләүдер. Чөнки бу үз вөҗданың каршында имтихан тоту белән бер. Кемдер әле синең иҗатыңны күккә чөеп мактарга, салпы ягыңа салам кыстырып үсендерергә мөмкин. Ләкин үз әсәрләренең нинди югарылыкта булуын шагыйрь, әгәр ул чын шагыйрь икән,үзе генә аңлап, белеп торадыр.*

Сөекле шагыйребезнең туган көне якынлашканда Г.Тукайның Казандагы әдәби музеенда Эльмира Шәрифуллина әнә шундый имтихан тотты. Биредә аның Тукайга багышлап язылган «Шагыйрь чишмәсе» («Без – Тукайлы халык») дигән поэмасы сәхнәләштерелеп күрсәтелде. Үзенчәлекле шигъри спектакльнең сценарий авторы да, режиссеры да – шагыйрә үзе. Хәтта башкаручылары – Казанның 1 нче педагогия көллияте студентлары да – үз шәкертләре. /.../ Студентлар шигырьнең тәмен, сүз куәтен, ләззәтен тоярга, шул ләззәтне башкаларга да җиткерергә өйрәнгәннәр. Менә кемнәр киләчәк безнең мәктәпләргә!

Мәгънәле, хисле-моңлы әсәр өчен дә, шушы фәһемле шәкертләре өчен дә сөенгәндер Тукай рухы».

Хәзер монысы да тарих бит инде: «Быел Г.Тукайның 120 еллыгы уңаеннан музей алдында зур эшләр тора. Шул уңайдан без «Тукай һәм аның заман-

дашлары» дигән цикл ачып җибәрәбез», – дип башлады үзенең сүзен музей директоры Рәмис Аймәт. «Юллар чатында» дип исемләнгән әлеге кичәдә әдип Фатих Әмирханның иҗатын өйрәнүче галимнәр катнашуы очраклы түгел. /.../

...Шагыйрә Эльмира Шәрифуллина исә бик тә кирәкле проблема күтәрде. Телебезне үстерүгә зур өлеш керткән язучының *(Ф.Әмирханның. –* **Э.Ш.***)* музее булмавы өчен борчылуын белдерде. /.../»

Л.Галимҗанова, «Шәһри Казан», «Әдип исеме күләгәдә кала», 27.01.2005»:

«Әлеге мәкаләгә өстәп, Яңа Савин районындагы 170 нче мәктәпнең «Большая перемена» исемле мәктәп газетасыннан да бер өзек китерик:

«Шарифуллина Э.М., заслуженный деятель искусств РТ, член Союза писателей СССР и РТ, поэтесса. Встреча с этой поэтессой определила судьбу музея им. Ф. Амирхана./.../

«Роль школьного музея в формировании духовного мира школьников»,

27. 01. 2006»

«Каюм коесы» исемле поэмамның да язмышы бәхетле булды, дип исәплим. Яшел Үзән шәһәренең 10 нчы гимназиясендә инде дистә елдан артык барган «Насыйри укулары»ның тантаналы өлеше шушы поэмага нигезләнеп алып барыла. Аның, Татарстан дәүләт радиосы архивында, нәфис сүз остасы Айрат Арсланов укуындагы язмасы саклана. Гомумән, Татарстан дәүләт радиосы архивында талантлы драма артистларыбыз Вера Минкина, Шәүкәт Биктимеров, Дания Нурлы, Юныс Сәфиуллин, Хәлимә Искәндәрова һ.б.лар катнашында язылган тагын ике «Тәмуг кисәве» һәм «Мордар» дигән поэмаларым бар. Аларны, музыкаль бизәлеш белән, режиссерыбыз Госман абый Әхмәтҗанов эшләгән иде.

Сөембикә, Габдулла Тукай, Каюм Насыйри, Муса Җәлил, Фаил Шәфигуллин, Бакый Урманче, Сара Садыйкова, Мөхәммәт Мәһдиев, Фатих Әмирхан һ.б. кебек халкымның кадерлесенә әверелгән шәхесләребезгә кайта-кайта мөрәҗәгать итүем, әсәрләремдә аларны терелтү, фидакяр хезмәтләрен танып баш ию – мирасыбыз чыганакларын барлау, югалтмаска тырышу, шул ук архив – үткәнебез һәм киләчәгебез турында кайгырту лабаса.

Киләчәгебез, дигәннән, балалар язмышы мине бервакытта да битараф калдырмады. 1987-1988 елларда «Азат хатын» («Сөембикә») журналында «Асрамага бала бирәм» исемле рубрика белән республикабызның балалар йортларында тәрбияләнүче балалар турында язганда, үткәннәргә кайтып, ачлык, сугыш елларындагы балалар язмышын да өйрәнгән, кызыксынып архивларга мөрәҗәгать иткән идем. Язып алганнарымның, журналда басылганнары белән беррәттән, блокнотымда калганнары да байтак икән.

Менә алар.

1920 ел, 19 август. Татнаркомпросның балаларны саклау бүлегенә

«...Сукыр балалар училищесындагы балалар, беренче чиратта эчке киемнәргә, бигрәк тә, берәр пар булса да оекбашка, теш щеткалары, таракларга мохтаҗ. 2 генә данә булса да дәреслек кирәк. Күрмәүчеләргә кече яшьтән белем бирү, хезмәткә өйрәтү сорала. Кешенең гыйлем һәм һөнәр үзләштерү вакыты нәкъ менә үсмер һәм яшьлек елларында бит...»

Сукырларга бәйле тагын бер документ:

«Рәсәйдә 1897 елның 28 гыйнварында, беренче гомум җан исәбен алу вакытында сукырлар:

116204 ир кеше (йөз мең ир-атка – 186);

131696 хатын-кыз (йөз мең хатын-кызга – 208);

Гомумән: 247900 кешегә (йөз меңгә – 197 кеше).

Казан өязендәге сукырлар:

5382 ир-ат (йөз мең ир-атка – 508);

7458 хатын-кыз (йөз меңгә – 671);

Гомумән: 12840 кешегә (йөз меңгә – 592).

Ишетмәүче-күрмәүчеләр:

2264 кеше (йөз меңгә – 104 кеше).

Рәсәйдәге Казан өязе, бу мәсьәләдә I урында тора. Өстәп: сукырлар санының һәр йөз мең кешегә Англиядә – 87, Германиядә – 85, Франциядә – 84, Америкада – 52, Голландиядә – 40, Даниядә 30 кеше туры килүен әйтергә кирәк.

Әгәр дөрес дәвалану, шифаханәләр ярдәме булса, без дә Голландия, Дания кебек илләр рәтенә басарбыз».

Архив документларын актарганда тагын шунысы күзгә ташлана, балалар бакчаларында да, балалар йортларында да татар балалары күпкә аз булган. Әйтик, 1919 елның икенче яртысында балалар бакчалары буенча төзелгән сметадан күренгәнчә, 61 рус балалар бакчасында – 5250, 10 мөселман балалар бакчасында 920 бала тәрбияләнгән.

1928 елның 15 октябрендә Свияжск хезмәт колониясендәге караучысыз балаларның (беспризорниклар) милли чыгышын күрсәтеп теркәп куелган мәгълүматта 73 рус, 16 татар, 4 керәшен, 2 чуваш икәнлеге әйтелә.

Балалар язмышына, мәктәп тормышына кагылышлы аяныч бер язма. Ул – Алабуга шәһәре реаль училищесы директорының Татнаркомпросның уку-укыту бүлеге Идарәсенә язган аңлатма хаты:

«14 февраль төнендә Сарапул шәһәре ягыннан җәза максаты белән Кызылгвардия килде. Безнең училище укытучысы (законоучитель) Павел Дернов үзенең өч улы белән кулга алынды, улларының берсе – училищеның 7 нче сыйныф укучысы.

Дернов кызылгвардиячеләр тарафыннан шул ук төндә үтерелә. Ә улларын икенче көнне көндезге сәгать 4тә аталар.

Законлы укытучының ни өчен үтерелүе билгеле түгел.

Өемдә җентекле тентү үткәргәннән соң, төнге сәгать 2дә мине дә кулга алдылар, әмма икенче көнне көндезге сәгать 12дә, бернинди сорау алуларсыз, җибәрделәр.

Тентү башка укытучыларда да булган, тик алар кулга алынмады.

Җәза отрядының революцион штабы, минем үтенечемне канәгатьләндереп, училищеның башка укытучы һәм укучылары кулга алынмаячагына язма гарантия бирде.

Хәзер дәресләр, укыту эшләре тәртиптә.

Директор: Вербийский. 1918».

«Архив материаллары белән эшләү – мин белгән эшләрнең иң тәэсирлесе, иң мавыктыргычы», – дип яза М.С.Шагинян. Бу чынлап та шулай. Шөгыльләнгән кадәресе минем дә иҗатымны баетты, дип әйтә алам. Мәсәлән, татар халкының күпкырлы шәхесе Фазыл Туйкинның тормышы һәм эшчәнлеге турында өйрәнүләрем, аның иске татар теле язуындагы әсәрләрен гамәлдәге алфавитка күчереп киң катлам укучыга тәкъдим итүем, мәрхүм ирем – Фаил Шәфигуллинның вафатыннан соң 9 китабын төзеп чыгаруым – бу эшкә балаларым, оныкларымны да тарта алуым – әлеге шөгыльнең, чынлап та, мавыктыргыч һәм файдалы булуына бер дәлил.

«Безнең мирас» журналының мирасыбызны, архив материалларын саклау һәм торгызу юнәлешендә киң кырлы эш алып баруына сөенәм һәм укып туйгысыз бай эчтәлекле журнал чыгарулары өчен хезмәт коллективына һәм, әйтерсең, нәкъ шушы эш өчен туган баш мөхәррир Ләбиб Леронга чын күңелемнән рәхмәт әйтәм!

РЕДАКЦИЯДӘН: Танылган шагыйрә Эльмира Мөхәммәт кызы Шәрифуллинаның июнь аенда гомер бәйрәме. Каләмдәшебезне бу күркәм вакыйга белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз.. ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

Заһир Бигиев
(1870-1902)

Күренекле мәгърифәтче, татар укучысына «Меңнәр, яки гүзәл кыз Хәдичә», «Зур гөнаһлар» романнары аша таныш[1] каләм иясе Мөхәммәтзаһир Ярулла улы Бигиевнең биографиясенә турыдан-туры бәйле рәсми документлар юк диярлек. Бөтен булган кадәресе – «Мавәраэннәһердә сәяхәт» әсәрендә автор үзе телгә алып киткән берничә факт һәм шул ук китапка бертуган энесе Муса Бигиев (1873-1949) язган кереш сүздәге биографик белешмә генә.

Бигиевләр нәселе асыл чыгышлары белән Пенза губернасының Чембар өязе Кикин исемле авылдан була[2]. Әдип үзе Ростов-Донда туа, 1891 елда Казанда Күл буе мәдрәсәсен тәмамлый, шуннан соң туган шәһәренә кайтып, гомеренең азагына кадәр биредә имам-хатыйп вазифасын башкара.

1893 елның 11 июлендә Заһир Бигиев Мавәраэннәһергә (Урта Азиягә) юл тота. Беренче максаты Бохарада газета ачу һәм, күңеленә ята калса, берәр мәдрәсәдә укырга калу булса да, бу максатларның һәрберсе тормыш чынбарлыгына бәрелеп челпәрәмә килгәч,

[1] Әдип тәгаен язып калдырган «Мөртәд» һәм «Катыйлә» романнарының язмышы бүгенгәчә билгесез.

[2] Хәзер бу авыл Пенза өлкәсенең Каменка районына карый.

сәяхәтен фәкать гади мосафир-турист сыйфатында гына дәвам итә. Кайчандыр мәгърур дәүләтләр тоткан бердәм төрки халыкның бүгенге хәле – гамьсезлеге, наданлыгы, артта калганлыгы, яшәгән урыннарының җимереклеге, пычраклыгы, шапшаклыгы аның күңелендә гаять авыр хисләр уята. Милләт тормышындагы тискәре күренешләрне әдип гомум мәдәни дәрәҗәнең түбәнәю нәтиҗәсе итеп карый, боларның сәбәпләрен милли горурлык, ватандарлык хисе сүрелүе, тарихны, үткәндәге рухи мирасны белмәү, ул мирасны тудырган шәхесләрне санга сукмау – кыскасы, кешеләрдә гыйлем-мәгърифәткә омтылыш кимү, иҗтимагый аң, әхлак принциплары тупаслану белән аңлата.

Язучы, күңеле тәмам сүрелгән хәлдә, 1893 елның 23 сентябрендә туган шәһәре Ростов-Донга кайтып җитә. Ләкин кайткач та тирә-ягындагы тормыштан юаныч тапмый. Төшенкелектән чыга алмыйча, юлъязмаларын рәткә китереп, үзенең соңгы әсәрен – «Мавәраэннәһердә сәяхәт»ен («Транс-Оксаниягә сәфәр») китап итеп эшли. Аннары сигез елдан артыгракка сузылган газаплы, рухи бушлык белән өртүле гомеренең ахыргы әйләнеше башлана. «Гаять көчле авырулы бер хәлгә төштем, – дип язып куя ул сәяхәтнамәсенең соңгы битендә. – Башлануы кайгыдан юану өчен бер кәеф-сафа кору сымаграк булып күренсә дә, ахыры соң дәрәҗәдә һәлакәтле булды. Кулыма каләм тотмас хәлгә килдем. Тормыш ләззәтләреннән өмет өздем. Моннан соң яшәвемдә файда булмас, дидем дә әҗәл сәгатен, Газраилнең визитен көтә башладым...»

Заһир Бигиевнең тәгаен ничек мәрхүм булуы турында анык фикер юк. Соңгы елларында әдип «күкрәк чире»ннән интеккән, шуның аркасында күп вакытын Түбән Стеблевка авылында уздырырга мәҗбүр булган. Ләкин кабергә керткән сәбәп шулмы – билгесез. Арада «хатыны агулаган» (бу фикерне Мөхәммәт Гайнуллин инкяр итә; галим 1950 нче елларда Ростов-Дон шәһәренә бара, анда әдипнең җәмәгатен һәм ул вакытта әле имин сакланган каберен күрә), «шәһәрдә купкан фетнә вакытында карагруһлар тарафыннан кыйналып үтерелгән» (галим Мәхмүт Гайнетдинов версиясе) кебек фаразлар да бар. «Зур гөнаһлар» китабында урын алган ахыр сүздә Рәис Даутов исә болай дип яза: «Күрәсең, әдипнең авыруы торган саен көчәя барып, ахырда аны фаҗигале финалга китереп җиткерә – 1902 елның башында Заһир Бигиев, үз-үзенә кул салып, күптәннән бирле күңеле тарткан «мәңгелек йортка» китеп бара...» Тарихчы-галим Азат Ахунов мондый фикер белән килешми: аныңча, имам-хатыйп, тирән дини гыйлемле кеше, Аллаһ тарафыннан иңдерелгән гомерне үз куллары белән өзәргә базмас иде.

Безгә шушы фаразларның берсенә иярергә генә кала. Чөнки әлеге үлемгә кагылышлы асыл хакыйкать беркайчан да ачылмас инде, мөгаен.

Рүзәл Мөхәммәтша *әзерләде.*

Әдәбият

1. Ахунов Азат. Известный и неизвестный Загир Бигиев // ж. Гасырлар авазы – Эхо веков, 2006. – №1.
2. Бигиев Заһир. Зур гөнаһлар. Романнар һәм сәяхәтнамә. Төзүчесе, төп текстның транскрипциясен һәм хәзерге әдәби телгә тәрҗемәсен эшләүче, искәрмәләр һәм ахыр сүз авторы Р. Даутов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – Б.360 – 279.

Безнең мирас №6 июнь 2017

БАТТАЛ БУЛУЫН ОНЫТМАДЫ...

Фәрит Баттал

Сулдан уңга: Салих Баттал, Долория, Вячеслав, Ольга Яковлева. 1940 нчы еллар

Салих Батталның өч баласы бар иде: Мәрьям исемле татар хатыныннан Виктор һәм марҗадан Вячеслав белән Долория. Мөбарәк абый сөйләгәнчә, беренче малае туганда Салих абыйның Виктор Гюго романнары белән мавыккан чагы була. Улына кушылган француз исеме – шуның нәтиҗәсе. Виктор абый безгә еш килә, кайвакыт ул бертуганыбыз булып ук тоела башлый иде. Килгән саен вак-төяк уенчык, йә туңдырма, йә китаплар китерә, безне корыч мускуллары белән сокландыра иде.

Шахмат уенында мин аны бер мәртәбә – кыш көнендә ул яланбаш килеп, башы авырткан чакта гына ота алдым. Виктор абый, безгә кушылып, әтисенә дә рәхәтләнеп кунакка йөри иде. Дөрес, армиядән кайткач, аралары суынды: Салих абый аңа «чирәм җирләр»ен үзләштерергә китәргә кушты да... улы әтисен тыңламады. Салих абыйның җияне (Галимҗан абыйның улы) Шамил абыйга да шундый агитация ясалган. Егерменче еллар ачлыгыннан котылыр өчен үзенә авылдан китәргә туры килгәч, тыныч заманда башкалар да чит якта бәхет эзләсә яхшы, дип са-

Ахыры. Башы журналның 5 нче санында.

наган ул, күрәсең. Ләкин аның сүзенә һичкем колак салмады.

Виктор абый углеводород чималы институтында уңышлы эшләде. Ләкин этисе «аркасында» аңа да вакыт-вакыт кыен ашарга туры килгәләде. 1983 елның 16 декабрендә «КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Г.И.Усмановка язучы Салих Батталдан» юлланган гаризадан өзекне (автор язганча калдырам) китерик: *«Ныне уже от пожилых солдат я слышу о том, как полюбившийся в школьные годы афоризм «Баттал икәнемне онытсам да, сафта икәнемне онытмам» стал в годы их службы в армии общей клятвой народу.*

Это и моя пожизненная личная клятва. Верный ей, стоя на страже ленинских идей в литературе как часовой, забываю о личных переживаниях, когда под воздействием клеветы отворачиваются от меня школьники и педагоги, когда из-за меня страдают родные, портрет сына – инженера-изобретателя снимают с доски почёта... Всего не перечислишь».

Хәер, моңа гаҗәпләнергә кирәкме? Никита Хрущёвны дәүләт башлыгы урыныннан төшергәндә «Известия» газетасында баш мөхәррир булып эшләгән киявен дә алалар бит. Чит илдә бу хакта шаярмый калмыйлар: «Каенатасының сәламәтлеге какшау сәбәпле, «Известия» газетасының баш мөхәррире Аджубей эш урыныннан азат ителә».

Салих абыйның икенче хатыны парашютчы Ольга Яковлева иде. Алар 1948 елда аерылыша. Илленче елларда Салих абый Кадрия Ишукова – шагыйрь Фатих Кәримнең тол хатыны белән торып ала. Мөнәсәбәтләре тату була. Ләкин Кадрия ханымның кызларына этиләре урынына чит кешене күрү бик ошамагач, Салих абый бу гаиләдән дә китә.

Узе сугышта чакта аның ике баласы Мәскәүдә – Ольга Николаевнаның туганнарында тәрбияләнә. Вячеслав Суворов училищесында укый, фәнни эш белән дә шөгыльләнеп ала. Каләм шыгырдата башлагач, Салих абый аның өчен шатланып, бергә төшкән фотосурәтләре артына, шаярып: «Дюма-отец и Дюма-сын», – дип язган була. Әмма «кече Дюма»ның фәндә дә, әдәбиятта да әллә ни казанышы күренмәде. Хәрәкәтчән, бихисап ниятләрдә коенып яшәгән Вячеславны ун елдан соң очраткач танымадым. 1982 елда Мәскәүгә белем арттыру курсларына барсам, ни күрим: каршымда йончыган, таушалган бер кеше басып тора иде. «Крокодил» журналының күптәнге санында басылган, юмористик булырга тиешле мәкаләсен күрсәтеп мактангандай итте. Өстәл кәгазьләре арасында шул ук «Крокодил»дан үзгә хат һәм андагы «мәкаләгезне бастырудан баш тартабыз» сүзләре күренде.

Вячеслав 1991 елда илле өч яшендә бакыйлыкка күчкән. Хатыны Люба соңрак: «Нәшриятта романы калды», – дип белдерде безгә.

Долориянең барлыгын мин озак вакыт белмәдем дә диярлек. Бая әйтелгән уңайдан Мәскәүгә җыенганда без Салих абыйдан аның адресын сорап алдык. Туганнан туган апам белән егерме тугыз яшемдә паспорт күрсәтеп таныштым. Вячеслав өйләнгән булса, Долория аерылган икән. Икесенең дә мәктәп яшендәге берәр кызы бар. Фоторәсемнәрен сорап алып, Казанга кайткач Салих абыйга күрсәттем. Шунда ул бу дөньяда ике оныгы барлыгын белде. Сурәт артына кемнең кем баласы икәнен язганда Салих абыйның күңеле йомшарып киткәндәй тоелды. Ләкин бер ел узып, безнең чакыру буенча кызы Казанга килгәч, араларында булган элеккеге ызгышларны оныта алмыйчамы, Салих абый аны да, аны алып килгән этиемне дә бусагадан уздырмаган. (Салих абыйның: «Мин сугышта чакта Оляның бертуганы Зоя балаларны аталарына каршы рухта тәрбияләгән, шуңа күрә Долория минем белән һәрвакыт тупас сөйләшә иде», – дип аңлатканы булды.) Шул ук елның мартында безгә юллаган хатында Долория үзенә мондый характеристика бирә: *«...глупая двенадцатилетняя девочка, которая писала резкие письма под диктовку тётки. А последняя была совсем*

Безнең мирас №6 июнь 2017

не заинтересована в добрых отношениях отца и детей». (Җөмләдән, ике арадагы киеренке мөнәсәбәтләр Батталның «Сигезенчесе кем?» повестенда чагылыш тапкан.)

Салих абыйның вафатыннан соң, Долория безгә тагын килеп китте. Аңа әтисенең каберен күрсәттем, мирасы белән кызыксынгач, Язучылар берлегенә алып бардым. Шуннан соң Долория белән даими элемтә урнашты. Яңа 2000 нче ел белән котлап, кызының кияүгә чыгуы һәм бала табуы турында язган хаты ахыргысы булып чыкты.

Ата белән кызның барып чыкмаган очрашуыннан соң, Салих абый белән гаиләбез арасындагы мөнәсәбәтләр дә үзгәрде. Янына кызын алып килергә үзе рөхсәт итүгә карамастан, шушы вакыйгадан соң ул кырын карый башлады кебек. Моны һич көтмәгән әти Салих абыйга үпкәләде. Мөгамәләне җайлар өченме, күпмедер вакыттан ул үзе шалтыратты, трубкага әтине чакырды, минем аша ниндидер китапны алып килүне үтенде. Ләкин гафу сорауны ишетмәгәч, җыентыкны әти генә кертеп чыкты. Ике бертуган арасы берничә елга өзелде.

Советлар Союзы Герое, шагыйрь Муса Җәлил белән бергә җәзалап үтерелгән сугышчыларны орден белән бүләкләү көтелә, дигән хәбәр илтүне сылтау итеп, 1988 елда хәлен белергә килдем. Кешегә ышанмаска өйрәнгән Салих абый: «Мин исәнме, юкмы икәнен тикшерергә килдеңме?» – дигән сорау белән каршы алды.

Нидә мәгънәсе яшәүнең?
Җавап бар минем дә бер –
һәркемнең тоткан урнында
һәм туган илендәдер.

Әйе, уен түгел яшәү.
Шушындый чаклар була –
күз йомасың – йокы алмый,
ачасың – кошмар була.

Партиядән куылган, дистәләгән еллар буена кыерсытылган чакларда беркемгә ышанмау үзен аклагандыр, билгеле. Бервакыт, ишеген ничектер ача алып, аның өенә таныш булмаган җирән сакаллы егет килеп кергән, дип сөйләде әти. Керү максатын да аңлата алмагач, Салих абый аны боргычлап милициягә тапшырган. 1983 елда Салих абыйның телевизорын төзәтер алдыннан бушаган розетканы беркеткәндә стена куышыннан бер-берсенә эретеп ябыштырылган ике транзистор килеп чыкты. Абыйга боларның радиоприборларда куллана торган детальләр икәнен аңлаттым. Шуннан соң берничә көннән телефонын тикшерергә дип килгән монтёрга Салих абый: «Минем өйдә сөйләгәнемне тыңлар өчен дәүләт акчасын әрәм итмәгез, мин сезнең өчен кызык нәрсәне сөйләмим бит», – дигән. Әлбәттә, мондый очракларны Салих абый махсус оешмалар казынуы итеп күрде. Бәлки, теге монтёрның килеп чыккан транзисторларга катнашы да булмагандыр, тик үзгәртеп кору елларында «ышанычсыз» кешеләр фатирларына тыңлап тору җайланмалары куелу турында мәкаләләр басылгалады. Ләкин Салих абыйның гадәткә кергән шикчеллеге гомере азагында аны дусларыннан, туганнарыннан аерды.

Хәтере калуга карамастан, кызыклы мәгълүмат, бигрәк тә җәлилчеләргә кагылышлылары белән уртаклашыр өчен, әти дә Салих абыйга шалтыраткалаган, берничә мәртәбә өендә дә булып кайткан. Мөнәсәбәтләрнең яхшыруын сизмәгәч, туксанынчы елның мартында бәхилләшергә барган. Салих абый: «Әллә мин тиздән үләрмен, дип уйлыйсыңмы?» – дип сорагач, әти: «Кем белә, бәлки алданрак мин үлеп китәрмен», – дип җавап кайтарган һәм... юраганы юш килгән.

Соңыннан Салих абый янына Фәридә, Галимҗан абыйның кызы Рауза апа барган, ул алар белән дә ишек катында ике-өч сүз алышудан узмаган.

1989 елның апрелендә без моңсу уйлар уята торган хәбәр ишеттек: Салих абыйга «50 лет пребывания в КПСС»

Фатих Кәрим каберен яд иткәннән соң.
Уртада Салих Баттал белән Кадрия Ишукова.
1958 ел

түштамгасын тапшырганнар икән. Юк, мыскыллап әйтмим: гаделлек өчен көрәшкәндә партиядән куылып, егерме елдан соң съезд тарафыннан анда торгызылуың – зур җиңү, принципиаль эш. Партия стажы тергезелүен таләп итеп, Салих абый дөрес эшләгән. Кызганыч, әлеге тамганы алырга Салих абыйның чираты җиткәндә КПСС белән бәйле атрибутларның кадере беткән чак иде инде.

1990 елның октябрендә Салих абый хатыны Мәдинә апа белән бергә циркка – им-томчының «дәвалау» сеансына барып шаккатыра. «Табиб», үзенә реклама ясауга бирелеп, сеансны башламыйча торгач, Мәдинә апа аны ашыктыра башлый, ләкин «сихәтләргә» тиешле бәндә: «Сезне паралич сугачак!» – дип укынып, боларны бөтен тамашачы алдында цирктан куып чыгара.

Советлар Союзы Президенты М.С.Горбачёв указы нигезендә җәлилчеләр Беренче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены белән бүләкләнгәч (ул вакыттагы СССР халык депутаты, язучы Туфан Миңнуллин тырышлыгы ярдәмендә), 1991 елның 24 декабрендә Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев орденнарны яугирләрнең туганнарына тапшырган. Әлеге уңайдан эшләнгән репортажны монтажларга килгән мөхәррирне үзем эшләгән телестудиядә очратмасам, бу хакта белмичә дә калган булыр идем. Абдулла Батталга тиешле орденны илбашы кулыннан Мөбарәк абый алганын күргәч, әти аңа шалтыраткан:

– Син моны каян белеп бардың соң?

– Салих абый әйтте, – дигән ул. – Аны чакырганнар да, бара алмагач, миңа хәбәр итте.

– Нигә соң син безгә әйтмәдең?!

– Сиңа инде әйткәннәр, дип уйладым...

Әлбәттә, этинең кәефе нык кына кырылды: «Улым! Кайсы җәлилчеләрнең туганнарын Казакъстаннан ук табып кайтарганнар, ә монда бертуганнарың санга сукмасын...»

1993 елның июлендә Салих абыйның соңгы – дүртенче хатыны Мәдинә апа мәңгелеккә күчте. Әлбәттә, Салих абый

шуннан соң да төрле очрашуларга йөрүен дәвам итте, газеталарда басылып торды, хәтта «Встреча с Батталом» дигән телевизион тапшыруда да катнашты (интервьюны өендә алдылар). 1994 елда «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясендә уналты фронтовик җыелды, шулар турында чыккан репортажда сиксән сигез яшьлек Салих абый турында мондый сүзләр язылган: «...*гаярь очучы Салих Батталның туксанда да зиһене сокланырлык. Солдат җырын җырлап көлдереп тә алды*». Бакчасында безгә сәнгатьле итеп укыган «Губ со смыком» турындадыр сүз, дип сагышлы елмаеп куйдым...

Салих абыйны соңгы күрүем 1994 елның 25 августында булды. Бу – җәлилчеләрне, шулар арасында Абдулла Батталны да җәзалап үтерүгә илле ел тулу уңаеннан кирмән янында аларның барельефларын ачу тантанасы көне иде. Тантанага килгән Салих абый белән исәнләшкәч, ул миңа: «Туганнардан икәнеңне аңлыйм, танымыйм гына», – диде.

– Фәрит, Фуат малае, – дип җавап бирдем.

– Ә-ә, искә төшердем. Үзгәргәнсең.

Сүз бирелгәч, Салих абый җәлилчеләр батырлыгына багышланган кыска шигырен укыды да, рәхмәтле саубуллашу кәлимәсенә вакыт әрәм итмичә, микрофон яныннан китте. Тантана озак барды. Аякларым арып кремль янында чүгәләп тордым. Һаман басып торган ветераннар ничек түзде икән? Тиздән Ләйлибәдәр апаның улы Рәшит абый белән Салих абыйның Милли музейга киткәнен күрдем. Тантана тәмамлангач, Салих абыйга студия автобусында өенә кайтырга тәкъдим иттем (ул студиягә якын тора иде). Шулвакыт язучы Рафаэль Мостафин аны Җәлил музейфатирына барып чәй эчәргә чакырды. Чәй турында ишеткәч, абый, миңа җавап бирмичә, Мостафинга иярде.

Чираттагы елның уникенче мартында Салих абыйның вафатын ишеттек. Йортына барганда Мөбарәк абый белән хатыны Рәисә апаны очраттым. Фатирның ватык ишегендә милиция суккан мөһерле кәгазь ябыштырылган иде. Күршеләрдән белдек: төтен сизгәч, алар янгын сүндерүчеләрне чакырган. Төнлә Салих абый йоклаган бүлмәдә янгын чыккан икән. Үзен тәрәзә янында яткан килеш тапканнар, кул-аякларына ут тигән. Милициядә безгә, «труп в морге», диделәр. Соңыннан Виктор абый сөйләгәнчә, бу салкын төннәрдә туңганга күрә, әтисе бер розеткага күп электр җылыткычларын тоташтырган һәм тирә-ягына тезеп җылынган икән. Көчәнеш артудан пробкалар атасы урынга розетка дөрләп янып киткән.

Ундүртенче мартта Салих абыйның гәүдәсен Язучылар берлегенә алып килделәр. Рәис Ринат Мөхәммәдиевтән соң, Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Рабит Батулла, Локман Бадыйкшан, Харис хәзрәт Салихҗан сүз алды, туганнардан – Мөбарәк абый, Рәисә апа чыгыш ясады. Мәчет аша Яңа бистә зиратына җитеп, Салих абыйны моргтан китергән табутта нәкъ әнисе (минем дәү әни) каберенә күмдек. (Шуңа күрә соңыннан кабер ташлары да икесенә бер булды.) Урыннары Тукайдан ерак түгел – Салих абый яраткан шагыйренә мәңге якын булып калды.

Шагыйрь, «Баттал икәнемне онытсам да, постта икәнемне онытмам» сүзләрен «үземне механизм итеп сизгән вакытта яздым», ди. Моңа ияреп үзгәртелгән җавапның кайчан булса да килеп чыгуы көтелә иде. 1990 елда мактаулы да, кайгылы да «диссидент» исеме чыккач, шагыйрь Нури Арслан аңа дусларча болай дип яза: «*Кемнәр булуыңны онытсаң да, Баттал булуыңны онытма!*» Салих абыйның бу хакта онытканы булмагандыр. Үз карашларыңны көрәшеп якларга туры килгәндә, фамилияңне онытырга бирмиләр.

Әти сугыштан кайтмаган Галимҗан, Абдулла абыйларын кызганып исенә төшерә иде, Салих абый турында горурларып: «Ул үлгәч, аны күтәреп алачаклар әле», – ди иде. 1996 елның ма-

Казанда Бертуган Батталовлар урамы.
2016 ел

енда матбугатта, Казан урамнарының берсенә Салих Баттал исемен кушарга кирәк, дигән тәкъдим күренде. Кайчандыр чынлапмы, шаярыпмы, Салих абый болай дип язган:

Менә буксир. Аның тәгәрмәче
өсләрендә – исме: «Джон Рид».
Нигә ышанмаска, киләчәкнең
бер буксиры «Баттал» булыр дип?!

1985 елга исә фикерен үзгәртә:

Мин Шамил йә Ибраһимов түгел;
проспектсыз да ярар, ничек тә,
үлсәм, исмемне таптамагыз
урам түгел, сукмак итеп тә.

Кеше дусты идем. Рефлексларым
үткен булган бәлки шуңа да?
Колтушида Павлов этләренә
куйган һәйкәл җитәр миңа да.

1996 елның ноябрендә без бар туганнар исеменнән шәһәр администрациясенә төзәтмә-гозеребезне тапшырдык: Салих абый истәлеген мәңгеләштерергә уйланылса, энесе Абдуллага да ихтирам күрсәтеп, урамнарның берсенә «Бертуган Батталлар» исеме кушылсын иде, дидек. Тәкъдимебез белән килешмәсәләр, бу фамилиягә бөтенләй тимәскә үтендек. Чөнки ул очракта Абдулла абый онытылачак, дип санадык. Казанда булмаса да, хәзер Олы Тигәнәледә Салих Баттал һәм Абдулла Баттал урамы бар. Моның өчен авылдашларга мең рәхмәт!

Шулай да...

2015 елның 8 октябрендә Казанның Идел буе районындагы М-14 торак комплексындагы (республика клиник хастаханәсе артында) яңа урамнар исемле булды. Шәһәр башкарма комитеты карары нигезендә аларның берсенә язучы, шагыйрь Салихҗан Батталов белән алман әсирлегендә Гайнан Кормаш оештырган яшерен төркемдә илбасарларга каршы көрәшкән Абдулла Батталов хөрмәтенә «Бертуган Батталовлар» исеме бирелде. ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

УТЛЫ КИСӘҮ

Лерон Гыйльфанов

(Истәлекләр, уйланулар)

Хатирәләр суда батмый, утта янмый.

Ләкин бу чорда «утлы кисәү» бераз сүрелде.

Касыймов абый үзенә бернәрсә дә таләп итмәде. Моннан мунча бурасы да буратып алып китмәде. Саламнарны вакытында өйдерә иде. Көзге сөрү чорында сөргән җиргә килми калган көне булмады. Килгәч, тракторны туктатып тора идек. Менә ул профессорларча үзенең киңәшен әйтә: «Лерон, син беләсеңме, менә болай ит: тирәнлек ул бер уровень түгел, сөреп барганда кара балчыктан әрлән балчык чыга башласа, менә шул тирәнлек», – дия иде. Ә алда язып узган колхоз хуҗасы моның ни икәнен белмәде, белергә дә теләмәде. Менә сиңа ике кеше – ике төрле караш. Касыймов абый хезмәтемне күрә белде. Аның чорында, районда зәп сөрүне 300 гектарда башкарып, беренче урын алдым һәм мине телевизор белән бүләкләделәр. Бер елны баян бирделәр. Ике тапкыр шифоньерлы булдым. Аннан чәчүдә колхоз буенча беренче урын алгач, район буенча 30 кешелек төркем белән Казан Сабан туена бардык. Касыймов абый мине Мәскәүгә ВДНХга җибәрде. Колхозда берничә тапкыр беренче урын алдым.

Касыймов абый киткәндә тыныч китте. Мондый шәхесләр – үз эшенә бирелгәннәр сирәк була. Колхоз, дәүләт байлыгына кул сузмады ул. Гадел кеше иде, җаны җәннәттә булсын. Шулай да аның белән узган эшләр турында сөйләшеп, безнең өйдә берничә сәгать ашап-эчеп утыру насыйп булды. Вафат булганын белми калдым, соңгы юлга озата алмадым – ни кызганыч!..

...Касыймов абый урынына район җитәкчелеге Тойгельдедә зоотехник булып эшләгән, 1941 елгы булса кирәк, Биктимеров дигән кешене алып килеп, җыелыш ясап, колхозга баш итеп куйды. Бу кеше минем үземә башта ук ошамаган иде. Сәхнәгә менгәнче күн кепка иде башында. Минем белән рәттән бер эскәмиядә утырды. Күңелем сизгән булса кирәк. Җыелыш аны сайлагач, мин арттан сорау бирдем: «Эшләве күпкә булырмы?» – дидем. Ул халык алдында әйтте: «Моннан китмим, әгәр эштән чыксам, монда дуңгыз булса да көтәм», – диде. Әмма язмышның үз законы була шул. Бу кеше турында озак язып булыр иде, ләкин файдасызга. Үз җимеше үзенә инде...

Мин үзем колхозның идарә әгъзасы, шактый еллар партком әгъзасы булып тордым. Биктимеровны эшеннән алу өчен район прокуроры Кузьмин, авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Әхмәтшин абый һәм тагын бер кеше килде. Шулай итеп, бу «куян»ның гомере кыска булды...

Алдагы язмыш ничек булыр – ул хакта да уйларбыз әле.

1946-1960 елларда Түреш авылы Карамалыга таба 27 хуҗалыкка артты. Ә инде кабат таралу чоры 1966 нчы елларда һәм 1973 нче елларда артка таба китеп алды.

Биктимеров «әмирлек» иткән чорда өч хуҗалык авылдан чыгып китте. Миңнеразый – Мөслим колхозына, ике кеше Удмуртиягә юл тотты. Фәйзыян белән мин дә шул якка аздан гына китми калдык. Бу иптәшләрнең китүләрендә авылның шул «туң баш хуҗалары» 50 процент гаепле булды. Мин белгәннәрдән генә өч «туң баш» халыкка яшәргә күп зыян салды. Кешеләр бәләкәй чана белән саламга барса, аларны җәмәгать судына бирделәр, чаналарындагы саламны туздырып бетерделәр. Ә бит авыл хуҗасының бурычы – кешеләрнең малларын салам-печән белән дә тәэмин итү. Эшләгән кеше хезмәт хакын тулысынча ала алмаган чаклар да күп булды бит...

Башы журналның быелгы 2 нче санында.

Салам белән бәйле бер хатирәне яңартып алыйк әле. Колхоз малларына трактор чанасына төяп салам ташыйбыз. Утын-агач алып кайтабыз. Салам төяүдә Әхтәм, Мирзанур, тагын бер-ике кеше йөри иде. Кайбер авылдашлар, эштән соң салам алып кайтып бирегез әле, дигәч бер ай тирәсе 13 хуҗалыкка салам ташыдык. Акча алмадым, аракы эчмәдем. Икенче авылның «таш, баш хуҗасы», күршеләрем Асия апа белән Илсурга салам алып кайткач, законсыз сүзләр белән безне үзенчә тәрбияләп, «яңадан беркемгә дә салам алып кайтмыйсыз», дип үз «указ»ын укыды. Ул әйтергә тиеш иде югыйсә: бик әйбәт иткәнсез, авылдашларыгызга булышкансыз, дип.

Тагын авылдашым Гаттаров абый турында берничә сүз. Ул «Урал» колхозында зур төзелешләр алып барды: Дусай авылында да, Яңа Карамалыда да урта мәктәп, кибетләр төзеттерде. Игенчелек алга таба зур сикереш ясады. Уңыш гектардан 30-40 центнер чыкты. Гаттаров абый районнан Мәскәүгә партиянең XXI съездына делегат булып

Леронның әтисе Хөҗҗәт һәм әнисе Хәмдия. 1939

Кечкенә Лерон әнисе Хәмдия белән. 1940

барды. «Почет билгесе» орденына лаек булды. Рәхмәт аңа!

Менә шушы Касыймов абый, Гаттаров абый кебек булсынга йөргән рәисләр белән, алар күләгәсендә «кара таракан» кебек «таш баш» авыл хуҗалары да үзләренчә авылны алга-артка алып бардылар.

Хуҗалыкны җитәкләргә «иптәш» Биктимеровтан соң Солтанов дигән кеше алынды. Бу иптәш колхоз белән 26 еллар җитәкчелек итте. Бу чорда да колхоз, ил өчен, дип, район белән алга барды. Төзелеш эшләре игенчелек, башка төрле эшләр белән бергә барды. Еллар уза торды. Дәүләт башына баш мие 80 % та эшләмәгән Горбачев-Ельциннар килде. Менә моннан инде «утлы кисәү»нең утлары икенче төрле яна башлады...

Боларны анализлап тормыйм: чын яшәү хисе артка китә башлады, илне талаучылар, наркоманнар, сугыш чукмарлары басты. Эшсезлек, колхозларны тәмам җимерү, бала – атаны, ата баланы белмәс чор килде. Шунысы кызык: илне таратучыларның ник берсен җәзага тартсыннар! 25 ел буе һаман халыкны телерадио аша шомартып, алдап-йолдап киләләр. Гомерләр гел «утлы кисәү» өстендә үтә. Авылыма бер-бер артлы начарлыклар өстәлеп тора. Шуның берсе: 1966 елда КПСС Үзәк Комитетының Пленумы булып, ил буенча мелиорация системасы кертелде, күпчелек авыл җирендә көтү

Авылдашлар җыелган чак. Рәсемдә: уңнан өченче кеше – Лерон Гыйльфанов

йөри торган урыннарны, әрәмәлекләрне, җимеш бирә торган урыннарны «корчевать итеп сөрү» башланды. Моның шаукымы безнең районга да, безнең колхозга да килеп җитте. Безнең авыл башыннан 100 метр тирәсе, зират яннары агачлык иде. Безнең бакча артындагы көтү йөри торган, имән, усак, шомырт, чикләвек агачлары үскән 50 гектар җирне «корчевать итеп» басу ясадылар. Кычкырып еламадык кына. Безнең бакча артына тракторлар агачларны төпләп килгәндә, җаным түзмичә, бер трактор янына барып, йөртүчесенә әйтәм: авыл кырыйлап агачлык калдырып булмасмы, дигән идем, ул миңа: беләсеңме, безгә приказ бирелгән, диде. Авыл халкы берни дә эшли алмады. Калды авыл ямьсезләнеп. Менә хәзер күпме җирләр кала чәчелмичә. Илдә юк авыл җиренең кадерен белгән кеше. Минем үземне авыл, аның халкының язмышы нык борчый. Урамнарга чыгам да, хәйран калам. Юктан башка нәрсә юк. Хәзерге чорда авылда ферма маллары (ат, сыер, тана, бозау, тавык фермалары) юк. Кешеләр җыелыр өчен клуб юк. Медпункт юк. Кибет юк. Кая барабыз? Яшьләргә эш юк. Кем ныклап яшәргә тели – шулар чыгып китте. Ә бит авылыбыздан күкрәк сугып мактанырлык шәхесләр чыкты. Игенче механизаторлар, терлекчеләр, нефтьчеләр, агрономнар, врачлар, шәфкать туташлары, юристлар, очучы, фән кешеләре... Иң зур байлыгыбыз – Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Наил Әюпов. Кечкенә бер авылга өч язучы, шагыйрь: Харрас Әюпов, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Ләбиб Лерон.

БЕЗ ӘЛЕ КАЯ БАРАБЫЗ?

Берничә сүз үзебезнең төп йорт хәлләре турында. Элек авылыбыз зираты такта койма белән әйләндерелгән иде. Моннан 10-15 еллар элек Мөслимдә яшәүче ике авылдашыбыз (Илгиз Низамов, Мөҗәһит Әхмәтҗанов) авыл халкын җыеп, уртак фикергә килеп, зиратны тимер материалдан эшләтте. Кирәк-яракны куярга тимеркалай будка бар. Зиратта елга ике тапкыр өмә уздырыла. Күренекле шагыйрь Харрас Әюпов каберенә матур таш һәйкәл куелды. Исеме мәңгеләштерелеп, Харрас чишмәсе төзекләндерелеп матурланды. Күп йортларның түбәләре калайдан. Авылда зур буа бар. Юлыбыз – асфальт. Ут бар, газ кереп беткән. Ә шулай да авылның киләчәге шикле.

1921 елда Түрештә беренче йортлар корыла башлый. Чеп-чи татар авылы урыслашып бара. Телисеңме-юкмы, бу шулай. Җәй көннәрендә урыслашкан татар балаларының

Түреш авылындагы мәктәп

тавышлары йөрәккә хуш килми шул. Милләтнең милләт булып калуы кыл өстендә тора. Горбачев белән Ельцин илнең астын өскә китерә башлагач, безнең колхоз тагын икегә бүленде: Яңа Карамалы үзе бер колхоз булып башка чыгып, бераздан соң кабат Иске Карамалыга кушылды. Шушы чордан «колхоз» дигән берәмлек тарала башлады. Кемнәрнеңдер байыйсы килеп, колхозларны Казан хәтле җирдәге кешеләр кулына тапшырдылар: «Вамин» акча каракларына күчеп бетте, ахыр чиктә колхозлар банкрот булып тар-мар ителде. Безнең Түрешне, оҗмахка кертәбез, дип, «Алга» ПМКсына куштылар. Әмма ләкин монда оҗмах ишеген күрү насыйп булмады. Авыл тагын артка китә барды. Фермада маллар тотмадылар, тораклар сүтелеп бетте, ындыр табагындагы складлар юкка чыкты. Авыл клубы бетте, башлангыч мәктәп сүтелде. Ә башта ПМК хуҗасы Шәңгәрәев: клуб булыр, медпункт булыр, урамга койма тотабыз, дигән иде. Болар бар да «күке» сүзе генә булды. Боларның ничек итеп болай эшләүләрен өстәге район җитәкчелеге контрольдә тотмады. Хәзер мәктәп ихатасы «сугыштан калган» хәлдә. Ә бит авылга Казаннан да шактый дәрәҗәле кунаклар кайта, район җитәкчелеге дә күрәдер. Әмма, ни кызганыч, авылга караш сукырларча. Ә бит шушы җир, аның халкы шәһәр халкын туйдыра. Бу бер бездә генә түгел, бөтен урыс җирен биләп алган. Илгә менә 25 ел «ремонт» ясыйлар. Гадел җитәкчеләр бармак белән генә санарлык...

Кая барабыз? Тукайча әйтсәк, без әле кая барабыз? Шушы сорауны әүвәл үземә бирәм. Онытып җибәргәнмен: бервакыт колхоз хуҗалары катнашында авылда бригада җыелышы үтте. Шунда мин партком секретарена сорау бирдем. Авыл янына Карамалы яклап нарат-чыршы үсентеләре утыртырга иде, дип. Ә шунда парторг миңа, син әллә айдан төштеңме, ди. Мине ник бер авылдашым якласын! Кешене санга сугу юк иде шул, хуҗалар гына гомергә башлы-хаклы булды...

Түреш урманы җәнлекләргә бик бай иде. Аларны әллә кайлардан килеп юк итеп бетерделәр. Бар иде кыр кәҗәсе дә, урман боҗырлары, куян-төлке, кыргый дуңгыз, бурсыклар, боланнар...

Тагын авыл хуҗалыгы турында: 25 ел эчендә Дәүләт Думасында авыл язмышы турында, зурдан кубып, ник бер көн тәртибенә куеп карасыннар. Өйрәнделәр шул барысын да чит илдән ташып ашарга. Шушы бай урыс җирендә – көлке бит! – «Беларусь» тракторы ише тракторлар чыгара торган завод юк, чылбырлы трактор заводы ябылды. Ничәмә-ничә миллионнарга төшереп, чит илдән комбайннар кайтарабыз. Кызык та, кызганыч та. Әллә инженерлар юкмы соң? Ник булмасын, бар алар. Аларны күрүчеләр, эшләтүчеләр, эшләгәнгә түләргә җыенучылар гына юк. Сугыш чорында 52 хуҗалык кына булган авылымның язмышын бераз гына булса да язып калдырырга

Мәрьям апа белән Хәсән абый Салиховлар

кирәк, дигән идем. Ә шулай да халкым, нинди генә «хуҗалар» яисә «туң баш» авыл хуҗалары эшләмәсен, ил өчен башларын салып та, тыныч тормышта да булсынга, дип эшләде.

АВЫЛЫБЫЗНЫҢ ХӨРМӘТЛЕ КЕШЕЛӘРЕ

Сугыштан соң авылыбызда башлангыч классларда балаларга төпле белем һәм тәрбия бирүче (пенсия яшенә кадәр) ирле-хатынлы Хәсән абый белән Мәрьям апа (Салиховлар) булды. Хәсән абый (без аны Салихов абый дип йөрттек) үзе – Мөслимнән, Мәрьям апа Сарман районыннан иде. Алар авылны яратып яшәде, үзләренә йорт салып чыкты. Салиховлар тәрбия биргән балаларның күбесее югары уку йортларында белем алды. Араларында төрле һөнәр иясе бар.

Хәбибулла абый белән Гыйльмиямал апа (Ялаловлар). Тырыш, эшчән, тату гаилә иде. Мәрхүмнәр инде. Хәбибулла абый сугыш ветераны иде. Гомер буе шофер булып эшләде. 4 бала тәрбияләп үстерделәр. Барысы да югары белемле. Исән-саулар.

Галимулла Әюпов гаиләсе. Бу бабай авылны аякка бастыруда зур өлеш кертте. Мин белгән ике улының берсе – Исмәгыйль исемлесе – баһадир гәүдәле, тыныч холыклы иде. Сугышта зур җиңүләрдә катнашып, сугыш беткәч, туган ягына кайтып, башта Күбәк урта мәктәбендә берничә ел балаларга белем бирде, аннан соң Вәрәшбаш мәктәбенә күчте. Бераздан Мөслим колхозына партия оешмасы секретаре итеп куйдылар үзен. Бу эштә ул, колхозчылар белән кулга-кул тотынып, булсынга эшләде. Төгәл, таләпчән, намуслы кеше иде. Мәрхүм инде. Аның хезмәтен лаеклы бәяләделәр, Ленин орденына ия булды. Галимулла абыйның икенче улы – миннән ике яшькә кечесе – Наил исемле иде. Камал театры артисты иде. Тагын кабатлап әйтәм, Россиянең атказанган артисты, Татарстанның халык артисты иде. Бик яхшы җырлый, гармунда моңлы итеп уйный иде.

Авылга беренче йорт нигезләрен салучы, колхозның иң хөрмәтле кешесе Әхмәтҗан бабайның малае Мирзашәех абыйны яхшы беләм. Тәртипле кеше иде. Аны колхозның «моторы» дияргә була. Сугыш чорында башка картлар белән көнне төнгә ялгап иген үстерүдә зур өлеш кертте, муенына тубал асып орлык чәчте. Алар икәү генә иде. Урыпҗыюда, басуда көлтәләрне яңгыр үтмәслек итеп эскерткә, кибәнгә куюда эшләделәр. Бабайның бер улы Шәрип абый сугыштан кайта алмады. Икенче улы Заһит агай, сугыш чорын да кертеп, 10 елга якын армиядә булып кайтты. Сугышта берничә тапкыр яралана, кабат сугышка кереп, әти-әнисе янына Түрешкә кайта. Минем белүемчә, Заһит агай белемле, намуслы, кешеләргә ярдәмчел иде. Бухгалтериядә пенсиягә хәтле берөзлексез

эшләде. Кайчакларда авылда «таш баш» хуҗалар эшләгәндә, кыенлыклар килгәндә, бик борчыла иде. Заһит агайны да авылның иң хөрмәтле кешесе иде, дип әйтер идем. Мәрхүм инде. Заһит агай армиядән кайткач, авылны оештырган һәм сугыш чорында төрле җитәкче урыннарда эшләгән Ислам агайның эшчән, уңган Җүәйрә исемле кызын үз итеп, гаилә корды. Ике малай, бер кыз үстереп, югары белемле иттеләр. Ул балалар хәзер үзләре әти-бабай, әбиләр инде. Өчесе дә исән әле, шөкер. Җүәйрә апа төрле эшләрдә эшләде. Озак еллар авылның алма-яшелчә бакчасында хезмәт куйды.

Тагын бер гаилә – Исламов агайлар. Чыгышлары буенча – Иске Урәзмәттән. Исламов агайның Мизхәт исемле малае белән 7 сыйныфны бергә бетердек. Дус-тату укыдык. Үскәч, Иске Карамалыда йорт салып, гаилә корып, яхшы гына эшләп, пенсиягә чыкты. Икенче улы Фәүзел агай колхозда агроном-экономист булып, үз хезмәтен намус белән башкарып, төп йортка китеп барды. Төпчек улы Флүс хәзергә авылда яши, югары белемле, тәртипле, пенсиядә инде. Сөйләшергә уңай кеше.

Мин белгәндә, Түреш колхоз булып торганда ук, авылның чишмәсе янында, кыздырып, агач чана табаннары, ат арбаларына кирәк әйберләрне бөгеп ясыйлар иде. Монда башта Мирзашәех, Шәйгәрдән бабайлар, Марсның әтисе Сәлах агай, Хәниф агайның әтисе Мирхаҗиян агайлар эшләп, колхозның төп көчләре булып, арба-чанага интектермәделәр. Ә Хәниф агайның әтисе авыл халкын бәләкәй чана, хатын-кызларга көянтәләр ясап биреп куандыра иде. Авыл шулай ук үзенең ир-атлары белән булсын дип көн күрде. Күпләре инде бездән алда төп йортка күчте. Уйлыйм да, күп нәрсәләрне кабат барларга тотынам. Чөнки хәзерге яшь буын боларны белмәгән, күрмәгән ич. Иң аянычы – телисеңме-юкмы, туганлык җепләре өзелә. Милләтнең язмышы кыл өстендә. Татар кызларының 40%ы башка милләт кешесенә кияүгә чыга. Чит ил кешеләренә ияреп, бәхет эзләп китәләр. Татар яшьләре гаилә кормый, аракы эчә, наркоманга әйләнә. Дөнья үзгәрә. Син телисеңме-юкмы, илдә урыслашу бара. Тагын кабатлыйм: авылның киләчәгенә өмет юк. Хәлләр – ифрат начар, өстәге эреле-ваклы түрә бүген өчен яши, киләчәк өчен «мая» туплау ягын кайгырта. Моны һәркем күрә, белә. Тик аскы катлау халык берни дә эшли алмый.

ТАГЫН БЕР ИСТӘЛЕК

Хәбибулла абыйлар яныннан чыгып, чокыр аркылы, ничә сутый булгандыр, авылның яшелчә бакчасы бар иде. Анда төрле яшелчә үстерәләр иде. Бригадиры – Марсның әнисе Нәкыя апа, ул эшкә таләпчән иде. Миңа анда эшләргә туры килмәде. Рәттән генә тимерче алачыгы эшли иде. Тимерче булып Баянов агай (без аны шулай атап йөрттек, исемен хәтерләмим) эшләде. Ул язучы-фронтовик Нур Баянның энесе иде. Монда җирләнде. Тимер алачыгы яңадан зират янына күчте. Анда Баянов агай, Мирзагаян агай икесе бергә шактый еллар эшләде.

Авылдашым Өммеһани апа турында берничә сүз. Аларның төп йорты беренче мәктәп артында, без яшәгән җирдән ерак түгел иде. Апаның ире сугышка киткәнче безнең әти янында ярдәмче булып эшләде һәм сугыштан кайтмады. Апа алты бала белән калды. Олы улы Гайни сугышка китте. Калганнарын Өммеһани апа берүзе карап укытты, эшләтте. Сугыш чорында көлтәне аннан да оста һәм авыр итеп бәйләүче булмагандыр. Мин иптәш малайлар белән аның бәйләгән көлтәләрен күп ташыдым. Аларны арбага бер генә кеше атуы кыен иде. Шушы апа балаларына артык булып, районда картлар йортында яшәп үлде. Башта балалары төп йортны сатып акча эшләде. Өммеһани апаның бер улы, алтмыш яшен тутыргач, бакыйлыкка күчте. Шунысын анык беләм: ата-ана нигезен таркатучылар һәм ата-ананы карамаучылар мәңге рәхәт күрми. Трагик хәлләр...

И, язмыш!..

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

ШАГЫЙРЬНЕҢ ИЛҺАМЧЫСЫ

Фатих Кутлу

Төрекчәгә тәрҗемә итү уе белән Зәйтүнә Мәүлүдованың Тукай турындагы истәлекләрен укыганда, мин Зәйтүнәнең ихлас, саф мәхәббәтенә сокландым һәм күңелемдә аңа карата ихтирам хисләре уянды. Ихтыярсыздан, мәрхүмәнең каберенә барып, рухына дога кылу теләге туды. Ләкин, ни кызганыч, күпме сорашсам да, әлегә кадәр аның каберен белүче галим-голәмәне, әдип-әдибәне очратмадым...

«Казан утлары» журналының узган елгы апрель санында урын алган «Зәйтүнә-Тукай мәхәббәте дәвам итә» исемле мәкаләм шулай башланып киткән иде. Аннан соң бер елдан артык вакыт үтсә дә, Зәйтүнәнең каберен (дөресрәге, әүвәл зиратын) табу теләге җанда һаман сүрелмәде. Киресенчә, көчәя генә барды. Бу уй мине һич кенә дә тынычлыкта калдырмады.

Бер-ике аксакал язучы-галимебездән: «Зәйтүнәнең кабере Дәрвишләр бистәсендә булырга мөмкин», – дигән сүз ишеттем. Кайчан үлүе турында кызыксынгач, Зөфәр Рәмиев 1957 елны атады. Улы Атилла Расих 1996 елда, килене Зәкия ханым 1999 елда вафат булганга, Зәйтүнәнең кабере ташландык хәлдә түгелдер, дигән өмет туды. («Атилла абый әнисенең каберен бер генә каләмдәшенә дә күрсәтеп калдырмады микәнни? Әллә күрсәтеп тә мәгълүмат җуелганмы?» кебек сораулар һавада эленеп калды.)

Аллага тапшырып, Зәйтүнә Мәүлүдованың (Рәсүлеваның) үлем турындагы таныклыгын эзләргә ниятләп, Әхтәмов урамында урнашкан ЗАГС идарәсенә бардым. Анда миңа: «Дәрвишләр бистәсе Казанга буйсына, сез башта Меридиан урамындагы Үзәк ЗАГСка барыгыз, анда берәр мәгълүмат табылырга мөмкин», – диделәр. Икенче көнне шунда юнәлдем. Хезмәткәр – марҗа ханым иде. Рәсүлеваның Тукай белән бәйләнешен кыскача сөйләп бирдем, фоторәсемен күрсәттем. Сокланып карады. «Атасының исеме Хәйдәр, үзе 1957 елда вафат», – дидем. Ул миңа: «Дәрвишләр бистәсе хәзер генә Казанга буйсына, теге чорда алай булмаган», – дип җавап кайтарды һәм компьютерда нәрсәдер эзләргә кереште. Озак эзләде, тапмады. Гозерем Тукайга бәйле булгангамы, аның чын күңелдән булышасы килүе күренеп тора иде. «Сез көтеп торыгыз», – дип, беразга югалып алды. Көтәм, көтәм – юк. Түземлегем бетеп барганда, ниһаять, кулына журнал тоткан килеш пәйда булды: «Таптым! Ул Дәрвишләр бистәсендә түгел, Казанда үлгән». Аннары журналдагы мәгълүматны укырга кереште: «Хәйдәр кызы Зәйтүнә Рәсүлева. 08.06.1957. 62 яшь *(туган елы күрсәтелмәгән. –* **Ф.К.***)*. Молотов районы[1], Курск урамы. Имза: А.Рәсүлев». *(«А.» – ире Габделкадыйр (урысча – Абдулкадир) булганмы, улы Атилла Расихмы – әйтә алмыйм. –* **Ф.К.***)*

Бу көн 28 апрель иде. Ничек шатланганымны күрсәгез! Хезмәткәр ханыма кат-кат рәхмәтләр әйтеп: «Зәйтүнә мәрхүмәнең кайсы айда, нинди көндә үлгәне ачыкланды. Кайда, кайсы адрес буенча вафаты мәгълүм. Болар турында иң беренче миңа белү насыйп булды!» – дип куанычымны бүлештем. Ул: «Ләкин кайда җирләнүе хакында һичнинди хәбәр юк», – дип көрсенде. «Бу хакта кайсы оешмадан белешергә мөмкин?» – дип кызыксындым. «Казандагы Арча зиратына барыгыз, бәлки, аларда берәр мәгълүмат табылыр». Горький паркы янындагы каберстанда миңа: «1957 елда үлеп, аның монда күмелүе мөмкин түгел. Бу – нәсара зираты бит. Сез Яңа бистәгә барыгыз», – диделәр.

Әйе, Казанда бакыйлыкка күчкәч,

[1] Хәзерге Киров районының бер өлеше.

«Тукайның илһамчысы Зәйтүнә Мәүлүдова». Ильяс Айдаров эше

аның кабере, һичшиксез, Иске Татар зиратында булырга тиеш иде. 2 май көнне шунда бардым. Зират идарәсендә мине: «Мәрхүмә җирләнгән урынны табу мөмкин түгел, – дигән хәбәр каршы алды. – Сезгә зират буйлап эзләргә генә кала». Мин: «Ул елгылар чама белән кайсы тирәдә җирләнергә мөмкин?» – дип төпчендем. «Тукайга җитәр-җитмәс сул якка сукмак китә, шуннан башлый аласыз». Ул өйрәткәнчә барганда, юл кырыенда гына, Алланың рәхмәте, Атилла Расих белән хатыны Зәкия Рәсүлеваның каберенә тап булдым. Зәйтүнә мәрхүмә дә шушы тирәдәдер дип фаразлап, ярты сәгатьтән артык эзләп йөрдем. Ләкин тапмадым. Әлегә...

Эзләнүләремне туктатырга уемда да юк. Күңелемне тынычландырырлык табышка юлыкмасам да, һичьюгы, Зәйтүнәнең алтынчы айда үлеп, вафатына алтмыш ел туласы көннәрдә шушы мәгълүматка ия булуыма һәм ошбу хәбәрне халыкка җиткерер өчен язмамны «Безнең мирас»ның алтынчы санына өлгертә алуыма чиксез сөенәм. ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

ГУЛАГ тоткыны Ибраһим Салахов

Госман Гомәр

Таякка таянып йөргәч, аны кайберәүләр, сугыш инвалиды, дип уйлады...

Түгел шул! Ир-егетләр фашизмга каршы кан койганда, Ибраһим Салахов (фамилиясен үзе «а» белән язды) Сталин лагерьларында иза чикте.

Казакъстанның Күкчәтау каласында гади эшче гаиләсендә туып-үскән Ибраһим Салахов 1928 елда, 17 яшендә Казанга килеп, педагогия техникумына укырга керә. Аны уңышлы тәмамлап, республиканың яшьләр матбугатында эшли башлый. Бер-бер артлы шигырь һәм хикәяләрен бастыра. Татарстан китап нәшрияты яшь авторның тәүге китабын чыгара. Гаскәри хезмәттән соң егет 1937 елның язында Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә, әмма кинәт сырхауланып китә. Өметле авторның хәленә кереп, Татарстан язучылар берлеге Ибраһимны Ялтадагы шифаханәләрнең берсенә дәваланырга җибәрә. Шунда ул биредә дәваланучы Галимҗан Ибраһимов белән күрешә. Язучылар берлегенең шул чактагы рәисе Кави Нәҗми үтенече буенча, Ибраһим Салахов әдипнең кульязмасын китап нәшриятына алып кайтырга тиеш була. Шушы гамәлне сәбәп итеп, халык дошманы белән яшертен контрреволюцион элемтә тотуда гаепләп, институтның өченче курс студентын 1937 елның 25 октябрендә кулга алалар. Сырхаудан терелеп җитмәсә дә, Мәскәүдән килгән махсус төркем 1938 елның 12 маенда И.Салаховны ун елга ирегеннән мәхрүм итә, тагы биш елга аның гражданлык хокукларын чикли.

Әдип Колыманың алтын приискаларында тәмуг газаплары кичерә. Сәламәтлеге тагын да какшау нәтиҗәсендә авариягә эләгә, болай да өшегән бармаклы аякларын имгәтә, күзләренә дә зыян килә. Ибраһим Салахов 1937 елның 25 октябреннән 1947 елның 25 октябренә кадәр ГУЛАГ тоткыны була.

Ул, гаиләсе белән Күкчәтаудан җиде чакрымдагы Кызыл Яр авылына урнашып, ашханәдә буфетчы булып эшли башлый. Бары тик Сталин үлеменнән соң гына, хокуксыз җан иркен сулыш ала.

1956 елның 25 апрелендә И.Салаховны гаепләү эше яңадан карала һәм ул аклана.

Калганы инде минем күз алдындагы хәлләр. ГУЛАГ тоткыннарыннан Татарстан Язучылар берлегенә беренчеләрдән булып Ибраһим Салахов аяк басты. Анысын яхшы хәтерлим, мин ул чакта Язучылар берлеге китапханәсен тәртипкә сала идем. Үзе белән шул мәлдәрәк таныштык. Аннары Берлектә берәм-берәм элеккеге тоткын студентлар





Мәҗит Рәфиков, Аяз Гыйләҗев, Гурий Тавлин, Сөббух Рәфиков, ниһаять, Хәсән Туфаннар күренде. Китапка килгәндә, Татарстан китап нәшрияты Ибраһим Салаховның, нәкъ егерме ел узгач, «Дала дулкыннары» дигән дүртенче китабын бастырып чыгарды.

Үзем журналист булып «Социалистик Татарстан» газетасында эшли башлагач, Ибраһим ага Салахов белән арабыз тагын да якынайды. Аны хөрмәтләп каршы алабыз, чәй белән сыйлыйбыз, ГУЛАГ хәлләре турында сәгатьләр буе әңгәмә корабыз. Җылы мөнәсәбәтебез өчен ул кат-кат рәхмәтләрен җиткерә, «Колыма хикәяләре»н язарга җыенуын әйтә. Бусы – редакциядәге хәлләр.

Башта бит Көкчәтау белән Казан арасында хатлар йөри. Редакциягә дигән хатларын турыдан-туры минем исемгә җибәрә. Хатлар йә гарәп, йә латин имласында, сирәк кенә кириллицада була. Соңгы имланы ул өнәп бетермәде. Хатларның берничәсе архивымда да сакланып калган. Монда күрсәтелгән гарәп имласындагысы 1990 елның 17 маенда язылган, кириллицадагысы исә – 1991 елның 9 гыйнварында. Алардан милләтпәрвәр, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе, Казакъстан Республикасының шәрәфле гражданины, җөмһүриятнең иң зур бүләге – «Парасат» («Алтын дуслык») ордены кавалеры Ибраһим Низам улы Салаховның ошбу хатларны юллаганда нинди олы эшләр белән мәшгуль булганлыгын күрергә мөмкин. Әңгәмәбез вакытында да ул милли проблемалар турында борчылып, хисләнеп сөйли иде. Фотохәбәрчебез Мидхәт Шакирҗанов әнә шул мизгелне татып алган да инде.

Туксанынчы елдагы очрашуыбызда Ибраһим ага 80 яшьлек юбилеена килүемне үтенде. «Госман энем, синсез табынымның бер чите китек булачак, килми калма!» – дип кисәтте. Редакция бит ул – бүлек мөдире, баш мөхәррир бар. Вакыты килеп җиткәндә генә: «Минзәләгә бар, анда мәктәпнең астын-өскә китереп яталар», – дип, кулыма юллама тоттырдылар. Бер төркем язучы-галимнәр Көкчәтауга минсез генә китеп барган. 85 еллыгына да бару насыйп булмады – дөньясы болганып бетте. Чакырган иде югыйсә. Ә 1998 елның ямьле җәй аенда олуг әдибебез көтмәгәндә бакыйлыкка күчте – урыны оҗмахта булсын.

Менә фотосы истәлеккә калды. ■

«АЮЧЫЛАР, БАГУЧЫЛАР, ЗУР БАРАБАН КАГУЧЫЛАР...»

Эльмира Каюмова

Элек мишәр татарлары яшәгән төбәкләрдә ***«аю биетү»*** *дигән тамаша таралган булган. XIX гасыр урталарында Сембер губернасы (хәзерге* ***Ульяновск өлкәсе Иске Кулат-кы районы****) авылларында булган күренешне болай тасвир-лыйлар: «Аючылар авыл халкын җыяр өчен барабан суга, быргы кычкыртып йөри торган булганнар. Халык җыелып беткәч, аючылар аюларын думбыра сугып төрле такмаклар әйтеп биетәләр. Курайчылар курай уйнап, думбырачылар думбыра сугып, яшь киленнәрдән көлеп, «чәнчеп», такмак әйтә торган булганнар. Аю биетеп йөрүчеләр дүрт-биш кеше булып, араларында курайчы, думбырачы, җырчы, такмакчы, көлдерүчеләре була»*[1].

[1] Макаров Г.М. Домбра татар Среднего Повол-жья // Страницы истории татар-ской музыкальной культуры. Казань, 1991. Б.12.

Фоторәсемнәрдә: «Мишәр» ансамбле. Чувашия Республикасы, Урмай авылы

Р.Якупов фотолары

Әлеге истәлекләрдә телгә алынган «думбыра»ны кыллы яисә бәрмә уен коралы итеп аңлатырга мөмкин, дип яза Г.Макаров. Минем уйлавымча, икенче мәгънәсе чынбарлыкка күбрәк туры килә. Әлеге фикерне куәтләп, берничә дәлил китерәм.

Төрки телләрдә ***«дөнгер»***, ***«дөмбер»***, ***«думбырый»***, ***«думбыра»*** – бубенның борынгы атамалары. Татар теленең кайбер диалектларында бу төшенчәләрне шулай ук барабанга карата да кулланганнар. Бәрмә музыка коралы итеп расларга уйнау рәвешен «думбыра чиртү» түгел, ә «думбыра сугу» дип әйтү дә нигез бирә.

Халык аючылар турында җырлар һәм бәетләр чыгарган. Аючылар төркемнәрендә яшь егетләр дә йөргән. Иске Аллагол авылында (элек Пенза губернасында, хәзер – Мордовия Республикасына керә) туган Хафиз Ишмәмәтовтан язып алынган әсәрдә мондый сүзләр бар:

Аючылар, багучылар,
Зур барабан кагучылар;
Кызлар багып йөрер өчен
Юк сылтаулар табучылар[2].

Мордовия мишәрләре арасында таралыш тапкан авыз иҗаты үрнәкләрендә барабан һәм барабанчылар еш телгә алына:

Йөгереп кердем магазинга,
Кызыл косынка багырга.
Әтием-әнием риза кылган
Миңа аючыга барырга.

Аючылар, барабанчылар,
Бармак очтан йөручеләр.
Алты авылдан алтмыш хатын
Килде мине тыючылар[3].

Билгеле булганча, Русиядә аю белән бәйле һөнәрчелек ерак заманнардан ук килә. Ул патшаларның яраткан күңел ачу чарасы да булган. Русларның аю кәмитендә барабанчылар да катнашкан[4]. Хайваннарны төрле хәрәкәтләр ясарга өйрәткәндә бубенга сукканнар[5].

Рус вәкилләре белән бергә, бу шөгыльдә аеруча сергач мишәрләре дан тоткан. Хәтта аю сыны Сергач шәһәренең гербында урын алган, ә аючыларга (нинди төбәктән чыгуына карамастан) гомумән ***«сергач»*** исемен такканнар.

Шулай итеп, аю биеткәндә бәрмә уен кораллары актив файдаланылган. Сүз уңаеннан, барабанның себер татарлары (аларда ул ***«тип»*** дип атала), Мари Иле татарлары традицияләренә хас булуы турында әйтеп китәргә кирәк. Бубенны исә әстерхан татарлары ***«кабал»***, ***«кавал»*** диләр. ■

[2] Сайдашева З., Ярми Х. Татарско-мишарские песни. – М., 1979. № 2. – Б. 10.
[3] Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. – Казан, 1988. № 392. – Б. 277.
[4] Некрылова А.Ф. Медвежья комедия. Некоторые проблемы и аспекты изучения // Фольклор и этнография: у этнографических истоков фольклорных сюжетов и образов. – Л., 1984. – Б.191.
[5] Солодухо Я. Медвежья академия // Советский цирк. 1959. №3.

Безнең мирас №6 июнь 2017

КАДЕРЛЕ ЯДКЯР

Гөлгенә Кәримова

Зәйнәп Фәрхетдинова белән икәүләшеп архив барлыйбыз. Алдыбызда – җырчының утыз еллык иҗат чорында тупланган рухи байлыгы: матбугат чараларында дөнья күргән язмалар, җыр альбомнары, фотосурәтләр, тамашачы хатлары...

Менә ул арадан бер калын папка чыгарып, бавын сүтте. Йөзеннән, кул хәрәкәтләреннән күренгәнчә, бу папкада иң кадерле ядкярләр сакланырга тиеш. Ноталар икән. Композиторларның үз кулы белән язылган, аларның җан җылысы, күңел яктылыгы сеңгән ноталар – төп нөсхәләр...

– Бусы – «Зәңгәр кыңгыраулар»ым, – диде Зәйнәп, кәгазь битен сыйпап, – көзләр сарылыгы түгел, алтын төс күчкән аларга...

Шулай хатирәләргә биреләдек.

Казан дәүләт мәдәният институтында укыганда ук җыр сөючеләр күңелендә үз урынын тапкан Зәйнәп Фәрхетдинованың, укуын тәмамлагач та, баштанаяк җыр дөньясына кереп китәсенә беркем шикләнми. Ләкин тормыш һәр мәсьәләгә төзәтмә кертергә ашыга, хыялларны тезгенли төшә. Монда да шул: яшь гаилә алдында торак проблемасы килеп баса. Казан мех фабрикасы җитәкчелеге «Иделкәем» ансамбле солисткасын югалтырга теләми, шуңа күрә бу парга аерым бүлмә бирергә карар кыла. Һәрнәрсәнең үз тәртибе: бүлмәгә керәләр икән, җырчылар шул оешмага ук эшкә дә урнашырга тиешләр. Консерваториядә белем эстәүче Зөфәр Билалов укудан буш вакытында ишегалды себерергә алына. Зәйнәп исә тулы ставкага тулай торак тәрбиячесе булып эшкә керә. Озакламый тулай торакта тормыш тамырдан үзгәрә, кайный башлый, яшь кадр нинди генә чаралар уйлап тапмый! Фабрика җитәкчелеге мондый табыштан гаять канәгать була, билгеле. Зәйнәп исә киресенчә: «Минем урын түгел бит бу, минем урыным – сәхнә бит», – дип өзгәләнә. Дөрес, ул төрле чараларга, бәйрәмнәргә даими чакырыла, аларда катнаша, репертуарын баета. Ләкин моңлы сандугач өчен болар гына җитми шул! Берсендә радиодан яраткан җырын – «Зәңгәр кыңгыраулар»ны ишетеп елап ук җибәрә. Яшь аралаш җырлап утырган Зәйнәпне күргәч, укудан яңа кайтып кергән Зөфәрнең йөрәге ничек түзсен?! Ул аны, җитәкләп диярлек, Татар дәүләт филармониясенә алып бара.

– Бәхетебезгә, анда солистка кирәк булып чыкты, – дип искә ала Зәйнәп. – Филармония кадәр филармониягә теләсә кемне алмыйлар. Илһам Шакиров җитәкчелегендәге комиссия җырчыларны җиз иләк аша үткәрә...

Чорыбызның тере легендасы яшь артистны халык җырларын җырлатып сыный. Бу хакта соңрак Зәйнәп болай дип искә төшерәчәк: «Илһам абый бормалы-бормалы озын көйләрне сайлап алып башкара да, миңа кабатларга куша. Бар дөньямны онытып мин дә әлеге дулкынга кушылам». Нәтиҗәдә, конкурс буласы көнне Зәйнәп филармониягә йөгереп керсә, урамга инде очып-канатланып ук чыга. Илһам абыйсы аңа: «Сеңелем, җырла, син җырларга тиеш», – дип фатиха бирә.

Шуннан соң бер ай да узмый, радиоэфирдан, сәхнәләрдән Зәйнәп Фәрхетдинованың җанны әсир итәрлек тавышы агыла башлый:

Җирдә, күктә – кая барсам, шунда
Уем синең белән очраша.
Бөтен хыялларым чынга аша,
Зәңгәр кыңгыраулар чыңласа...

Әлеге уңайдан 1992 елда күренекле шагыйрь Харрас Әюп «Та-

тарстан яшьләре» газетасында: «Мин бу яшь җырчының тавышында күкнең чыңлаганын гына түгел, бөтен бер милләтнең язмышын, аның моң-зарын, кайгы-сагышларын, ачынуларын, мәхәббәтен, өметен-ышанычын ишетәм сыман. Күкрәктән, йөрәк түреннән, бәгырьдән сыгылып чыккан моңлы тавыш, әби-бабаларыбызның киләчәк буыннарга барып җитәргә тиешле җан авазы... чишмә суыдай саф, кыңгырау чәчәкләредәй назлы», – дип язып чыга.

Әйе, бәгырь түреннән агылып, юк, ургылып чыккан моң кемнең генә йөрәген кузгатмады да, кемнең генә күңелен яуламады икән?! Нәкъ менә шушы җыр Зәйнәбебезне миллион кеше өчен үз-якын кеше итте, аны бөтен татар дөньясына танытты.

– Бу җырны миңа кадәр Венера Ганиева җырлады. Үзем аны беренче тапкыр Камал театры артисты Зөлфирә Зарипова башкаруында ишеттем һәм шунда ук гашыйк булдым. Ул чорда бер җырны бер генә җырчы башкара дигән сүз юк иде. «Зәңгәр кыңгыраулар»ны да һәркем үзенчә яхшы, матур итеп башкарды», – дип хәтер яңарта Зәйнәп. Үзенең «Зәңгәр кыңгыраулар»ын Зәйнәп Фәрхетдинова башкаруында ишеткән композитор Фуат Әбубәкеров түзми, концерттан соң сәхнә артына керә һәм... җырчыга әлеге җырның ноталары язылган автограф бүләк итә...

Аннан соң башкарылган әсәрләрнең гомуми саны дүрт йөздән артып китсә дә, шагыйрь әйткәнчә, «беренчеләр барыбер беренче шул»: «Зәңгәр кыңгыраулар» Зәйнәп Фәрхетдинова күңелендә әлегәчә аерым урын тота. Алай гына да түгел, татар халкы күңелендә дә үзгә исәптә ул җыр. Шулай булмаса, быелгы TMTV премиясен тапшыру тантанасында «Зәңгәр кыңгыраулар» «Халык мәхәббәте» номинациясендә җиңү яулар идемени?!

Зәйнәп Фәрхетдинова озын, сузып җырлана торган катлаулы җырларны аеруча якын итә: Сара Садыйкованың «Сусау», Рәис Нәгыймовның «Авыл» кебек әсәрләре – шундыйлардан. Милләтебезнең мәңге сүнмәс йолдызлары булган Фәридә Кудашева, Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова кебек могтәбәрләребездән соң эстафетаны үз кулына алып, инде өч дистәгә якын ел бу иҗади гаилә – Зәйнәп Фәрхетдинова белән Зөфәр Билалов – халкыбызның иң бөек әсәрләрен халыкның үзенә кайтара: «Гөлҗамал», «Илкәем», «Озата барма», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү», «Әллүки».

Зәйнәп Фәрхетдинова үзе, Габдулла Тукай фикеренә кушылып, халык җырларын, моңыбызны милләтебезнең авыр язмышы, катлаулы үткәне белән чагыштыра: «Аларда, безнең бөклегебез белән беррәттән, халкыбызның ничәмә гасырлык сыкранулары, әрнүләре», – ди.

Сәхнәгә өч дистә елдан артык хезмәт итү дәверендә Зәйнәбебез үзе дә халкыбызның олы бер байлыгына, мирасына әверелде. Җырчының кабатланмас тавышына, илаһи моңына, үлмәс җырларына гашыйк булып, аны үзенә үрнәк итеп, Җыр күгендә күпме яңа йолдыз кабынды һәм бүген дә кабына тора. ■

Гамьле сәфәр

19 майда Мамадыш районының Көек-Ерыкса авылында бер төркем әдәбият-сәнгать әһелләре – Татарстанның халык язучылары Рабит Батулла, Марсель Галиев, Татарстанның халык шагыйре Гәрәй Рәхим, Татарстанның халык артисты Мингол Галиев, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Алмаз Хәмзин, «Җыен» хәйрия фонды директоры Фуат Рафиков, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррир урынбасары Марат Закир һәм ветераннар арасында җиңел атлетика, чаңгы буенча 29 мәртәбә дөнья чемпионы, Казанның мактаулы гражданины Әхмәт Сиражиев, район хакимияте вәкилләре катнашында авыл халкы белән очрашулар булды.

Көек-Ерыкса урта мәктәбендә шигырь, җыр-моң вә фәһемле сүзләр белән үрелеп барган очрашуда укучылар һәм укытучылар «Җыен» фондының эшчәнлеге белән таныштды. Бу авылда туып-үскән, Татарстанның җиңел атлетика федерациясе вице-президенты Габделхак Фәләхиев белән фондның директоры Фуат Рафиков «Шәхесләребез» дигән баш астында нәшер ителгән китапларны бүләк итте. Аннары Алмаз Хәмзин белән Мингол Галиев укучыларга җыр буенча мастер-класс үткәрде. Шушы авылда туып-үскән, бу мәктәптә озак еллар балалар укыткан ветеран мөгаллимнәр, каләм әһелләре Рәим Гобәев белән Рәсимә Галиеваның да биредә булуы ямь өстенә ямь өстәде.

Җомга намазыннан соң авыл халкы белән очрашу мәчеттә дәвам итте. Рабит Батулла үзенең «Җыен» фонды тарафыннан чыгарылган Коръән тәфсирен һәм Коръәннең Казан басмасын имамхатыйпка тапшырды. Мингол Галиев мөнәҗәтләр башкарды.

Кичкә таба кунаклар Мамадыш шәһәренә юл тоттылар. Биредә алар районның легендар шәхесе, сугыш һәм хезмәт ветераны Вахит Галиев белән очраштылар. 91 яшьлек аксакалга үзе дә аксакал Рабит Батулла изге китапны бүләк итеп бирде.

«Җыен» фонды оештырган әлеге гамьле сәфәрдән һәммәсе дә канәгать калды. Мамадышка барганда сәфәрдәшләр Илһам Шакиров җырларын тыңлап барса, башкалабызга кайтканда исә Әлфия Афзалова җырларын тыңлап хозурланды.

Морад Дусай

Ләйсән Зиннурова фотосы. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин



ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ҺӘМ КПСС – Совет хакимияте елларында татар әдипләренең күпчелеге Коммунистлар фиркасе сафында тора, чөнки шунсыз иҗади үсү һәм карьера ясау мөмкин түгел иде. XX гасыр азагында илдә иҗтимагый үзгәрешләр башлангач, күп кенә язучыларыбыз КПСС сафларыннан чыгаруны сорап, башлангыч партия оешмасына мөрәҗәгать иткән (Марсель Галиев, Мансур Вәлиев, Ризван Хәмид, Нәбирә Гыйматдинова, Әхәт Мушинский, Мәгъсүм Насыйбуллин, Геннадий Паушкин, Рафис Корбанов, Флүс Латыйфи, Диас Вәлиев, Лев Кожевников, Марс Шабаев, Рәдиф Гатауллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Кояш Тимбикова, Мәдинә Маликова). Язучыларның партия оешмасы аларның гаризаларын канәгатьләндергән. («Казан утлары» журналы, 1991, 3 сан.)

Бу үзе бер кызыклы тема һәм, ихтимал, киләчәктә без бу вакыйга турында тәүбәле хатирәләр дә укырбыз әле.

ТАТАРЛАРНЫҢ КОСМОГОНИК КАРАШЛАРЫ – Җирнең ничек яралуы турында татарда мондый бер легенда бар. «Хак сөбхан кәмал кодрәте берлән бер күл яратты. Ул үрдәккә боерды: «Ошбу күлнең төбендәге комны йигел», – дип. Ул үрдәк барчасын йийде. Андан соң Хак Тәгалә дәхи боерды. «Карныңдагы комны дөньяга чачгыл», – диеп. Алла әмеренчә сачды...» Җир шуннан хасил булган, имеш. (Легенданың бу варианты 1843 елда Казан шәһәрендә Шәрифулла бине Җармөхәммәт тарафыннан язылган кульъязма китапка кергән. Кульъязманы 1980 елда Мамадыш районы Сөн авылында Нәҗип Исмәгыйлев (Нәккаш) тапкан.)

Авызына шар капкан үрдәк сурәте археологик табылдыкларда да очрый, шуңа күрә җир ералу турындагы әлеге карашлар татарда шактый таралган булган, дип әйтергә нигез бар.

Борынгы әлгәрләребез җирне яссы итеп күзаллаган. Ул гаять зур үгезнең мөгезендә тора, имеш. Ә бу үгез иксезчиксез океанда йөзеп йөрүче зур бер балыкның мыегына беркетелгән.

Җирне җиһанның (галәмнең) үзәге дип санаганнар. Күктәге Кояш, Ай, йолдызлар җанлы нәрсә, дип фараз кылынган. Җирдәге барлык җанлы вә җансыз мәхлукат, шул исәптән кешеләр дә, күк җисемнәренә турыдан-туры бәйләнгән, дип исәпләнгән, ягъни бу карашлар Борынгы Шәрык мифологиясенә нигезләнә, дияргә мөмкин. Шулай да

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

йолдызларга карап юрау (астрология) һәм язмышны белү «гыйлеме» бездә җентекләп эшләнмәгән, Ислам карарлашкач исә астрологиягә үсү мөмкинлекләре бик нык чикләнгән.

Тагын кара: ***Болгар илендә астрономия.***

ТӘВАФ ИТҮ, ТӘВАФ КЫЛУ – Әйләнеп йөрү (мәс., хаҗ вакытында Кәгъбә тирәсендә 7 тапкыр әйләнү). Туваф кылу язылышы да очрый. Хаҗ вакытында изге зиратларны да тәваф кылалар.

Тәваф кылуның төп кагыйдәләре 632 елда Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) «хушлашу хаҗы» вакытында бәян ителгән. Тәваф кылу өчен хаҗи әл-Мәсҗид әл-Харамга «Тынычлык капкасы» («Баб әс-сәлам») аша уң аяктан керергә, Кәгъбәнең төньяк-көнчыгыш почмагындагы «Кара таш» каршына килеп, аны үбәргә (тәкбил) яки аңа кулы белән кагылып кулын иреннәренә тидерергә (истилам) тиеш (әгәр халык күп булып, таш янына килергә мөмкин булмаса, ташка кулны сузып, аннары аны үбәргә мөмкин). «Кара Таш»ка баш игәннән соң, Кәгъбә тирәли җиде тапкыр әйләнәләр. Кәгъбә тирәсендә әйләнгәндә тәваф кагыйдәләрен белгән ихтыяри сәед җитәкчелек итә. Диварга якын гына, сәгать йөрешенә каршы барырга кирәк *(кайбер чыганакларда, мәсәлән рус телендәге «Ислам» энциклопедиясендә – 217 биттә – әйләнү юнәлеше нәкъ киресенчә күрсәтелгән, ләкин Насыйр-и Хосрәү Кәгъбә тирәли әйләнгәндә сул ягың һәрвакыт Кәгъбә тарафында булырга тиеш дип яза. –* **А.Т.***)*. Баштагы өч әйләнәдә кызу адымнар белән атлыйлар (рамал), калган әйләнүләрдә гадәттәгечә атлап барыла. Кәгъбә тирәли җиде тапкыр әйләнгәч, керү урыны янына килеп, диварга гәүдәң белән сыенырга, уң кулыңны керү урынына таба сузып, Аллаһыга, Пәйгамбәргә рәхмәт әйтергә һәм гөнаһларыңны ярлыкауны сорарга кирәк. Ахырда ике рәкәгатьле намаз укыла, беренчесе вакытында «Сүрәи әл-Кяфирин»не (109), икенчесе вакытында «Сүрәи әл-Ихлас»ны (112) укыйлар.

Кече хаҗ (гомрә) кылганда тәваф бер тапкыр, ә тулы хаҗ вакытында ике тапкыр – Мәккәгә кергәндә (тәваф әт-тәхийә) һәм хаҗ йоласын тәмам иткәндә (тәваф әл-вәдаг) кылына. Хаҗга беренче тапкыр килгән кешенең тәвафы тәваф-и кодум, ягъни «кавышу (ирешү) тәвафы» дип атала.

Мөхәммәд Пәйгамбәрнең хушлашу хаҗы вакытында иң ахырда золхиҗҗәнең 14 нче көнендә төнлә Бәйтулланы тәваф итүен дә саубуллашу тәвафы диләр (Сөнгатулла Бикбулат). Шул ук көнне ул Мәдинәгә кайтып киткән.

Чыганакларда тәваф әл-ифадә төшенчәсе очрый, аңа хаҗ вакытында Минәдән кайткач хаҗиларның Кәгъбә тирәли әйләнүе дип гомуми аңлатма бирелә. Монда ифадә сүзе файда мәгънәсендә килә булса кирәк.

Хатын-кызларга тәвафны ирләрдән аерым кылырга киңәш ителсә дә, бу шарт үтәлеп бетми. Аннары «айлык»ларыннан соң пакьләнеп җитмичә торып, хатын-кызга тәваф кылырга рөхсәт ителми.

Татарстанның мөстәкыйльлеге өчен көрәшү көннәрендә (XX гасырның 90 нчы еллары) митингка җыелган халыкның Казанда элекке КПСС Өлкә комитеты бинасын тәваф кылганын хәтерлибез. Ислам принциплары күзлегеннән караганда, мондый гамәл акланмый, чөнки бу бәдбәхет бина изге түгел (яңа булса да, ун елдан соң сүтеп үк ташланды).

Гомумән, изге урыннарда тәваф кылуның бер Исламга гына хас түгеллеген әйтергә кирәк. Мондый йола христиан дөньясында да билгеле (христианнар кайчагында теге яки бу изге урын тирәли артка таба чигенә-чигенә әйләнеп йөриләр), борынгы гыйбранилар да Иисус Навин җитәкчелегендә Иерихон шәһәре тирәсен әйләнеп чыккач, шәһәр диварлары җимерелеп төшкән, имеш. Менә шушында КПССның Татарстан Өлкә комитеты бинасын җимертү факты искә килеп төшә... ■

КУКМАРАНЫҢ АТАКЛЫ БАЙЛАРЫ

Миндә бер самавыр бар. Тарихи, истәлекле самавыр. Кукмараның атаклы байлары – бертуган Комаровлар эшләткән аны. Биш-алты мөһер сугылган әлеге җиз самавырга «Бр. Комаровъ» дип тә язылган. Дөрес, «Бр. Комаровъ» дигән сүзне дә, мөһер «эзләрен» дә хәзер инде бик укып булмый: еллар үз эшен эшләгән – язулар җуелган, кайчандыр ялтырап торган самавыр кара-коңгырт яшелгә әйләнгән. Җитмәсә, әүвәлге кыяфәтенә кайтарам, дип, мин дә зур ялгышлык эшләп ташладым: ком белән ышкып, булган язуларны танып булмаслык хәлгә җиткердем...

Сүземне самавырдан башлавым тикмәгә түгел. Менә шул самавырдагы «Бр. Комаровъ» язуы, мөһер эзләре, нигәдер, нык тәэсир итте миңа. Бертуган Комаровлар, аннары Кукмараның башка фабрикант-купецлары белән кызыксына башладым. Хатыным Фидания Кукмара районыннан булганлыктан, юлым

бу якка гел төшеп тора. Яшь чакта поезд белән кайтып-китеп йөрдек, «Бертуган Комаровлар тукталышы»нда да күп тукталдык. Шул тукталыштан ерак түгел генә «Киез итек фабрикасы» (хәзер ул «Кукмара киез итек, киез комбинаты» дип йөртелә) барлыгын да белә идем. Комбинатның бүгенге генераль директоры Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшин белән бертуган Комаровлар турында, комбинатның үткәне, бүгенгесе, киләчәге хакында берничә мәртәбә гәпләшкәнебез булды. Соңгы күрешүебездә Шамил Михәйдәр улы даны бөтен дөньяга таралган комбинатның музеен булдыру нияте белән янып йөрүен әйтте.

Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшин

«Кукмара киез итек, киез комбинаты»ның генераль директоры Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшин белән белән булган әңгәмәне журналыбызның алдагы саннарыннан укый аласыз. Хәзер исә XIX гасыр башында исемнәре киң танылган Кукмара байлары – фабрикантлар Е.А. һәм А.Е.Лебедевлар, бертуган Войдиновлар, Комаровлар, Родигиннар, Вавиловлар, купец Габдулла Үтәмешев турында, 2008 елда Ш.М.Әхмәтшиннең турыдан-туры ярдәме белән дөнья күргән «Кукморский край» дигән китапка нигезләнеп, кыскача мәгълүмати язма тәкъдим итәбез.

Ләбиб Лерон

АТАЛЫ-УЛЛЫ ЛЕБЕДЕВЛАР

XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башларында Кукмара төбәгендә, бакыр кою заводыннан тыш, поташ (калий карбонатын элек шулай атап йөрткәннәр, борынгы римлылар аны кер юганда кулланганнар, поташны күпмедер дәрәҗәдә сода дип тә әйтергә мөмкин) заводлары да булган. Аларның хуҗасы – отставкадагы секунд-майор Евграф Алексеевич Лебедев. Соңыннан Гурьевка һәм Лубяндагы әлеге заводлар аның улы Александрга мирас булып калган. Лубяндагы завод таш янкормалы агач корпуста урнашкан була. Анда ике мастер һәм 60 эшче хезмәт куйган. Мастерның хезмәт хакы атнасына 8 сум, ә эшченеке исә 4 сум булган. Эш вакыты 10 сәгатькә сузылган. Атна саен исәп-хисап ясалган: управляющий хезмәт хакын һәр эшченең кулына үзе тоттырган.

Поташ (сода) ясау җайланмасы



Поташны әзерләү өчен көлдән файдаланганнар. Моның өчен якын-тирәдәге авылларда яшәүчеләрдән көлне потына 1 тиен түләп җыйганнар. Завод елына 500 пот (сигез тонна), кайвакыт тагы да күбрәк сода әзерләгән.

Лебедевның поташ (сода) заводы Казан губернасыннан читтә дә билгеле булган. Товарны гадәттә Мәкәрҗә ярминкәсендә сатып алганнар. Сода Казандагы сабын һәм пыяла ясый торган заводларда да киң кулланыш алган. Аны еш кына калийлы ашлама итеп кулланганнар. Завод җитештергән бер өлеш сода бертуган Комаровларның Кумарадагы фабрикасына да даими җибәрелеп торган.

Е.А.Лебедевның улы Александр – 1883-1887 елларда Казан шәһәре башлыгы буларак билгеле шәхес. Александр Евграфович Лебедев – пар белән эшли торган агач эшкәртү заводына беренчеләрдән булып нигез салучы. 1872 елда Лубянда ачылган заводта елга – 75 көн, тәүлегенә 23 сәгать эшләгәннәр. Эшчеләрнең сәламәтлеген махсус табиб белән фельдшер даими тикшереп торган. А.Е.Лебедев үз хисабына 50 кешегә исәпләнгән мәктәп тоткан.

1910 елда заводның агач корылмасын ташка алыштырып төзегәннәр.

Шулай да Кукмара төбәгендәге поташ (сода) заводына нигез салучы булып беренче гильдия купец Габдулла Үтәмешев санала – Ул 1792 елда Күкшел авылында шундый тәүге заводны хутка җибәрә.

БЕРТУГАН ВОЙДИНОВЛАР



А.П.Войдинов гаиләсе белән

1896 елгы мәгълүматлар буенча, Кукмарада берничә киез итек әзерләүче остаханә булган. Шундый остаханәләрнең берсе белән запастагы писарь Алексей Петрович Войдинов җитәкчелек иткән. Аның остаханәсендә 19 эшче елның 180 көнендә 9ар сәгать хезмәт куйган. Һәр эшченең хезмәт хакы – 900 сум.

Кул хезмәтен кулланып эшләүче берләшмәгә исә Егор Петрович Войдинов хуҗа булган. Алдарак телгә алынган 1896 елда Е.П.Войдиновның 16 эшчесе 600 сумлык хезмәт хакына 5000 сумлык киез ката әзерләгән. Берләшмә елына 250 көн (10ар сәгать) эшләгән.

Шул елларда Кукмарада Алабуга купецы Василий Макарович Вавиловның да киез итек әзерли торган берләшмәсе булган. Аның техник җиһазының алты ат егәрле двигателе керосин белән эшләгән. Шул ук 1896 елда В.М.Вавилов берләшмәсенең эш күрсәткече, башкаларныкы белән чагыштырганда, иң югары булган: җитештерелгән товар 90 мең сум белән бәяләнгән. Бу – «Бертуган Николай һәм Сергей Комаровларның Сәүдә йорты»на караганда өч мәртәбә күбрәк дигән сүз. Бертуган Комаровларның киез итек белән кәлүш җитештерүче берләшмәсе 1895 елда 32500 сумлык 10800 пар аяк киеме әзерләгән. Сигез ат егәрле пар машинасы, янә бер пар казаны булган берләшмә айга 285 көн эшләгән, эш вакыты көнгә 12 сәгатькә җиткән.

Кукмарадан тыш, киез итек басучы остаханә Состамак авылында

да булган. Хуҗасы Хөсәен Исмәгыйлев саналган әлеге берләшмә елына 270 көн эшләп, 6000 мең сумлык итек әзерләгән, 10 кеше көн саен 12шәр сәгать хезмәт куйган.

БЕРТУГАН КОМАРОВЛАР

Н.В.Комаров

1909 һәм 1914 еллардагы исәп-хисап кәгазьләренә теркәлгән мәгълүматларга караганда, «итекчеләр» арасында гаять җитди көндәшлек булган. Бик сирәк берләшмәләр генә «үз аякларында басып кала алган».

XX гасыр башында иң куәтле берләшмәгә ике династия – бертуган Комаровлар белән бертуган Родигиннар гына ия булган.

Бертуган Комаровлар үз берләшмәләренә 1870 елда нигез салган, дияргә тулы нигез бар. Җирле халыктан сатып алынган йонны фабрикада эшкәрткәннән соң, мамык хәленә китерелгән товарны үз өендә торып (1500ләп кеше) эшләүчеләргә тапшырганнар. Итекләр әзер булгач, бертуган Комаровлар аларга үз тамгаларын – «фирменный» билгеләрен төшергән.

1909 елгы мәгълүматлар буенча, «Бертуган Николай һәм Сергей Комаровларның Сәүдә йорты»ның төп капиталы 20 мең сум исәпләнгән, берләшмәнең запас капиталы исә 1,5 миллионга җиткән. Эшчеләр саны 2500гә күтәрелгән: 1000е – фабрикада, 1500е читтән торып эшләгән.

Фабрика җитештергән товарны Минзәлә, Казан, Түбән Новгород (Мәкәрҗә), Сембер ярминкәләрендә көтеп алганнар. Россия һәм халыкара сәүдә күргәзмәләрендә куелган товарлар медальләргә лаек булган.

БЕРТУГАН РОДИГИННАР

«Бертуган Родигиннар ширкәте»нең фирма бланкы

«Бертуган Родигиннар ширкәте»нә 1886 елда нигез салына. Туганнарның берсе – Иван Дмитриевич Рудниктагы киез итек фабрикасының хуҗасы саналган. Икенчесенеке – Михаил Дмитриевичныкы Кукмарада урнашкан була.

Бертуган Родигиннар арасында эш вазифасы болай бүленә: Николай Дмитриевич – управляющий, Михаил Дмитриевич – директор-оештыручы.

40 ат егәрле пар двигателе белән эшләгән берләшмәдә 1700 кеше хезмәт куйган. «Бертуган Родигиннар ширкәте»нең вәкиллекләре Мәскәүдә һәм Казанда да булган. ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

Фабрикантлар мирасы

Л.Галимуллина

2016 елда Кукмара бистәсе аша тимер юл узуга 100 ел булды. Шушы вакыт эчендә никадәр пассажир һәм йөк поезды безнең төбәк аша узгандыр?

XX гасыр башында тимер юл транспортын куллану илнең икътисады үсешендә зур роль уйнаган, чөнки товар әйләнеше су юлы һәм җигүле транспорт белән тормышка ашырылган. Бу су юлы һәм зур шәһәрләргә ерак урнашкан эшкуарлар өчен бик күп уңайсызлыклар тудырган. Бигрәк тә, зур фабрикалар тотучы хуҗалар Русия хөкүмәтенең 1911 елда Мәскәүне Екатеринбург белән тоташтыручы тимер юл проектларын әзерләүне хуплап каршы алалар. Бу юл бөтен Россия аша үтеп, Себер һәм Ерак Көнчыгышны тоташтырырга тиеш була. Казан-Сарапул-Екатеринбург һәм Түбән Новгород-Малмыж-Екатеринбург юлын төзү буенча эшләнгән ике проект та төбәкләр арасында бик күп бәхәсләр уяткан.

Казан-Екатеринбург тимер юлы Көнбатыш Урал һәм Русия үзәгендәге завод-фабрикаларның бер-берсенә чимал сату алу өчен һәм ягулык материалына да экономик яктан файдалы булыр иде.

Ниһаять, 1912 елның 27 апрелендә Министрлар Советы утырышында, бертавыштан, Мәскәү-Казан тимер юл оешмасының Казан-Сарапул-Екатеринбург проекты җиңеп чыга. Бу проектның җиңүе һәм тимер юлның Кукмара авылыннан 20 чакрым ерактан үтүе Кукмара һәм Мамадыш өязе фабрикантлары өчен уңайсыз булуы ачыклана. Һәм бу мөһим эш белән Кукмара авылының «Бертуган Комаровлар» сәүдә йорты хуҗасы Николай Васильевич Комаров шөгыльләнә башлый. 1913 елда ул, актив җәмәгать эшлеклесе буларак, земство комитеты исеменнән Мәскәү-Казан

тимер юлы җитәкчелегенә, тимер юл, элек планлаштырылганча, Кукмарадан 20 чакрым төньяктарак Бөр елгасы аша түгел, завод-фабрикалары булган Кукмара аша үткәрелсә, файдалы булачагын җиткерә. Фабрикант бу хәлне экономик яктан отышлы, дип саный. Аның белешмәсеннән күренгәнчә, Кукмара авылы аша узучы товар әйләнеше зур була: районга ел саен 720 мең пот йөк килгән, читкә 980 мең пот товар чыгарылган. Н.В.Комаровның дәлилләре министрлык вәкилләрен ышандырырлык булып, ниһаять, 1913 елның 14 маенда Казан-Екатеринбург линиясен инженер Белоцерковцевның проектын, юл элемтәсе министры С.В.Рухлов раслый һәм Казан-Екатеринбург тимер юлының бөтен участокларында эш башлана.

1914 елда хәзерге Кукмара районы биләмәсендә Казан белән Уралны тоташтыручы тимер юл салына башлый. Аны немец хәрби әсирләре сала. 1916 елда Кукмара авылы аша 34 чакрымлы бер юллы тимер юл уза. Шулай итеп, юллар күтәрелә, беренче рельслар салына. Беренче рельслар тешле эшләнеп, паровоз һәм вагоннарның тәгәрмәчләре дә шулай ук тешле булган. Юлда атнаун көнгә бер мәртәбә генә составлар узган. 1930 елда икенче юлны уздыру өчен Нурминкә елгасы аша күпер төзелә. Юл төзелешендә, Кукмара халкы белән бергә, I Бөтендөнья сугышында әсир төшкән һәм биредә яшәп калган немец солдатлары катнаша.

1920 елда Кукмарада беренче тимер юл вокзалы сафка баса. Ул Кукмара халкына һәм килгән кунакларга 85 ел хезмәт итә. 2005 елның 9 февралендә хәзерге вокзал фундаментына беренче нигез ташы салына һәм шушы ук елны кулланугa тапшырыла.

Ә 1991 елда Кукмара киез итек фабрикасы директоры Шамил Әхмәтшин тәкъдиме белән, фабрика каршына электр поездлары өчен тукталу платформасы ясала. Бу тукталышның рәсми исеме «927 нче км» булса да, халык телендә ул «Бертуган Комаровлар» исеме белән аталып йөртелә. Фабрикантларның Кукмара халкы өчен эшләгән яхшылыклары үзләренә һәйкәл булып кайтты.

Тимер юл, элек һәм бүгенге кебек үк, киләчәк буыннарга да хезмәт итсен иде. ■

Безнең мирас №6 июнь 2017

Ядкярләргә – бер гасыр

Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондыннан

1917 елның 1 июне

ЧИСТАЙ ШӘҺӘР ҖӘМӘГАТЬ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ КОМИТЕТЫНЫҢ ЧИСТАЙ ӨЯЗ ҖӘМӘГАТЬ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ КОМИТЕТЫНА ХАТЫ

Җәмәгать куркынычсызлыгы комитеты шушы елның 25 маендагы утырышында, Чистай өязе халкының Азатлык Заемына язылуда бөтенләй диярлек катнашмавын исәпкә алып, карар бирде: Азатлык Заемын популярлаштыру максаты белән, үз араларыннан кайбер әгъзаларны өязгә юлларга; андый хезмәтләрне тәкъдим итәргә һәм Өяз җәмәгать куркынычсызлыгы комитетына мөрәҗәгать итәргә.

Комитет рәисе Попов

Сәркатип өчен Хөснетдин Ваһапов

ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.147, 24б.

1917 елның 6 июне

ЧИСТАЙ ӨЯЗ ҖӘМӘГАТЬ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ КОМИТЕТЫНЫҢ ЕРЫКЛЫ ВОЛОСТЬ КОМИТЕТЫНА ХАТЫ

Өяз комитетының башкарма советы, Вакытлы хөкүмәтнең бөтен җирләрне хезмәт халкы карамагына тапшыру турындагы күрсәтмәсе булганчы, волость комитетына чиркәү җирләрен сөрүдән тыелып торырга тәкъдим итә.

Руханиларның үз атлары белән даими эшчеләр ярдәмендә эшкәртелүче чиркәү җирләренә өяз комитетының шушы елның 5-10 маендагы карарында күрсәтелгән хезмәт нормасы кулланылырга тиеш һәм ул җирләрнең хезмәт нормасыннан артыграк өлеше генә тартып алынырга мөмкин.

Чиркәү җирләре сөрелгән очракларда халык руханиларга җир урынына башкача ярдәм күрсәтүне билгеләргә тиеш.

Һәртөрле көч куллану һәм волость белән авыл комитетлары тарафыннан чара күрелмәү закон нигезендә җәзага тартылачак.

Совет әгъзалары имзалар

ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.147, 25б.


Въ Чистопольскій Уѣздный Комитетъ Общественной Безопасности.

Землевладѣльца при д. Муслюмкиной Ахметвалея Ахметсафина.

Заявленіе.

10 Іюня сего года крестьяне дер. Татарскаго Сарсаса Изгарской волости во время моего отсутствія въ городъ Казань, якобы по распоряженію Изгарскаго Волостнаго Комитета вырубили и увезли къ себѣ въ деревню 617 возовъ сырорастущаго и сухостойнаго лѣса, продолжаютъ возить и въ настоящее время а потому покорнѣйше прошу Уѣздный Комитетъ сдѣлать съ своей стороны распоряженіе объ охраненіи самовольной рубки и возки лѣса

1917 елның 13 июне

МУСЛЮМКИНО АВЫЛЫНЫҢ ҖИР МИЛЕКЧЕСЕ ӘХМӘТВӘЛИ ӘХМӘТСАФИННЫҢ ЧИСТАЙ ӨЯЗ ҖӘМӘГАТЬ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ КОМИТЕТЫНА ГАРИЗАСЫ

Шушы елның 10 июнендә Изгар волостеның Татар Сарсазы авылы крестьяннары, минем Казанга китүемнән файдаланып, Изгар волость комитеты күрсәтмәсе буенча дигән булып, 617 олау үсеп утырган һәм корыган агачларны кисеп алып киткәннәр, ташуны әле дә дәвам итәләр. Шуңа күрә өяз комитетыннан урманны рөхсәтсез кисүне һәм ташуны тыю турында күрсәтмә бирүне үтенеп сорыйм.

ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.147, 29б.

Документлар урыс теленнән тәрҗемә ителеп бирелә.



ОТЪ ВРЕМЕННАГО ПРАВИТЕЛЬСТВА.

Въ эти тревожные дни, послѣ недавно объявленнаго Правительствомъ обращенія къ населенію о сохраненіи полнаго спокойствія, безотвѣтственныя лица позволили себѣ помѣстить въ „Маленькой Газетѣ“ 13-го іюня отъ имени неизвѣстной организаціи призывъ къ демонстраціи съ требованіемъ сверженія Правительства.

Правительство твердо рѣшило оказать отпоръ всѣми силами государственной власти попыткамъ подобнаго рода, ведущимъ къ гражданской войнѣ, каковы бы ни были внѣшніе предлоги и мотивы, выставляемые при этомъ. Временное Правительство надѣется, что населеніе Петрограда своимъ спокойствіемъ и выдержкой поможетъ власти сохранить порядокъ. Правительство и съ своей стороны приметъ самыя рѣшительныя мѣры къ предотвращенію всякихъ подобнаго рода выступленій.

14-го іюня 1917 года.

1917 елның 14 июне

ВАКЫТЛЫ ХӨКҮМӘТНЕҢ ПЕТРОГРАД ХАЛКЫНА МӨРӘҖӘГАТЕ БАСЫЛГАН ЛИСТОВКА

Бу шомлы көннәрдә, хөкүмәтнең халыкка тулы тынычлык саклау турындагы мөрәҗәгатеннән соң, җавапсыз затлар билгесез оешма исеменнән «Маленькая газета»ның 13 июнь санында хөкүмәтне бәреп төшерүне таләп иткән демонстрациягә чыгарга чакыру бастырырга юл куйдылар.

Хөкүмәт, нинди генә тышкы сәбәпләр һәм сылтаулар китерелмәсен, гражданнар сугышына китерүче мондый омтылышларга дәүләт хакимиятенең бөтен көчләре белән кискен отпор бирергә карар кылды. Вакытлы хөкүмәт Петроград халкы үзенең тынычлыгы һәм.сабырлыгы белән хакимияткә тәртип сакларга ярдәм итәр, дип өметләнә. Хөкүмәт тә, мондый чыгышларга юл куймас өчен, үз ягыннан иң кискен чараларны күрәчәк.

ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.109, 44б.

1917 елның 30 июне

ЭШЧЕ ҺӘМ СОЛДАТ ДЕПУТАТЛАРЫ СОВЕТЫ БӨТЕНРОССИЯ ҮЗӘК БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЛИСТОВКАСЫННАН

Иптәшләр! Эшче һәм солдат депутатлары советының Бөтенроссия съездында белдерелгән Учредительное собраниене чакыруны тизләтү турындагы теләк гамәлгә ашты: Вакытлы хөкүмәтнең 14 июньдәге карары белән сайлаулар 17 сентябрьгә, Учредительное собраниене чакыру 30 сентябрьгә билгеләнде.Сайлау кампаниясе шушы көннәр билгеле булгач башланды.

Сайлауга нибары 2,5 ай вакыт калды. Бу вакыт аралыгында гаять зур техник эш һәм күпчелек өлеше сәяси сайлауларда әле беренче мәртәбә генә катнашкан барлык гражданнарны да бөтенхалык Учредительное собраниесенең максатлары һәм бурычлары белән таныштыруга кагылышлы тагын да мөһимрәк сәяси эш башкарылырга тиеш...

Революцион демократия алдында торган бурычларның бөтен авырлыгын танып, Эшче һәм солдат депутатлары советының Бөтенроссия съезды...Эшче һәм солдат депутатлары советының Үзәк Бөтенроссия Комитеты каршында Учредительное собраниегә сайлаулар буенча бюро оештыру турында карар кабул итте...

Бу бюроның эшен гамәлгә куеп, Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты сездән үз эшчәнлегегез районында сайлауларга әзерлекне кичекмәстән башлауны сорый...

ТР ҮДА ТСД , ф.36, тас.1, э.147, 312б.

Документларны басмага ТР Дәүләт архивы секторы мөдире
***Римма Садыйкова** әзерләде.* ■

E-mail: prm.archive@tatar.ru
www.arhiv.tatarstan.ru

М.Шәйдуллин, Р.Ратникова, Н.Ихсанова, Ә.Шакиров, Л.Шәфигуллин

Хәтердә син, туган авылым!

2013 елның 10 сентябрендә Россиянең һәм Татарстанның халык артистлары, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге ияләре Нәҗибә Ихсанова белән Әзһәр Шакиров туып үскән Азнакай районының Яңа Ташлыяр авылы булган урынга куелган истәлек стеласын ачу тантанасы булды.

Стеладан тыш, биредә инде шактый эш башкарылды – иске зират, төзекләндерелеп, коймасы һәм ташлары алыштырылды.

«Таттелеком» ААҖнең генераль директоры Лотфулла Шәфигуллин җир йөзеннән юкка чыккан авылның – милләтебезнең горурлыгына әйләнгән олы хөрмәткә лаек азнакайлылар, сәхнә осталары һәм ветераннарының туган җире истәлеген мәңгеләштерү идеясе белән чыккан иде. Аның игелекле башлангычына муниципаль район башлыгы Марсель Шәйдуллин да теләктәшлек күрсәтте. Бу истәлекле җирдән үтүче юл буенда биредә атаклы шәхесләр туып үсүен дәлилләгән стела лаеклы урынын алды. Нәҗибә Ихсанова белән Әзһар Шакиров, стеланы тантаналы рәвештә ачканнан соң, якташлары һәм күп санлы кунаклар белән, кайчандыр Ташлыяр авылы булган урынга юнәлде. ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның июнь ае

Сәхифәне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Зыяфәт [кунак итү]

Әл-мөфти әл-ислам дамелла Галимҗан хәзрәтнең мөфтилек хидмәтен башкару өчен Уфага китүе мөнәсәбәте илә, мөхибләре [якын дуслары] тарафыннан сиһшәнбе көн, 6 июньдә аның шәрәфенә зыяфәт мәҗлесе ясалачак. Катнашырга теләгән әфәнделәргә Исхак әфәнде Карташев кибетенә килеп язылырга мөмкин.

Съезд ачылды

Кичә, өченче июньдә Новый клуб бинасында Казан губернасы мөселман авыллары мөселманнары съезды ачылды. Килгән вәкилләрнең хисабы биш йөз чамасында булып, һәммәсе авыл киемендә, авыл халкыдыр. Съезд – нәкъ авыл съезды. Гаять гади рәвештә клубның түбән катында вәкилләр – югары тавышларга ия булмаганнар, лоджияларның берсе – мөхәрриләргә, икенчесе читтән килгән кадерле кунакларга билгеләнгән, президиум сәхнә уртасына урнаштырылган. Аның бер ягында мөхәррирләр өстәле, бер ягында съезд комиссиясе тарафыннан куелган стенографистлар утыра. Мәҗлесне тәбрик итәргә килүче руслардан губернский земский управа рәисе генә күренә. Казандагы һәммә организациядән тәбрик итәргә килгән вәкилләр бар. Сәгать биштә Габдерахман Исхаков матур гына нотык сөйләп, арадан бер хәзрәтнең Коръән укуга чыгарылуын үтенә. Галәветдин Назиров тарафыннан сүрәи «Кәһәф»тән берничә аять укылып мәҗлес ачыла.

Кояш. – 1917. – №1127. – 4 июнь.

Мөселманнарга гыйбадәтханә

Архангельский бистәсендәге мөселманарның күп булуын, күл аркылы чыгып, аларга мәсҗедләргә йөрүнең уңайсызлыгын һәм рамазан аенда кичнең дә кыскалыгын игътибарга алып, Ближний Архангельскийда үз йортымда бу сәнә тәравих укыр өчен урын әзерләдем. Имам булу өчен бер шәкерт куелачак. Ахангельский бистәсендәге мөселманнарның дикъкатенә шуны белдереп, мөкатдәсе рамазан кичләренә, тәравих намазына калмый килүләрен үтенәм. Йортның капкасы тәравихка килүче һәр мөселман өчен ачык, рәхим итсеннәр. Хөрмәт илә, Габдерахман Шәмсетдинов.

Кояш. – 1917. – №1128. – 6 июнь.

Җәйге дәресләр

Казан мөгаллимәләр җәмгыяте тарафыннан укый-яза белмәгән һәм укый белеп тә яза белмәгән ханымнарны укырга һәм язарга өйрәтү өчен җәйге дәресләр булачак. Теләгән ханымнар түбәндәге кешеләрдә язылырга мөмкин: Алкин ышкулында Фатыйма Дәүләткилдиева, Кызыл мәсҗед мәхәлләсендә Шакирҗан Таһиров йортында Суфия Таһирия, Зәңгәр мәсҗед мәхәлләсендә Сабир хәзрәт йортында Гайшә Халидиядә.

Кояш.– 1917. – №1129. – 8 июнь.

Даталар иске стиль белән бирелә.

Шәһәр театры бинасын сорау

«Сәйяр» труппасы артистлары мөдире Г.Кариев Казанда торучы халыкларның өчтән берен мөселманнар тәшкил иттеген, шәһәр театры салынган вакытта мөселманнарның да көче кергән вә шул сәбәпле, ул бинадан мөселманнарның да файдаланырга хакы булдыгын белгезеп, атнасына бер мәртәбә 300 сум хак бәрабәренә шәһәр театрын мөселманча спектакль куюю өчен сорап гариза биргән икән. Управа Кариевның бу гаризасын шәһәр театры комиссиясе һәм шәһәр театрын иҗарәгә [арендага] бирүче Ыстапанофка тапшырган. 5 нче июньнән башлып, Кариев читтәге атаклы артист вә артисткаларны җыеп, көчле бер группа төзиячәк. Һәм һәр атнада берсе шәһәр театрында, берсе Большой театр бинасында ике мәртәбә спектакль куеп торачактыр.

Кояш. – 1917. – №1132. – 16 июнь.

Официант вә поварлар бюросы

Беренче июньдә мөселман номерлары вә чәйханәләрендә хидмәт итүче повар вә официантларның гомуми җыелышлары булып, рәис, сәркатиб һәм дүрт әгъза сайланып, официант вә поварлар бюросы төзелде. Бюроның вакытлы урыны Апанаевское подворьеда, 76 нчы номердадыр.

Солдатларымызга китап кирәк

Сугыш сафындагы 305 нче Ланшевский полктагы мөселман солдатларының вәкилләре Җарулла әфәнде Мортазин белән Җиһанша Җаббаров полктагы мөселман солдатларының китапка мохтаҗ булуларын сөйлиләр һәм химмәтле кешеләрдән мөселман солдатларга китап алырга иганә бирүләрен үтенәләр.

Кояш. – 1917. – №1132. – 16 июнь.

Митинг

Җомга көн Юнысовлар мәйданында фроннтан кайткан Габделхак Бикташев дигән бер унтер-әфитсәр, халыкны җыеп, азык эшләре вә башка нәрсәләр тугрысында сөйләде. Ач халык бу көндә бер көнге кебек кызарга тора иде, ләкин фронттан кайткан солдатка каршы Габдерәшитов исемле бер прапорщикның нигезле генә җавап бирүе халыкны таратуга зур ярдәм итте. Митинг куркыныч төс алганга, Солдат, эшче һәм крестьян вәкилләре шурасыннан да берничә кеше килгәнлеге беленде. Җыелыштагы сүзләр, кем нәрсә белсә – шуны сөйләүдән гыйбарәт иде. Бикташев, хәрби комитет вә Казан организацияләренә бик өстән карап, үзен Казанны тәртипкә салырга йибәрелгән кеше иттереп сөйли.

Кояш. – 1917. – №1133. – 18 июнь.

Тәшәккер

Казан сәүдәгәрләреннән Фазылҗан Сабитов бу көннәрдә Казанга 500 пот кадәр богъдай оны табып китереп, арзан бәһа илә фәкыйрь мөселманнарга егерме кадактан хисаплап саттырган. Хәзерге көндә богъдай онының бәһасе егерме сумга йиткән булса да, Сабитов фәкыйрьләргә 15 сумнан хисап итеп саттырган.

Кояш. – 1917. – №1134. – 21 июнь. ■

МАЙ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 3 майда Казан шәһәренең кызлар гына укый торган 4 нче гимназия-интернатында истәлекле очрашу булды. Анда «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Марат Закир белән Ленар Гобәйдуллин һәм басмабызның даими авторы язучы-сатирик Алмаз Хәмзин катнашты.

● 9 майда Казанда узган «Үлемсез полк» акциясендә Татарстанның атказанган артисткасы Хәлимә Искәндәрова да катнашты. Ул әлеге чарага Смоленск өлкәсенең Духовщинский районы Конопляники авылында һәлак булган әтисе – артиллерия лейтенанты Шакир Искәндәровның фоторәсемен алып чыккан иде.

● 12 майда Питрәч районының Шәле авылында журналист Алсу Хәсәнованы искә алу кичәсе булып узды. Анда «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире Миңназыйм Сәфәров, җырчылар Вил Усманов, Рөстәм Асаев һ.б. катнашты. Чараны күренекле артист һәм режиссер Айдар Хафизов алып барды.

● 13 майда Биектау районының Шәпше авылында, 400ләп кеше катнашында, «Иске Казан түгәрәк уены» татар фольклор республика фестиваленең йомгаклау чарасы үтте. Иң яхшы башкаручылар 5 августта Казан Кремлендә узачак «Түгәрәк уен» фестивалена чакырылачак.

● 15 майда Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубында һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты, шагыйрә Сания Әхмәтҗанованың иҗат кичәсе үтте

● 17 майда Казан федераль университетының «Tataristika» үзәгендә «Татар театры: югалту һәм табышлар» темасына багышланган сөйләшү булып узды. «Калеб» яңа буын җыены җитәкчесе Гүзәл Сәгыйтова алып барган әлеге чарада Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев, Казан театр училищесы мөгаллиме, режиссер Илдар Хәйруллин, «Мәдәни җомга» газетасы һәм «Сәхнә», «Безнең мирас» журналларының баш мөхәррире Вахит Имамов, Зиннур Хөснияр, Ләбиб Лерон, Буа татар дәүләт театрының сәнгать җитәкчесе Раил Садриев, Язучылар берлегенең драма секциясе җитәкчесе, «Безнең мирас» журналы хезмәткәре, драматург Рәдиф Сәгъди, Казан федераль университеты профессоры Әлфәт Закирҗанов, галимә Миләүшә Хәбетдинова, Әлмәт татар дәүләт драма театры директоры Фәридә Исмәгыйлева, К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрының әдәби бүлек җитәкчесе һәм артисты Шамил Фәрхетдинов, драматург һәм режиссер Илгиз Зәйниев татар милли театры сәнгате турында фикер алышты.

● 18 майда Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь районы Уразавыл Мәдәнният йортында милли тарихны өйрәнүгә юнәлдерелгән иҗади проект кысаларында оештырылган «Минем авылым», «Минем әни», «Тукай әкиятләре», «Минем шәҗәрәм» бәйгеләрен йомгаклау тантанасы булды.

● 19 майда – Татарстан Матбугаты көнендә – ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, массакүләм мәгълүмат чаралары җитәкчеләре белән очрашып, аларны һөнәри бәйрәмнәре белән котлады.

Шул ук көнне кичен «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә Татарстан Республикасы журналистика һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә «Бәллүр каләм – 2017» бәйгесенә йомгак ясалды.

● 19 майда VIII Бөтендөнья татар дин әһелләре форумы делегатлары Россия Ислам университетында узган «Ислам һәм матбугат» секциясендә үз эшләре турында мәгълүматны киң җәмәгатьчелеккә җиткерү юллары хакында киңәште.

● 20 майда Болгар шәһәрендә «Изге Болгар җыены» мөселманнар корылтае булып узды.

● 24 майда Азнакайда «Юкка чыккан авылларны өйрәнү проблемалары» дигән темага Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе булып узды. Чарада «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон катнашты һәм чыгыш ясады.

«...бездә гыйффәт бозыла»

(«Яшен» журналыннан)

БЕР АСРАУ КЫЗНЫҢ ИДАРӘМЕЗГӘ ЯЗГАН ШИКАЯТЕ[1]

Аһ вә зары

Яшем йитте сигезгә, әткәй илтте калага.
Байга биреп калдырды, дучар булдым бәлагә.
Иртә торсаң – кара эш, без бәхетсез кызларга.
Кичкә кергәч, арыгач, тотына балтыр сызларга.
Аякта иске читек, башымда җыртык яулык,
Көне-төне йөгерү, сакланмый безнең саулык.
Безнең ашау – калган аш, безнең эчү – калган чәй.
Көне буе чапкан җитми, тагын урыннарын җәй.
Бай хатыны кычкыра безгә яман сүз белән,
Үсеп җитә башлагач, карый яман күз берлән.
Көн-төн газап чигәмез, без, асраулар дөньяда,
Ахирәттә ни булыр – тапшырамыз Ходага.
Безнең хәлләр бик яман, бай да кул суза һаман.
Иртәдән кичкә кадәр бикә шелтәли яман;
Бер җугары, бер түбән йөгерәмез туктамый.
Бер атналап үтәдер, һичбер төнне йокламый.
Әле угылы эткәли, әле хуҗа төрткәли;
Безнең асрау кызларда шулай намус беткәли;
Намус беткәч нур китә, безне хуҗа хур итә:
«Асрау кызлар – намуссыз», – дип, безнең данымыз китә.
Шулай намус беткәли, эшләр судка киткәли.
Докторларга бирә-бирә, кредитлар беткәли.
Бәгъзе хаин карт байлар безгә бик тиз кызына,
Уникегә җиткән чакта бездә гыйффәт бозыла.
Үзе суфый була ул, үзе хаҗи була ул,
Аулак-аулак вакытларда безгә кулны суза ул.
Без, бичара, яшь кызлар, кемгә сөйлик бу сүзне.
Шулай хаҗи, хуҗилар харап итәләр безне.
Шулмы инде дин тоту? Асрауларны хур итү!
Фәрештәдәй саф кызны, баштанаяк карайту.
Кайсы безне никахлый, хәмел куйганга чаклы,
Хәмел тәмам булгачтын, бирәдер талак хатыны.

[1] Бер дә үзгәртмичә үзе язганча табигъ иттек. («Яшен» журналы редакторының искәрмәсе).



Рәсемдә: бай җиһазланган бүлмә эчендә түбәтәй кигән, зур бүксәле карт сәүдәгәр һәм аптыраган өч хатын-кыз сурәте.

Рәсем астында язу:
– Кара әле, син, ул ни кылуың инде? Син ярмаркада яңадан дүртенче хатын алган, диләр, дөрест сүзме ул?
– Бер дә хафаланмаңыз, моннан соң бишенчене алмам инде.

Яшен. – 1909. – №8 (29 апрель). – 16 б.

Мондый кабахәт эшләр бары безнең татарда,
Шундый хаин бәндәләрне кирәк иде атарга.
Харап итеп бетергәч, иргә бирәләр безне,
Алар тагы шелтәли, хуҗаң бозган, дип, сезне.
Без иминнәр итәмез, юк-юк, диеп, ирләргә.
Менә шундый вакытлар төшерә безне тирләргә,
Ул ышанмыйдыр сүзгә, ора бик каты йөзгә.
Хуҗаның шул хыянәте, гомергә китә безгә.
Безгә галәм дә дошман, безгә залим да дошман.
Әйтсәңезче, кардәшләр, кемгә сыгыныйк бу эштән?

Асрау кыз.

Яшен. – 1908. – №8. – Б.10.

Сәхифәне ***Рәйсә Шәрәфиева*** әзерләде. ■

Бөтендөнья татар конгрессы бинасы

«Безнең мирас»

елъязмасы / июнь

• 640 ел элек (1377)

Мамай мирзаның уң як Идел ярындагы идарәчесе – гаскәр башлыгы Гарәпшаһ Мәскәү кенәзлегенең урыс гаскәрләренә Пьяна елгасы буенда һөҗүм итә, хәлиткеч җиңүгә ирешә.

• 180 ел элек (1837)

Сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче Әхмәт Мөхәммәтгали улы Хөсәенов (1837-1906) дөньяга килә.

• 115 ел элек (1902)

15 июньдә шагыйрь Шамун Фидаи (Касыйм Хәсән улы Шакирҗанов (1902-1920) дөньяга килә.

• 95 ел элек (1922)

Уфада, Татарстан китап нәшриятының бүлекчәсе буларак, «Таң» исемле китап кибете ачыла. Башында Исмәгыйль Рәмиев һәм Давыт Юлтый торган бу кибет татар китабын пропагандалау, аны сату эше белән шөгыльләнә.

• 90 ел элек (1927)

Казанда «Татар дәүләт академия театры» исемле журнал чыга башлый.

• 75 ел элек (1942)

«Совет әдәбияты» журналында Фатих Кәримнең «Идел егете» поэмасы дөнья күрә.

• 60 ел элек (1957)

«Совет әдәбияты» журналында Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» исемле повесте басыла башлый.

• 25 ел элек (1992)

9-10 июньдә башкалабыз Казанда Халыкара тюркология конференциясе була.

19-21 июньдә I Бөтендөнья татар конгрессы оештырыла. ■

Мирасворд

Сәгыйть Рәмиев шигыре

Әмирхан Еники повесте

«Утызынчы ел» романы авторы

«Сак-...» бәете

Петр Чайковский операсы

Әхәт Гаффарның 1975 елда чыккан беренче китабы

... Сагиян (әрмән шагыйре)

Борынгы Рим полководецы

1905-1907 елларда Уральскида татар телендә чыккан газета

... Бәшири

Бомарше пьесаларындагы каһарман

Гаскәри берәмлек

Рус адмиралы, сәяхәтче һәм географ

Телдән әйтелгән фараз, гипотеза (диал.)

Того мәркәзе

Газ плитәсенең элекке «туганы»

Яшерен дошманлык, ачу, үч

Байрак, флаг (иск.)

Җайдак утыргычы

Чуаш телендәге әдәби журнал

Мансиларның элекке атамасы

Җиләк-җимеш «паласы»

Акчалата ярдәм

Калашников автоматы

... Харис (башкорт шагыйре)

Режиссер Рифкать ...

Актриса ... Хәйретдинова

... Хангилдин (тел галиме, педагог)

Тәрҗемәче ... Халитов

Кызны кияү йортына озата баручылар

Амударьяның борынгы исеме

Арыслан көтүе

Борынгы славян әлифбасындагы хәреф

Аллага якын, изге кеше (иск.)

Борынгы сугыш коралы

Бөтенне кисәкләргә бүлү

«... белән Мәҗнүн» дастаны

Вьетнам акчасы

5 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: Аталык, Думави, капрал, баек, Фасил, «Ургыл», якташ, «Ил», Газиз, Даши, алай, Лена, Зыя, кая, «Аваз», ачуташ, Шакир, Лас, әүлия, ушат, фи, «Аң», Әнәс, най.

Өстән аска: «Угызнамә», фа, паяз, Яруллин, Айдарский, таифә, Аитзак, «Ася», «Акмулла», Лаеш, ая, ку, клипер, алача, Агишев, Кашан, былина, аңа, азурит.

Рәис Габдулла төзеде.

Безнең мирас №6 июнь 2017



СОДЕРЖАНИЕ. ИЮНЬ 2017

Историческое наследие: «Булгар. Инфраструктура»; «Остров Алазань» Л.Сагитова; «Средняя Алазань» Р.Марданов, Н.Китаева; «Шакирд Кышкарского медресе – генерал Османской империи» И.Биккинин, А.Ахунов.

Педагогическое наследие: «Он из рода Амирхановых!» Р.Амирхан.

Тюркский мир: «Ногайские казаки» Р.Аминов, «Мы из племени борцов!» А.Галимзянов

Литературное наследие: «Кутадгу билик. («Благодатное знание»)» Й.Баласагуни; «Был чувствительным и гордым человеком» Р.Фаттахова.

Татарская песня: «Дорогое воспоминание» Г.Каримова.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов» А.Тимергалин.

100 лет назад..: «Казанские вести» в газете «Кояш»: июнь 1917 года».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. JUNE 2017

Historic heritage: «Bulgar. Infrastructure»; «The Alazan island» by L.Sagitova; «The Central Alazan» by R.Mardanov, N.Kitayeva; «The student of the Kishkar medreseh is the general of the Ottoman Empire» by I.Bikkinin, A.Akhunov.

Pedagogical heritage: «He is one of the Amikhanovs' tribe!» by R.Amirkhan.

The Turkic world: «The Nogay Cossacks» by R.Aminov, «We are of the wrestler's tribe!» by A.Galimzyanov.

Literary heritage: «Kutadgu bilik» («The blessed knowledge») by U. Balasaguni; «He was sensitive and proud one» by G. Karimova.

Word is a language's decoration: «Dictionary of national terms» by A.Timergalin.

100 years ago…: «Kazan news» is in the «Koyash» newspaper: June of 1917».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

«Кызыл
күләгәле
автопортрет».
Киндер,
майлы буяу.
1993 ел

ВИКТОР ФЁДОРОВ
(1940-2001)

СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык рәссамы.

«Шиһабетдин
Мәрҗани
портреты».
Киндер, майлы
буяу.
1989 ел

«Тукай сүзе».
(Тукай"«Сәйяр»
труппасы белән).
Киндер, майлы
буяу.
1986 ел

АЛДАГЫ САННАРДА УКЫГЫЗ:

Менә хикмәт! Аяз Гыйләҗевнең җиңгәчәе Ркаил Зәйдулланың әнисенең татар теле укытучысы булган икән. Фидания апа Шыгырданнан булса да бер хәл инде диярсең! Аяз Гыйләҗев Ркаил Зәйдулла турында «Йәгез, бер дога!» романында: «... Рөстәм Сүлти яза, Ркаил Зәйдулла яза, аларның һәр язганы Ходай биргән талант югарылыгында калачак!» – ди. Ә Ркаил Зәйдулланың «Аяз Гыйләҗевкә» дигән шигырендә түбәндәге юллар бар:

«Офыккача аклык бүген,
Ирексездән җаннарга йога.
Аксакалның эзләренә карыйм,
һәм кабатлыйм: йәгез, бер дога!..»

Шыгырдан төене. Фатих Кутлу

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә*

электрон версия

4 612750 670172

*«**БЕЗНЕҢ МИРАС**» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*